Самарские татары

# Самар татарлары

ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР

№ 4(5), ОКТЯБРЬ–ДЕКАБРЬ 2013

ТАТАР МИЛЛӘТЕН
ҖЫР ДА САКЛЫЙ





Виктор САЗОНОВ:
Мы – разные, но едины
в стремлении жить
в мире и дружбе



Ару-талу белмәс
Укытучы апа



Лейла Санфирова.
«Свет угасшей
звезды»



## Венера РАМАЗАНОВА:
## С особым трепетом передаю телезрителям новости татарского и исламского сообществ!

6+

***Газиз милләттәшләр!***

*Сезне якынлашып килүче Яңа 2014 ел белән чын күңелдән тәбриклибез!*

*Тылсымлы Яңа ел төнендә һәркайсыбыз хыял диңгезендә йөзә, барлык теләкләрнең дә үтәләсенә ышана. 2014нче ел сезнең өчен ышаныч-өметләрнең аклану, уй-хыялларның чынга ашу чоры булсын! Күтәренке кәеф һәм күңел көрлеге һәрвакыт изге эшләргә өндәп торсын! Сезгә һәм якыннарыгызга бәхет, исәнлек-саулык, иминлек һәм мул тормыш телибез!*

*Киләсе елларда да бергә булыйк, бердәм булыйк, милләтебезгә бергәләп хезмәт итик. Хәрәкәттә - бәрәкәт. Безне алда зур эшләр көтә!*

**Изге теләкләр белән Самар өлкә "Туган тел" татар җәмгыяте президенты Ильяс Гомәр улы ШӘКҮРОВ.**

***Дорогие соплеменники!***

*Сердечно поздравляем вас с наступающим Новым 2014 годом!*

*В волшебную новогоднюю ночь в каждом из нас просыпается маленький ребёнок, мы все загадываем самые сокровенные желания и надеемся на их скорейшее исполнение. Желаем осуществления всех заветных желаний, здоровья и подъема творческих сил! Пусть счастье, удача и благополучие всегда сопровождают вас и наступающий год станет годом больших достижений и добрых дел, годом финансового благополучия и стабильности!*

*Пусть и в дальнейшем всем нам будет суждено держаться воедино, вместе служить своему народу! В движении – жизнь и сила. Впереди нас ждут большие дела!*

**С искренними пожеланиями президент Самарского областного татарского общества «Туган тел» Ильяс Гумерович ШАКУРОВ.**

*Хөрмәтле милләтәшләр!*

*Барыгызны да якынлашып килүче Яңа 2014 ел белән котлап, исәнлек-саулык телибез. Гаиләбәхетегез тулы булсын, күңелләрегездә тынычлык хөкем итсен. Киләчәк көнгә ышаныч белән яшәгез. Күтәренке кәеф һәм күңел көрлеге һәрвакыт изге эшләргә өндәп торсын!*

*Киләчәктә дә бердәм булыйк! Халкыбыз берләшкән очракта гына туган телебезне, милли мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калачакбыз.*

*Бәйрәм белән!*

**Самара өлкә татар эшкуарларына ярдәм итү ассоциациясе.**

***Дорогие соплеменники!***

*Поздравляем всех вас с наступающим Новым 2014 годом. Желаем вам отменного здоровья, семейного счастья, душевного спокойствия, неизменного оптимизма, неиссякаемой веры в себя. Пусть приподнятое настроение, чистота помыслов и души способствуют вам творить благородные дела.*

*И в дальнейшем мы должны оставаться единым народом! Только так нам удастся сохранить родной язык, национальную культуру, свои традиции и обычаи.*

*С праздником!*

**Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области.**

*С Новым 2014 годом!*

# Хөрмәтле укучыларыбыз!

Мена инде "Самар татарлары" журналының беренче саны дөнья күргәннән соң да бер ел үтеп киткән. Ул ике телдә чыгып килүче бердәнбер калын, төсле, яхшы кәгазьдә басылучы бу басманың аякка басу чоры булды, дияр идем.

Узган елда журналның биш саны чыкты. Укучыларыбыздан мактау сүзләрен ишетеп тору күңелләрдә куаныч һәм өмет уятып тора.

Әйткән теләкләрегезне, тапкан кимчелекләрне кабул итеп, алдагы саннарны тагын да кызыклырак итү, камилләштерү өстендә бертуктаусыз эшләргә тырыштык. Шуңа да басманың һәр саны тагын да баерак эчтәлекле, матуррак бизәлешле булды.

"Самар татарлары" журналы массакүләм чарасы буларак та теркәлде. Элемтә, информацион технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр Федераль службасы идарәсендә теркәү үтеп, почта каталогына 72675 индексы белән кертелде. Хәзер аңа язылып була. Кварталга бер тапкыр килә торган бу басманың бәясе ярты елга язылучылар өчен - 424 сум 6 тиенгә, 3 айга язылган очракта 212 сум 3 тиенгә төшә.

Шөкер, өлкәбезнең социаль оешмаларын – мәктәпләрне, авыл-ларда урнашкан Мәдәният йортларын, балалар бакчаларын, хастаханәләрне үз акчаларына яздыручы берләшмәләр бар. Мәсәлән, өлкәбезнең татар эшкуарларына ярдәм итү ассоциациясе төбәгебезнең барлык татар авыл мәктәпләрен, берничә балалар бакчасын һәм Камышлы район Мәдәният йортын басмага яздырды. Әлеге күркәм үрнәк башка татар эшкуарларына да йогынты ясар, дип өметләнәбез.

Кулыгызга алган шушы журналыбыз яңа 2014 ел алдыннан чыкты. Шуңа да барчагызны да редакциябез исеменнән тылсымлы һәм якты Яңа ел бәйрәме белән тәбриклим. Яңа ел Сезнең өчен ышаныч-өметләрнең аклану, уй-хыялларның чынга ашу елы булсын! Сезгә һәм якыннарыгызга исәнлек-саулык, иминлек һәм мул тормыш телибез!

# Уважаемые читатели!

Вот и пролетел ровно год со дня выхода первого номера журнала «Самар татарлары». Это было временем становления единственного в Самарской области подобного двуязычного издания. За прошедший год мы успели выпустить пять номеров и собрать невероятное количество самых разнообразных отзывов. Радует, что большая часть из них положительная и доброжелательная.

Ко всем замечаниям в наш адрес мы относимся внимательно и серьезно, стараемся учитывать пожелания и советы читателей. Именно поэтому журнал от номера к номеру становится все более содержательным и красочным.

Журнал «Самар татарлары» получил свидетельство о регистрации СМИ, редакция заключила договор с Управлением федеральной почтовой связи России по Самарской области, благодаря чему теперь каждый из вас может его выписать в ближайшем почтовом отделении. Подписной индекс журнала «Самар татарлары» («Самарские татары») 72675. Стоимость подписки на 3 месяца составляет 212 рублей 3 копейки, на 6 месяцев – 424 рубля 6 копеек.

Отрадно, что есть организации и объединения, которые за свой счет подписывают на наш журнал социальные учреждения – школы, сельские дома культуры, детские сады, больницы... Так, учредитель журнала НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области» подарил подписку всем сельским школам Самарской области, где преподается татарский язык, нескольким детским садам и Камышлинскому районному Дому культуры. Мы надеемся, что добрый пример будет поддержан и другими татарскими предпринимателями.

Номер, который вы держите в руках, вышел в канун, нового, 2014 года. И от имени нашей редакции я поздравляю всех наших читателей с этим светлым и волшебным праздником – Новым годом! Пусть в новом году сбудутся все ваши мечты и желания! Здоровья вам и вашим близким!



**Данияр СӘЙФИЕВ,**
*"Самар татарлары" журналы мөхәррире*


РЕДАКЦИОННЫЙ СОВЕТ

**Шакуров Ильяс Гумерович** – президент СОТО «Туган тел»;

**Шакуров Ильдар Гомерович** – гл.врач ГБУЗ Самарский областной кожно-венерологический диспансер

**Сайфиев Данияр Ирекович** – гл. редактор журнала «Самар татарлары» («Самарские татары»;

**Нуретдинова Римма Равильевна** – редактор портала www.samtatnews.ru;

**Аглиуллин Рафгат Набиуллович** – гл. редактор газеты «Бердәмлек»;

**Ахмеров Шамиль Абульнагимович** – член Совета СОТО «Туган тел»

**Батршин Гумар Мулланурович** – председатель Попечительского совета фонда «Булгарское наследие»

**Колючев Ильгиз Исмаилович** – вице-президент СОТО «Туган тел»,

**Махмутов Фархад Сабирзянович** – директор ООО «Татарское радио – Самара»

**Надиров Азат Камилович** – член Совета СОТО «Туган тел»,

**Сагдеев Ильгизар Ягфарович** – ахун Самарской области, имам-мухтасиб Сызранского и Шигонского района

**Сафин Иршат Халилович** – имам-хатыб соборной мечети г. Самары

**Наиля Фаридовна Тагирова** – Зав. Кафедрой Самарского Государственного Экономического Университета

**Хузин Рифгат Туктарович** – председатель татарской национально-культурной автономии г. Самары

РЕДАКЦИОННАЯ КОЛЛЕГИЯ

**Биктаев Наиль Данисович**
**Варфаламеева Эльмира Мугаммаровна**
**Галимов Шамиль Хайдарович**
**Мифтахов Искандер Фуадович**
**Файзуллов Рустам Ильясович**
**Ширязданов Фарид Хамитович**
**Шарипов Руслан Кабирович**
**Султанова Жанна Валерьевна**

# Содержание:

Новости ... 3-9
Татар милләтен жыр да саклый ... 10-12
Татарский «Сэмбелэ»: новые традиции старого праздника ... 13-15
Учительница первая моя… ... 16-17
Вскрытие показало серьезные болезни ряда жизненно важных органов ... 19-23
**Виктор САЗОНОВ:** мы – разные, но едины в стремлении жить в мире и дружбе ... 24-25
Ничто не ново под луной? ... 26-29
Онытылмас мәгърифәтче ... 30-31
Ару-талу белмәс укытучы апа ... 32-36
**Рафаэль БАГУТДИНОВ**: «Главным богатством Камышлинского района является талантливый и творческий народ» ... 38-41
Егерме ел халкыбызга хезмәттә ... 43-45
Битва на Кондурче ... 46-50
Промышленники и меценаты Акчурины ... 52-53
Ильдус ГИЛЬМАНОВ: работы предстоит много ... 54-55
Татар мәчет тирәсенә тартыла ... 56-57
Авылның исеме аңа зур вазыйфалар йөкли ... 58-59
Как молоды мы были… ... 65-70
**Венера РАМАЗАНОВА**: «С особым трепетом передаю телезрителям новости татарского и исламского сообществ!» ... 72-73
Мәңге яшә, Әбдеки! ... 74-77
Беренче мәртәбә мәчет төзелешен татар хатыны җитәкләде ... 78-80
Энҗеләребезне барлап торыйк ... 81-84
Ульяновский центр национальной культуры открыт для всех ... 85-87
Әтисенең каберен эзләп узган гомере ... 90-91
Добрые дела творятся там, где их делают ... 95-97
Шигырь язучы белән шагыйрьнең аермасы нидә? ... 100-101
“Полиция хезмәткәре яхшы психолог булырга тиеш” ... 104
“Янәшәмдә ныклы терәгем бар” ... 106-107
«Duslar club» –яшьләр оешмасы ... 111-113
Как лечить душу ... 114-115
Творить белоснежные улыбки! ... 116-117
Наиля МИФТАХОВА и ее трудный век ... 118-119
**Равиль ИКСАНОВ:** «Положительную энергетику мы создаем сами» ... 120-122
**Эдуард ЛАТЫПОВ:** «Я из райцентра Камышла Самарской области, у меня татарская фамилия, а бегаю я за Башкирию» ... 124


10
**ТАТАР МИЛЛӘТЕН ЖЫР ДА САКЛЫЙ**


32
**АРУ-ТАЛУ БЕЛМӘС УКЫТУЧЫ АПА**


92
**СВЕТ УГАСШЕЙ ЗВЕЗДЫ**

Издатель НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», адрес: 443087, г. Самара, пр. Кирова, 206

**Главный редактор:** Данияр САЙФИЕВ
**Корреспонденты:** Миляуша ГАЗИМОВА, Римма НУРЕТДИНОВА, Эльвира ШАВАЛИЕВА, Фарид ШИРИЯЗДАНОВ, Шамиль БАГАУТДИНОВ, Нурсина ХАКИМОВА
**Дизайн-макет, верстка:** Александр ГОРБАЧЕВ, Юрий ШВЕЦ
**Фото:** Миляуша ГАЗИМОВА, Римма НУРЕТДИНОВА
**Корректоры:** Миляуша ГАЗИМОВА, Зоя НУРТДИНОВА

**Адрес редакции:**
443087, г. Самара, пр.Кирова, 206
**Телефоны редакции:** (846) 212-06-45
**Электронная почта:**
samartatarlary@bk.ru
**Журнал отпечатан в типографии «Книга»**, г. Самара, ул. Песчаная, 1, офис 404 А
**Тел.** (846) 267-36-82

Журнал «Самар татарлары» («Самарские татары»), № 4(5) октябрь/декабрь 2013 г.
**Учредитель:** НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области»
Журнал зарегистрирован Федеральной службой по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций. Свидетельство о регистрации СМИ: ПИ №ТУ63 – 00628 от 15.10.2013 г.
Дата выхода 23 декабря
Тираж 1790 экз. Цена договорная
6+

Использованы материалы Интернет-сайтов: **www.samddn.ru, www.biznesonline.ru**

# РУСТАМА МИННИХАНОВА ПРИЗНАЛИ САМЫМ ЭФФЕКТИВНЫМ ПРАВИТЕЛЕМ

**Агентство политических и экономических коммуникаций (АПЭК) во главе с Дмитрием Орловым и Лаборатория региональных политических исследований НИУ «Высшая школа экономики» (ВШЭ) разработали первый ежегодный рейтинг эффективности управления в субъектах РФ. В итоговом рейтинге первым оказался президент Татарстана Рустам Минниханов. Самым эффективным политическим управленцем авторы доклада сочли главу Чечни Рамзана Кадырова.**



Рейтинг рассчитывался на основе экспертных оценок и статистических данных. Губернаторов оценивали по трем направлениям — политико-управленческому, социальному и финансово-экономическому.

Первое место в рейтинге эффективности занял Рустам Минниханов, возглавляющий Татарстан с 2010 года. На второй строчке мэр Москвы Сергей Собянин, переизбравшийся в сентябре. Далее идут губернаторы Кузбасса и Самарской области Аман Тулеев и Николай Меркушкин. Глава Чечни Рамзан Кадыров замкнул пятерку. Вслед за ним — губернатор Подмосковья Андрей Воробьев.

# ВЕЛИКАЯ КНЯГИНЯ МАРИЯ РОМАНОВА ВРУЧИЛА МУФТИЮ МЕДАЛЬ



**В здании правительства Самарской области состоялась официальная встреча с главой императорского дома Романовых княгиней Марией Владимировной.**

Участниками встречи стали митрополит Самарский и Сызранский Сергий, председатель Регионального духовного управления мусульман **Талип-хазрат Яруллин**, а также руководители структурных подразделений областного правительства, предводитель губернского дворянского собрания **Александр Чухонкин** и председатель облправительства **Александр Нефедов.**

Во время встречи с руководством региона великая княгиня интересовалась многими аспектами жизни губернии: экономическим развитием, транспортной доступностью, авиасообщением, строительством и подготовкой к чемпионату мира по футболу 2018 года. Особенно главу императорского дома волновали вопросы поддержки молодых семей, патриотического и религиозного воспитания, соцзащиты детей-сирот.

В завершение встречи княгиня вручила митрополиту Сергию, муфтию Яруллину, Александру Нефедову, Юрию Иванову, Ольге Рыбаковой и другим официальным лицам императорские медали «Юбилей Всенародного подвига 1613-2013» и «В память 400-летия Дома Романовых».

# ПРОШЛО ПЕРВОЕ СОВМЕСТНОЕ ЗАСЕДАНИЕ РЕДСОВЕТА И РЕДКОЛЛЕГИИ МЕДИА-ПОРТАЛА И ЖУРНАЛА «САМАР ТАТАРЛАРЫ» («САМАРСКИЕ ТАТАРЫ»)

**В Доме дружбы народов Самарской области прошло первое совместное заседание редакционного совета и редакционной коллегии медиа-портала и журнала «Самар татарлары» («Самарские татары»).**

Редакционный совет и редакционная коллегия являются совещательными органами, определяющими общую идеологическую линию, стратегические направления портала и журнала, осуществляющими рассмотрение вопросов, связанных с поддержкой, сопровождением и информационным наполнением интернет-сайта и печатного издания, а также и формированием общих требований, предъявляемых к информационному наполнению данных СМИ.

Редакционный совет медиа-портала и журнала «Самар татарлары» («Самарские татары») будет возглавлять учредитель – президент СОТО «Туган тел» **Ильяс Шакуров,** редакционную коллегию медиа-портала – главный редактор сайта Римма Нуретдинова, журнала — главный редактор печатного издания Данияр Сайфиев.

В редакционный совет согласились войти такие активные члены татарских общественных и мусульманских религиозных организаций, как Рафгат Набиуллович Аглиуллин, Шамиль Абульнагимович Ахмеров, Гумар Мулланурович Батршин, Ильгиз Исмаилович Колючев, Фархад Сабирзянович Махмутов, Азат Камилович Надиров, Ильгизар Ягфарович Сагдеев, Иршат Халилович Сафин, Наиля Фаридовна Тагирова, Рифгат Туктарович Хузин, Ильдар Гомерович Шакуров.

В редакционную коллегию вошли Наиль Данисович Биктаев, Эльмира Мугаммаровна Варфаламеева, Шамиль Хайдарович Галимов, Искандер Фуадович Мифтахов, Рустам Ильясович Файзуллов, Фарид Хамитович Ширизданов, Руслан Кабирович Шарипов, Жанна Валерьевна Султанова.

Участники заседания ознакомились с положениями о редакционном совете и коллегии интернет-портала и журнала, концепцией нового сайта, обсудили перспективу развития интернет-ресурса и журнала, внесли свои предложения по структуре и работе портала. Например, было предложено включить в структуру сайта новые тематические рубрики «Тарих/История», «Сәламәтлек/Здоровье», «Сорау-җавап/Вопрос-ответ» на религиозную тематику.

# МИНТИМЕР ШАЙМИЕВ ВСТРЕТИЛСЯ С ПРЕДСТАВИТЕЛЯМИ САМАРСКОГО ОБЛАСТНОГО ТАТАРСКОГО ОБЩЕСТВА «ТУГАН ТЕЛ»



**6 декабря в Казанском Кремле Государственный Советник Республики Татарстан, Председатель Попечительского Совета Фонда «Возрождение» Минтимер Шаймиев встретился с президентом Самарского областного татарского общества «Туган тел» Ильясом Шакуровым, членом совета общества, руководителем национально-культурной автономии татар Ривгатом Хузиным, председателем Попечительского совета культурно-исторического фонда «Булгарское наследие» Гумаром Батршиным.**

*www. prav.tatarstan.ru*

В начале встречи гости из Самары вручили Минтимеру Шаймиеву копию памятного знака «Крылатый барс», установленного фондом «Булгарское наследие» в 2012 году в селе Ширяево Самарской области, где находились южные рубежи древнего государства Волжская Булгария. Затем было представлено около двух десятков печатных изданий, вышедших в свет по инициативе и содействию общества «Туган тел», причем спонсорами выступили сами члены общества. Среди изданий – книги об истории татар Поволжья, русско-татарские разговорники, красочный двуязычный журнал «Самар татарлары», который начал выходить с декабря 2012 года.





Ильяс Шакуров ознакомил Минтимера Шаймиева с деятельностью общества «Туган тел», созданного в 1989 году. Общество и сегодня ведет большую работу по популяризации татарского языка и культуры. Ежегодно проводятся олимпиады по татарскому языку, конкурсы, снимаются документальные фильмы о жизни самарских татар, оказывается помощь по проведению национальных праздников в городах и селах, где проживают татары. Начал работу новый информационный медиа-портал «Самар татарлары». В 2012 году «Туган тел» принимал участие в организации и проведении V Всероссийского фестиваля татарского фольклора «Тугэрэк уен» в Самаре.



Во встрече были озвучены вопросы, стоящие перед татарским сообществом области, наиболее острыми из них являются необходимость открытия второй татарской школы в Самаре и сохранение начальных школ в селах с компактным проживанием татар, открытие FM станции на татарском языке.

В ходе встречи были обсуждены проблемы сохранения и развития татарского языка и культуры в многоязычной среде. «Эти проблемы стоят сегодня перед всеми национальностями мира, поэтому надо неустанно искать и находить новые пути и способы стимулирования изучения родного языка», – сказал Минтимер Шаймиев. По его мнению, основы родного языка должны интенсивно закладываться в дошкольный период и в начальной школе.

Минтимер Шаймиев высоко оценил успешную и активную деятельность общества «Туган тел», подчеркнув, что это результат развития самосознания татар, которое заметно повысилось за последние два десятка лет.

В завершение встречи Ильяс Шакуров пригласил Минтимера Шаймиева на празднование 25-летия общества «Туган тел», которое состоится в будущем году.

*фото Михаила Козловского*



# В КАЗАНИ ПРОШЛО ЗАСЕДАНИЕ КООРДИНАЦИОННОГО СОВЕТА ПО ДЕЛАМ СООТЕЧЕСТВЕННИКОВ ПРИ ПРЕЗИДЕНТЕ РТ

**В Госсовете РТ прошло заседание Координационного совета по делам соотечественников при Президенте Татарстана. Провел его председатель совета, глава татарстанского парламента Фарид Мухаметшин.**

*«Татар-информ»*

Открывая заседание, глава татарстанского парламента отметил, что со времени последнего заседания прошло немало времени, произошли определенные изменения. В Казани успешно прошла Универсиада, в которой приняли участие и соотечественники.

**Фарид Мухаметшин** особо подчеркнул, что самым популярным и ярким событием в культурной жизни наших соотечественников является Сабантуй. В 2013 году он отмечался в 55 регионах Российской Федерации и 23 зарубежных странах, состоялся в 2013 году и международный Сабантуй в Ленинградской области. По словам спикера Госсовета РТ, подготовка к этим праздникам 2014 года уже началась. «Наша общая задача – с большей ответственностью подойти к их организации, тем более Казань в 2014 году станет культурной столицей тюркского мира», — сказал он.

В Татарстане проводится большая работа по работе с соотечественниками. Фарид Мухаметшин отметил, что Президент Татарстана Рустам Минниханов в своих поездках всегда находит время для встреч с соотечественниками.

«Продолжается консолидация татарской общественности. В этом году в столице Евросоюза объявил о своем существовании Альянс татар Европы. Хорошую возможность объединению соотечественников представляют республиканские молодежные проекты, среди которых выделяется движение «Сэлэт», — сказал Председатель ГС РТ. Кроме того, он добавил, что в вопросах работы с соотечественниками стали эффективнее использоваться современные технологии. К примеру, создана online-школа дистанционного обучения татарскому языку «Ана теле», действует портал «Татар иле» и др.

«Это направление представляется весьма перспективным, требующим особых усилий в их реализации», — подчеркнул глава республиканского парламента.

На сегодняшнем заседании члены Координационного совета по делам соотечественников при Президенте РТ рассмотрели ряд вопросов. Первым вопросом обсуждения стал вопрос о республиканских мерах программно-целевого характера по поддержке соотечественников в соответствии со Стратегией государственной национальной политики РФ и новой редакцией Концепции государственной национальной политики в РТ от 26 июля 2013 года. С докладами на данную тему выступили председатель исполкома ВКТ Ринат Закиров, первый заместитель министра образования и науки РТ Данил Мустафин, министр культуры республики Айрат Сибагатуллин. Так, Р. Закиров подчеркнул, что работа с соотечественниками в республике вышла на системный уровень, в министерствах есть структуры, которые работают в этом направлении.

В своем выступлении Данил Мустафин сообщил, что в 26 субъектах РФ функционирует 1305 общеобразовательных организаций, в которых изучается татарский язык и литература или проводится обучение на татарском языке, отдельная работа ведется с воскресными школами. Только в этом году из резервного фонда Министерства образования и науки РТ по заявкам 15 субъектов было передано более 7 тысяч учебно-методической литературы на сумму более 1 млн. 700 тыс. рублей. Заявки еще 9 субъектов проходят обработку.

Министр культуры республики в свою очередь сообщил, что одна из задач Минкульта РТ — содействие удовлетворению духовных культурных потребностей. Ежегодно по линии министерства проводятся сотни мероприятий в регионах России и за ее пределами, сообщил он.

Вторым вопросом на заседании был рассмотрен вопрос о взаимодействии с организациями соотечественников и татарскими общинами в развитии торгово-экономического сотрудничества РТ. Заместитель Премьер-министра РТ – министр торговли и промышленности Равиль Зарипов напомнил о том, что работа с соотечественниками осуществляется через сеть представительств и торговых домов РТ. В настоящее время за пределами республики действуют 21 представительство, 14 из которых зарубежных. Наиболее активными он назвал представительства в Турции, Франции, Чешской Республике и др.

Фарид Мухаметшин обратился к министру с просьбой большее внимание обратить на работу с соотечественниками и представительствами в регионах России.

***Киләсе елда Самар өлкә "Туган тел" татар җәмгыятенең оештырылуына егерме биш ел тула. Ул Россия күләмендә иң өлкән милли-мәдәни берләшмәләрнең берсе булып санала. Соңгы сайлауларда аның җитәкчелегенә яңа кешеләр килде һәм менә икенче ел инде оешма белән Самарның "Ипозембанк"ы директорлар советы рәисе, икътисади фәннәр докторы, профессор Ильяс Шәкүров җитәкчелек итә, башкарма директоры вазифаларын Данияр Сәйфиев башкара. Бу егетләр җитәкчелегендә иҗтимагый эшләрнең җанлануы күзәтелә. Күптән түгел генә оешманың өлкә Халыклар дуслыгы йортында узган хисап җыелышында да бу аермачык күренде.***

***Рәфыйк НУРИСЛАМОВ***

***Әнәс МИНГАЛИЕВ фотосурәте. "Бердәмлек"***




# "Туган тел" һәрвакыт берләштерүчебез булсын иде

Бүгенге көндә оешманың 117 әгъзасы булса, җыелышта әле тагын 26 кешенең гаризасы тикшерелеп, аларның барысы да өлкә "Туган тел" татар җәмгыятенә әгъза итеп кабул ителде. Араларында күбрәк яшьләр. Бу, әлбәттә, яхшы күренеш.

Җыелышта җәмгыятьнең советы составына да яңа әгъзалар өстәлде. Шулар арасында - Резеда Алешина, Линар Абсаттаров, Римма Нуретдинова, Искәндәр Мифтахов, Шамил Әхмәров - барысы да җәмгыять тормышында актив катнашучылар.

Оешманың президенты Ильяс Шәкүров үзенең хисап чыгышында соңгы вакытларда эшләнгән эшләр турында сөйләп үтте. Өлкәнең башка татар милли-мәдәни берләшмәләре белән берлектә өлкә "Туган тел" җәмгыяте инде күптән гадәткә кереп киткән Нәүрүз, Сабан туе кебек бәйрәмнәребезне үткәрүдә катнашып кына калмый, күп кенә яңа чаралар уздыруга да игътибар итә башлады. Мәсәлән, "Туган тел" оешмасы өлкәбездә Бөтенроссия күләмендә "Түгәрәк уен" фольклор фестивален үткәрүгә зур өлеш кертте. Аның тарафыннан татар балалары арасында татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадалар, шигырь уку, җыр бәйгеләре, төрле күргәзмәләр оештырылып тора. Татар телен яхшы итеп үзләштергән мәктәп укучыларына, урта һәм югары уку йортлары студентларына акчалата грантлар бирү дә каралган.

2012 елның декабрендә "Туган тел" җәмгыяте инициативасы буенча өлкәбездә татар һәм рус телендә төсле калын "Самар татарлары" журналы нәшер ителә башлады. Һәр квартал саен дөнья күрүче бу басманың 2013 ел ахырында бишенче саны укучыларга килеп ирешәчәк. Киләсе елдан аны өйгә дә яздырып алып булачак.

Өлкә "Туган тел" оешмасының, аның президенты Ильяс Шәкүровның тырышлыгы белән "Самар татарлары" дип аталган берләштерелгән интернет-портал эшли башлавы да куанычлы күренеш, әлбәттә.

Ильяс Гомәр улы киләсе елга билгеләнгән планнарга тукталып:

- "Туган тел" оешмасына һәм башка татар милли-мәдәни берләшмәләргә татарларыбызны күбрәк җәлеп итү өстендә эшләргә кирәк. Актив әгъзаларыбыз булмаса, без бернәрсә дә майтара алмаячакбыз. Ә иң зур максатыбыз - татар халкыбызны саклап калу, туган телебезне, мәдәниятебезне, сәнгатебезне үстерү, - дип белдерде оешма президенты. - Моның өчен безгә эш алымнарыбызны үзгәртергә, төрле секцияләр оештырып, нәкъ шулар ярдәмендә кабул ителгән планнарыбызны тормышка ашырырга кирәк.

Җыелышта чыгыш ясаучыларның һәрберсе "Туган тел"нең яңа җитәкчелегенең, бигрәк тә аның президенты Ильяс Гомәр улы Шәкүровның, эшчәнлегенә уңай бәя биреп, киләчәктә дә аны шулай дәвам итәргә кирәклеге турында әйтте. Оешманың актив әгъзаларының берсе Шәүкәт Хәйбуллов элеккеге елларда актив катнашкан кешеләрне онытмаска, аларның хәлен белеп, ярдәм итеп торырга чакырды. Ә Мансур Ямалетдинов, 1989 елда өлкә "Туган тел" җәмгыяте үткәргән дини-тарихи конференциянең дәвамы итеп, 25 еллык юбилейга да галимнәребез, җәмәгать эшлеклеләребез катнашында зур конференция уздыру кирәклеге турында әйтте.

Шамил Әхмәров, Шамил Баһаутдинов, Румил Шәрипов, Азат Надиров, Рифкать Хуҗин һәм башкалар эшләнгән эшләр белән беррәттән әле эшләнәчәкләренең дә байтак булуын, моның өчен ешрак җыелышып сөйләшергә кирәклеге турында да әйтеп үттеләр. Румил Шәрипов, мәсәлән, яшьләргә игътибарны арттырырга чакырды.

Чыгыш ясаучылар татар телебез өчен борчылып, үзләрен татар активистлары итеп санаучыларның да кайберләренең телебезне өйрәнергә теләмәүләре, балаларын да, оныкларын да өйрәтмәүләре, татарча газета-журналларыбызны укымаулары, татар концертларына йөрмәүләре турында сөйләделәр. "Туган тел" татар оешмасы һәрвакыт безгә үрнәк күрсәтергә, оештыручыбыз һәм берләштерүчебез булырга тиеш», - диделәр алар.

# АВТОНОМИЯДӘ – ЯҢА РӘИС

## САМАР ӨЛКӘ ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ ЙОРТЫНДА ӨЛКӘ ТАТАР АВТОНОМИЯСЕНЕҢ ИСӘП-ХИСАП ҖЫЕЛЫШЫ УЗДЫРЫЛДЫ

***29 октябрьдә Самар өлкәсенең татар милли-мәдәни автономиясе оештырылып эшли башлавына дүрт ел тулган икән инде. Һәр ел ахырында аның рәисе Минәхмәт Хәлиуллов автономия әгъзаларының гомум җыелышын җыеп, хисап тота.***

**Эльмира ШӘВӘЛИЕВА.** «Бердәмлек», **Миләүшә ГАЗИМОВА** фотосурәтләре.

Президиумга “Ялкынлы яшьлек” ансамбле җитәкчесе Илгиз Колючевны, Похвистнево районының “Туган тел” оешмасы рәисе Расих Латыйповны, өлкә автономиясенең башкарма комитеты рәисе Минәхмәт Хәлиулловны, оешманың директоры Равил Галимовны һәм “Сәлам” газетасында җаваплы сәркатип вазифаларын башкаручы Шамил Баһаутдиновны сайлаганнан соң, сүз Минәхмәт Хәлиулловка бирелде. Ул шушы дүрт елда оешманың Бөтендөнья татар конгрессы һәм Федераль милли-мәдәни автономиясенең башкарма комитеты белән даими хезмәттәшлек булдыруы турында сөйләде, быелгы күләмле чараларга — 25нче өлкә һәм Камышлыда узган I өлкә авыллары Сабан туе бәйрәмнәренә тукталып үтте, шулай ук Самарның “Яктылык” татар мәктәбендә эшләп килүче татар көрәше секциясе эшенә һәм өлкә автономиясе командасының “Дуслык” кубогына уздырылган мини-футбол ярышларында ике ел рәттән беренчелекне бирмәүләренә игътибарыбызны җәлеп итте. Чыгышында башкарма комитет рәисе Хәлиуллов өлкә татар матбугаты проблемаларына да тукталып, “Азан” газетасының ябылуы уңаеннан көрсенде, ә “Бердәмлек”кә өлкә хөкүмәтеннән киләсе елга күбрәк акча алырга булышырга вәгъдә итте. Шулай ук ул региональ Дини нәзарәтенең “Сәлам” газетасына өлкә автономиясе дә оештыручы булып теркәлгәч, аңа яңа сулыш керүе, бу газетаның киләчәккә перспективалары зур булуы турында сөйләде.

Минәхмәт Мидхәт улы чыгышының ахырында үзен башкарма комитет рәисе







вазифаларыннан азат итүне соралды һәм бу адымын шәһәр Думасында депутат вазифаларын башкару күп вакытын алу белән аңлатты.

Залдагы халык аның хисап докладын кабул итеп, өлкә автономия рәисе



вазифасына тәкъдим ителгән Әнвәр Гыйрман улы Горлановның кандидатурасын раслады. Әнвәр Гыйрман улы әлегә кадәр иҗтимагый татар оешмаларында эшләмәсә дә, мәчет эшләрендә бик актив катнаша һәм иҗтимагый оешмада эшләргә дә теләге зур, диделәр аны тәкъдим итүчеләр. Яңа җитәкчегә бу вәзгыяткә ияләшү җиңелрәк булсын өчен, аңа ярдәмгә оешманың башкарма директоры итеп 25 ел буе татар мохитында эшләгән Шамил Галимовны билгеләделәр.

Төп доклад буенча чыгыш ясаучылар өлкә милли-мәдәни автономиясенең башкарма комитеты эшчәнлеге буенча төрле фикерләр әйттеләр. Мәсәлән, Похвистнево районының “Туган тел” татар оешмасы рәисе Расих Латыйпов киләчәк тормышыбызны күзаллап, өлкә автономиясенә үз исемен аклар өчен, өлкәбездәге 28 татар авылын берләштерүче, аларның милли, мәдәни һәм мәгариф системаларындагы мәнфәгатьләрен кайгыртучы була башларга киңәш итте.

Гомумән, берләшү, бердәм булу кирәклеге идеясе күптән инде һавада очып йөрсә дә, әлегә Самар татарларының берләшүе күренми. Бәлки, бу мәсьәләне автономиянең яңа рәисе хәл итә алыр?!

***Самар шәһәрендә уңышлы эшләп килүче “Яктылык” мәктәбе быел Ватаныбыз Россия күләмендә дан казанды. Мәктәп мөдире Рәфгат улы Радик Газизов Россия күләмендә “Ел директоры” исеменә лаек булды, ә “Яктылык” мәктәбе шулай ук Россия күләмендә “Йөз иң яхшы мәктәп” исемлегенә кертелде.***

*Шамил Баһаутдин*




# РОССИЯНЕҢ “ЕЛ ДИРЕКТОРЫ”

Мондый олуг дәрәҗәгә ирешү барлык укытучыларның, ата-аналарның һәм балаларның куйган җимешләре. Мәктәпкә матди ярдәм күрсәткән эшбатырларыбызның өлеше дә зурдин.

Радик Газизов җитәкләгән уку йорты – ул аның туган йорты. Биредә ул педагогик чыныкмаларны мәктәпнең беренче мөдире Харидә ханым Дашкина кулы астында узды. Тәҗрибәле педагог, Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган укытучысы, “Туган тел” җәмгыятенең актив әгъзасы, сокланырлык асыл татарыбыз Самар татар тарихына татар мәктәбе ачу белән кереп, олуг дәрәҗәгә ирешә.

Харидә ханым үзе артыннан берьюлы ике шәхесне директор биеклегендә эшләргә әзерләп калдырды. Дания ханым Әбдерәхимованы һәм Радик Газизовны.

Дания ханым “Яктылык” мәктәбенең яңа бинасын салганда көнне-төнгә ялгап эшләде. Шул ук вакытта мәктәптә булдыклы кадрлар туплап, уку сыйфатын яңа үрләргә күтәрде.

Радик Газизов Дания ханым белән берлектә хезмәт итте.

Самар шәһәр департаментында, Самар өлкә мәгариф министрлыкларында җаваплы урыннарда эшләде. Менә шул административ хезмәтләрнең баскычларында тәҗрибә туплап, милли мәктәбебезне җитәкләүне үз җилкәсенә алды.

Бүгенге көндә Радик әфәнде яңа үрләргә ирешә. Мәгариф тармагында уңышны Бердәм дәүләт имтиханнарында җыйган баллар буенча бәялиләр. “Яктылык”та - иң югары баллар.



**Школа «Яктылык» признана лауреатом конкурса «100 лучших школ России»**

**Независимый общественный Совет, Оргкомитет конкурса и Международная академия качества и маркетинга сообщают, что муниципальное бюджетное учреждение средняя общеобразовательная школа «Яктылык» с углубленным изучением отдельных предметов городского округа Самара признано лауреатом конкурса «100 лучших школ России», а директор школы Р.Р. Газизов отмечен почетным знаком «Директор года».**

Тәрбия эшләре классик тәрбия ысулларына һәм татар халык педагогикасына нигезләнгән. Моны без барчабыз да күреп яшибез, моны мәгариф тармагындагы белгечләр таныйлар. Шәһәрнең бер җитәкчесе авызыннан мин мондый фикер ишеткән кеше: “Яктылык”та штучный товар!” Бу - зур бәя.

Бу һәр баланың үзенчәлегенә карап, гаилә тәрбиясе бирү, дигән сүз. Бу - чын педагоглар эше!

Бу алдагы мөдирләр – Харидә Дашкина, Дания Әбдерәхимова куйган хезмәтләрнең һәм бүгенге мәктәп мөдире Радик әфәнде Газизовның җиң сызганып эшләү җимешләре.

Шатланабыз.

Горурланабыз.

Кайнар тәбрикләүләребез.

Бу “Туган тел” исемле Самар өлкә татар җәмгыятенең 25 ел буена куйган хезмәтенә югары бәя бирү,

Самар шәһәренең татар милли-мәдәни мохтариятенең тырышлыгын тану,

Самар өлкә татар милли-мәдәни мохтариятенең мәктәп укучыларына спорт өлкәсендә зур ярдәм күрсәтүләрнең асыл нәтиҗәсе.



# ОРГАНИЗОВАНА РАБОЧАЯ ГРУППА ПО СОЗДАНИЮ ДОМА-МУЗЕЯ ГАКИЛЯ САГИРОВА

***Состоялась деловая поездка представителей татарской общественности Самары в районный центр Кошки. Ее цель — обсуждение вопроса по созданию дома-музея человека трагической и удивительной судьбы, всей своей жизнью продемонстрировавшего несгибаемость человеческого духа, поэта и художника Гакиля Сагирова в селе Старое Фейзуллово Кошкинского района.***

**samtatnews.ru**

В состав делегации вошли президент областного общества «Туган тел» И.Г. Шакуров, редактор татарской областной газеты «Бердэмлек» Р.Н. Аглиуллин, исполнительный директор Самарской областной татарской национально-культурной автономии Ш.Х. Галимов и представитель татарской НКА города Самара Т.Б. Абузяров.



Вопрос увековечивания памяти Гакиля Сагирова был поднят несколько лет назад, спустя два года после смерти известного татарского поэта и художника татарское сообщество Самарской области и участники церемонии открытия памятного камня на могиле поэта обратились к правительству Самарской, Ульяновской областей и Республики Татарстан.

Инициатором создания дома-музея стал редактор газеты «Бердэмлек» Рафкат Аглиуллин, сделавший много для популяризации героического примера Г. Сагирова, а в последние два десятилетия, уже через газету «Бердэмлек» – для пропаганды его разностороннего таланта и творчества. Благодаря его усилиям министерство культуры Самарской области выразило готовность профинансировать этот проект в рамках областной целевой программы, идею поддержали также руководители Кошкинского района. Посильный вклад готовы внести также Республика Татарстан и Ульяновская область. И самое главное, планом создания дома-музея славного сына татарского народа и всей нашей страны прониклись и руководители национальных общественных организаций.

Таким образом, началась непосредственная работа по претворению идеи создания дома-музея Гакиля Сагирова в жизнь. Прошедшую 15 ноября встречу в администрации Кошкинского района можно назвать первым шагом в конкретной работе. В ней приняли участие и глава Кошкинского района В.Н. Титов, его заместитель по социальным вопросам Ю.Д. Макаров, начальник управления культуры В.М. Гусаров и глава сельского поселения Р.Х. Минибаев.

Очерчены контуры будущей работы, создана рабочая группа, в нее вошли люди, которые могут конкретной работой помочь созданию дома-музея Гакиля Сагирова.

Дом поэта, где он прожил большую часть своей жизни, требует большой реставрации. Построенные из березовых бревен в 1934 году, сегодня он полностью обветшал. Рекомендуется его разобрать и построить из откалиброванных сосновых бревен на бетонном фундаменте, сохранив размеры дома. Крышу покрыть железом по современным стандартам.

29 июля 2009 года не стало творца и гения современности **Гакиля Шарифулловича Сагирова.**

Сын фронтовика, погибшего на войне, волею судьбы оставшийся без движения, он нашел в себе силы и научился писать и рисовать, зажав карандаш зубами. Благодаря упорству и таланту он стал настоящим поэтом и художником.



У члена Союза писателей Республики Татарстан, поэта, художника и журналиста Гакиля Сагирова семь сборников и рисунков, выпущенных в книжных издательствах Казани, Самары, Димитровграда и Ульяновска.

На разных языках разные люди, по сути, в один голос оценивают феномен Сагирова – его жизнеутверждающее творчество, пример человеческой стойкости и мужества как общенациональное наше богатство, как бесценное достояние разноязычного российского народа.

Подтверждают такую оценку и давно заслуженные художником награды. На Самарском Сабантуе он удостоен звания Человек года – за большой вклад в развитие национальной культуры, языка и за духовное объединение. Он лауреат Самарской областной общественно значимой Акции «Благородство», международной премии «Филантроп», премии имени Гаяза Исхаки Республики Татарстан и многих других литературных премий.



# ТАТАР МИЛЛӘТЕН ҖЫР ДА САКЛЫЙ

***Һәр көзне Самарның "Ялкынлы яшьлек" исемле җыр, бию, шигърият ансамбле өр-яңа программасын күрсәтә. Кырыкка якын артист катнашкан музыкаль программа гаҗәеп зур панораманы хәтерләтә.***

*Шамил БАҺАУТДИН*
*Диләрә САБИРҖАНОВА фотосурәтләре*



Тамашаны кызлар заманча бию белән башлап, үзенә күрә гаҗәеп бер күтәренкелек тудырып, залдагы тамашачыларны рухландырып җибәрделәр. Шул ук вакытта бу номерга тирән фәлсәфи мәгънә дә салынган иде – коллективның исемен аклау: "Без яшь. Без дәртле. Без 43 ел элек сайлаган кыйблабыздан тайпылмыйбыз!"

"Ялкынлы яшьлек" Самарның иҗади сәләте булган татар егетләрен һәм кызларын үз бођрасына алып, ул сәләтне үстереп, иҗат казанында кайнатып, асыл таштай ялтыратырга остарган татар сәнгатенең бер лабораториясе.



"Ялкынлы яшьлек" - көчле рухи бердәмлек биеклегенә менгезүче бер баскыч та.

"Ялкынлы яшьлек" - төрле гаиләдә, төрле интеллектуал биеклектә формалашкан егет-кызларны бер ноктага җыеп, милләт мәнфәгатьләрен кайгыртучы иҗат чишмәсе.

"Ялкынлы яшьлек" миллионлы шәһәрдә үзенә бер кечкенә генә милләтебезне саклаучы татар бистәсен хәтерләтә!

Ансамбль үзенең иҗади биографиясен булдырганда, бер генә максатны куеп хезмәт итте. Ул – татар яшьләрен сәхнәгә күтәрү. Ә алар, үзләре дә



сизмәстән, олуг мәнфәгатьләрне җилкәләренә сала бардылар. Ул мәнфәгатьнең исеме – татарны милләт буларак саклау.

Бүген без бер нәрсәгә инандык. Милләтне җыр да саклый. Милләтне аның биюе дә саклый. Милләтне аның шигыре дә саклый. Әле бит Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллалаһү галәйһи вәссәләм әйтеп калдырган: “Шигырьдә хикмәт бар”, дип.

Ансамбльнең 800нче концертындагы шигърият күз темасына багышланган иде. Ә инде арт пәрдәдә татарга гына хас казлар, каз өмәсенең татар туена барып тоташуын тасвирлаган тәэсирле һәм ышандырырлык кинокадрлар поэзияне тагын да көчәйтте.



Аера да алмыйсың, әллә татар тормышы үзе шундый сәнгатиме, әллә сәнгать татар яшәешенә шундый тәэсир иткәнме?

Татар эстрадасында ялтыраган йолдызлар бар. Алар вакыт-вакыт башкаларны күләгәдә дә калдыралар. ”Ялкынлы яшьлек” артистлары арасында да йолдызлар бар һәм шул ук вакытта йолдызлар арасы буш түгел. Бу йолдыз янудан туктаса, артта бушлык кала, дигән куркыныч юк! Бу - иң мөһиме.

Тагын бер үзенчәлек. Ансамбльдәге җырчылар төрле юнәлештә иҗат итәләр һәм беркайчан да бер-берсен кабатламыйлар. Татар халкының җырларын балачактан йөрәк түренә салган, һәр күзәнәгенә сеңдергән Искәндәр Әхмәтовны бүгенге көндә коллективның “Дәү этисе”, дип әйтәсе килә. Җырлаганда ару-талуны белмәс. Ул - татар рухын яңартып торучы мәңгелек егетебез.

Динебез Исламның атаклы галиме, хәзрәтебез Шиһабетдин Мәрҗәни: “Милләтне кием дә саклый”, дип язып калдырган. Искәндәр Әхмәтов татар киемендә җырлый. Бу бик мөһим нәрсә. Тамашага килгән балалар киемебезне дә күреп китәләр.

Ринат Азизовка Ходай Тәгалә сәхнә нурын бүләк иткән. Яшьлек өлгесе. Буй. Сын. Хәрәкәтчәнлек. Урынлы елмаю. Заман ирләренә генә хас кием зәвыгы үзендә. Кояз. Заман эстрадасына татар моңын кундыра белә.

Татарның бишеге авыл, дибез. Моңа һич тә шик юк.

Татарны “изм”нар үтерә алмады. Социализмда да исән калдык, коммунизм сазлыгына да батмадык, капитализм вәхшилегенә чыдадык. Инде глобализациясен генә таптыйсы калды. Ә ышаныч бар. Һичшиксез җиңәбез, Аллаһы теләсә. Чөнки, заман шаукымына бирелмичә, шәһәр шартларында Илдар Иваев кебек татар моңыннан үрелгән егетләребез бар! Илдар мәшһүрләр күтәрә алган “Тәфтиләү”не дә башкара алырлык җырчы.

Фәнил Зыятдинов – үзенчәлекле артист. Табигать бүләк иткән тавыш. Сәхнәдә ирләр образын саклаучы.

Җырчылыр арасында Әлфия Йосыпова үзенең җырлары белән дә, сөйкемле сүяге белән дә тамашачы каршында мәхәббәт казанган ханым. Аның инде үзенең тыңлаучысы бар. Халкыбызның күңеленә ята торган көйләрне сайлый белә һәм кешеләрнең йөрәкләрен тибрәндерерлек сәләткә ия.

800нче концерт тарихка керде. Нәрсәсе белән яңалык өстәде соң ансамбль?!

Әлбәттә инде, Алсу Галимова белән. Зифа буйлы, күлмәге йөзектән чыгардай, югары һөнәрмәндлек, чиксез тавыш мөмкинлекләре. Бүгенге көндә яшьләр арасында Рөстәм Яхин романсларын җиренә җиткезеп башкаручылар бик сирәк. Шул сирәкләрнең берсе – ул Алсу. Алсу Галимова 800нче концертның иң зур табышы дисәк тә, ялгышмабыз кебек.

Әлфия Гыйниятуллинаның пианинода уйнаулары “Ялкынлы яшьлек” ансамбленең югары музыкаль зәвыгы булганга ишарә.

Биючеләр төркеменең сылу кызларына тик мәдхия генә җырларга кала.

Тамашаны алып баручы Римма Гыйбадуллина үз хезмәтенең остасы. Чибәр. Дикциясе кирәгенчә.

Ә инде Линар Нуретдинов турында барлык яхшы сыйфатларны санап узарга була. Татар теленең үзенчәлекләрен, сөйләм нечкәлекләрен яхшы үзләштергән. Татар теленең төпсез чишмәсе әйтерсең лә Линарның тумыштан бер әгъзасына әйләнгән. Ана теле Линарга ана сөте белән сеңдерелгән. Күренеп тора: Линар татар телен сәхнәдә генә түгел, яшәештә дә куллана. Ул аның канына сеңгән. Шуңа да Линарның сәхнәгә чыгып, шигырь сөйләвен үзенә бер моңлы җыр тыңлагандай кабул итәсең. Күңелләргә тынычлык кереп урнаша. Милләтнең киләчәге бар икән дисең! Линарның тел осталыгы драма артисты биеклегендә.

43 ел буена куйган хезмәт үсештә. "Ялкынлы яшьлек" татарлыкны саклауда беренче сафта бара. Моны Казаннан килгән мәртәбәле кунаклар раслады. Алар арасында агалы-энеле академиклар Индус һәм Энгел Таһировлар һәм Русия Дәүләт Думасы депутаты, федераль татар мили-мәдәни мохтарияте рәисе Илдар Гыйлметдинов бар иде. Хөрмәтле кунаклар "Ялкынлы яшьлек"кә, татар милли культурасын үстерүдә зур өлеш керткәне өчен, мохтариятнең һәм ЮНЕСКОның дипломнарын һәм Мактаунамәләрен, ә ансамбльнең җитәкчесе Илгиз Кәлучкә алтын медаль тапшырдылар. Сәхнәдән милләтебез язмышы турында тирән эчтәлекле сүзләр яңгырады. Академик Индус Таһиров үзенең чыгышын: "Татар милләте мәңге яшәр, Аллаһы теләсә!" - дип тәмамлады. Залдагылар дөбердәтеп кул чаптылар.





Коллектив бик зур мәгънәгә ия бүләкләр алды. Төшенкелеккә бирелергә урын юк.

Буыннарыгыз талмасын, канатларыгыз каерылмасын, Ходай Тәгалә үзегезне нахак сүзләрдән сакласын. Кыргый капитализм вәхшилекләрен җиңеп чыктыгыз. Алдагы кыенлыкларны җиңәргә дә насыйп булсын.



***В Самаре состоялся ежегодный областной татарский праздник «Сэмбелэ». По данным министерства сельского хозяйства и продовольствия Самарской области, на этот день в регионе намолочено 1464 тысячи тонн зерна при средней урожайности 16,5 центнера с гектара (год назад этот показатель был на четверть ниже), что позволяет полностью обеспечить регион продовольственным, семенным и фуражным зерном. Вы спросите, какое отношение имеют эти факты к татарскому празднику? Самое прямое. Сэмбелэ всегда был символом осени, окончания полевой страды. Урожай собран, добросовестный хозяин готов к зиме – почему бы ни повеселиться,ни отметить окончание уборки урожая, ни поблагодарить Всевышнего за всё, что он даёт людям...***

*Светлана ИШИНА*

# ТАТАРСКИЙ «СЭМБЕЛЭ»:

## новые традиции старого праздника

Корни праздника уходят в древнюю историю, а вот наши дни он был возрождён не так давно, в 2000 году. Именно тогда в Самаре прошёл первый Сэмбелэ. И с тех пор каждый год, в октябре, татарские общественные организации собирают в областном центре своих соотечественников – лучших тружеников сельского хозяйства, кого в советские годы назвали бы передовиками производства,– чествуют их, вручают подарки.



Причём праздник как-то сам собой перестал быть чисто татарским – на него приезжают представители разных национальностей, и это никого не смущает, наоборот – только радует. Со сцены участников торжества приветствуют на двух языках – татарском и русском. А концертные программы одинаково интересны всем – и татарам, и не татарам.

Вот и на этот раз в ДК Литвинова собралось много гостей. Главными «виновниками торжества» стали простые люди, величайшие труженики, о каждом из которых можноне только статью – целую книгу написать. Механизаторы, водители, индивидуальные предприниматели, руководители крестьянских фермерских хозяйств из КамышлинскогоПохвистневского, Елховского, Шенталинского и самого урожайного – Кошкинского района,на его полях показатель урожайности самый высокий в области – 26,7 центнера с гектара!

Поздравляя передовиков, заместитель министра сельского хозяйства и продовольствия – руководитель департамента экономики АПК Роман Владимирович Некрасов, говорил о том,что именно руками этих людей сегодня создаётся продовольственная безопасность региона, а сам Сэмбелэ символизирует венец огромной, трудной и вместе с тем – благороднейшей работы на земле, ибо есть ли какое-то более мирное занятие, чем растить хлеб, разводить скот...

По приглашению ведущих на сцену поднялись главные участники праздника, среди них два фермера – победители 15-й Российской агропромышленной выставки «Золотая осень», которая с 9 по 15 октября проходила в Москве,во Всероссийском выставочном центре, – главы крестьянских фермерских хозяйств Минугали Самигуллович Гайсаровиз Похвистневского района и Ильшат Жаватович Каюмов из Камышлинского района. Р. В. Некрасов вручил им федеральные награды – медали выставки «Золотая осень» и ценные подарки, а остальным одиннадцати передовикам передал благодарственные письма министра сельского хозяйства и продовольствия Самарской области В. В. Альтергота.

Поздравили сельских тружеников и руководители татарских автономий – Минахмет Мидехатович Халиуллов и РивгатТуктарович Хузин, муфтий Самарской области,




председатель регионального духовного управления мусульман Талип-хазрат Яруллин.

От имени Губернатора Самарской области Н. И. Меркушкина участников праздника приветствовала консультант управления национальной и конфессиональной политики Вера Ивановна Алексеева. Она пожелала труженикам сили желания так же плодотворно трудиться на благо всех жителей губернии, отметив, что этот праздник особый – добрый, красивый. Он важен не только тем, что сохраняются традиции и обычаи татарского народа, но и тем, что повышается престиж аграрных профессий, это праздник связывает людей разных поколений, сельских жителей и горожан...

Вместе с аграриями из Камышлинского района приехал глава района Рафаэль Камилович Багаутдинов – он вручил благодарственные письма руководителями двух татарских автономий – областной и городской – за их большую работу по сохранению традиций и обычаев татарского народа.

Всем передовикам вручили дорогие (и главное – полезные!) подарки, но главным подарком для них, не сравнимым ни счем, наверное, всё-таки были добрые слова, которые в этот день щедро произносились со сцены. Ведь это так важно – знать, что твоя работа нужна, что её ценят на самом высоком уровне...

Программу праздника продолжило прекрасное выступление народного ансамбля из села Старое Ермаково «Ак каен», каждый номер которого зрители принимали бурными овациями, а также спектакль Камышлинского татарского народного театра «Четыре жениха для Диляфруз» по пьесе классика татарской драматургии Туфана Миннуллина.

Особой колорит празднику придали выставки – в фойе на праздничной площадке торговали блюдами национальной кухни, изделиями декоративно-прикладного искусства, на входе гостей встречали дети из татарских танцевальных коллективов, все в на-



циональных костюмах – красота такая, что глаз не отвести!

Официальная пропаганда настойчиво вбивала в сознание людей миф о якобы поголовной безграмотности татар в царской России. Миф оказался стойким, его отголоски порой раздаются и сейчас: «Вот мы, мол, научили вас читать и писать!» А на самом деле даже в самых глубинных татарских селеньях все (!) татарские мальчики и девочки с детства обучались чтению и письму, познавали основы своей веры. Известный этнограф К.Фукс в 1844 году писал: «Татарин, не умеющий читать и писать, презирается своими земляками и, как гражданин, не пользуется уважением других. По сему-то всякий отец старается, как можно раньше записать своих детей в училище, где они научились бы, по крайней мере, читать, писать и узнали начала своей религии… Этот народ более образованный, нежели некоторые, даже европейские». В подтверждение его слов приведу и высказывание его современника, исследователя М.Лаптева: «Вообще первая ступень образования – грамотность достаточно распространена между татарами, мало найдется даже женщин, которые бы не умели читать и писать».

Основанием для рассуждений о безграмотности татар могло служить то, что татарская письменность до революции была построена на основе арабской графики. Но ведь, следуя такой логике, надо приписать к «неграмотным» весь мир, который не пользуется кириллицей. А между тем, еще в 1802 году заработала первая татарская типография, основанная купцом Бурнашевым. Татарская издательская сеть расширялась из года в год. Увидели свет «Татарская грамматика» и «Хрестоматия» известного просветителя XIX века Ибрагима Халфина, выходили словари, литературные сочинения современников, учебники. На рубеже XIX – XX вв. стали издаваться газеты и журналы. С 1807-го по 1855 год только в Казани было издано 577 татарских книг на арабской графике тиражом 2400-4200 экз. каждая. И это были не только книги религиозно-духовного содержания, большую их часть составляла светская литература. Татарское население, татарские школы ежегодно получали десятки тысяч печатных книг.

Медресе, которые открывались практически при каждой мечети, в отличие от церковно-приходских школ, содержались ***исключительно*** на мирские деньги, не получая даже ломаного гроша из государственной казны.

Поворотным и поистине революционным в деле национального просвещения стали новометодные школы, у истоков создания которых стоял выдающийся татарский просветитель Исмаил Гаспринский. Новые школы не просто учили детей и юношество читать и писать, но уже давали достаточно широкое образование, приближенное к мировым стандартам. Национальная школа продолжала развиваться, как и прежде, опираясь лишь на внутренние ресурсы татарской общины, что вызывало серьезную озабоченность властей, которые всеми силами стремились не допустить единения тюркских народов, ограничить их доступ к общественной и политической жизни. На новометодные школы ополчилось реакционное мусульманское духовенство, обретя в этом деле союзников в лице православных церковников и представителей власти. Министерство просвещения изобрело «противовес»

новометодной татарской школе в виде русско-татарских и русско-башкирских школ. Это было слегка завуалированным продолжением государственной политики, направленной на русификацию наций, взамен полностью дискредитировавшей себя насильственной христианизации.

Была выдвинута и идея открытия школы для мусульман с помощью налогов с земств. По вопросу о помощи земства мнения разделились. Так, Ризаэдин Фахретдин поддержал решение о помощи земств, он писал что «нет преграды, чтобы брать помощь из казны земств для татарских национальных и религиозных школ, однако, возможность брать средства в необходимом количестве – это иллюзия». Выходившая в Петербурге татарская газета «Дума» отмечала, что «хотя казанские татары в земскую и городскую управу платят огромные налоги, за исключением миссионерских школ, на дело просвещения татар не расходуется ни ломаного гроша».

Русификация «инородцев» оставалась главной задачей православных миссионеров. Больше остальных преуспел в этом деле Н.И. Ильминский (1822 — 1891), черносотенный «миссионер», выработавший специальную систему национального угнетения и обрусительской политики среди колониальных народов царской России, в первую очередь среди народов Поволжья и Сибири, соратник и близкий друг Победоносцева, крайний монархист и реакционер. «Система» Ильминского



*Шигабутдин Марджани (1818-1889)*

заключалась в организованном насаждении христианства, крещении «инородцев», систематическом внедрении в колониях русского языка и великодержавной христианско-монархической идеологии, в создании специальных школ для крещеных «инородцев», откуда должны были выйти принадлежащие к коренному национальному населению кадры верных царю и России полупопов-полуучителей. (Источник: http://www.bonaen.ru/i/ilminskiy-nikolay-ivanovich).

Его верный ученик и последователь епископ Мамадышский Андрей (в миру князь А.А. Ухтомский), ведавший инородческими приходами и миссионерской деятельностью, 17 января 1908 года направил Петру Столыпину докладную записку, в которой с нескрываемой тревогой писал: «Завоевание



*Гаяз Исхаки (1887-1954)*

татарами-магометанами Казанского и всего Прикамского края происходит на наших глазах тихо, мирно, постепенно, но твердо и неуклонно».

В верхах быстро отреагировали на предостережение епископа. Столыпин выступил в Совете министров с докладом «О мерах противодействия панисламистскому и пантуранскому влиянию среди мусульманского населения». Затем последовало несколько «особых совещаний», направленных на широкомасштабное подавление национальной культуры и, в первую очередь, новометодных мектебов и медресе. Борьба с национальной школой, таким образом, была введена в ранг государственной политики.

Царское правительство старалось всячески пресечь культурные и духовные связи между различными тюркскими народами, тем самым ослабить их единение. Мусульмане же требовали



*Садри Максуди (1878-1957)*

свободы открытия общеобразовательных и духовных школ всех разрядов по программам, установленным самими мусульманами, со свободой преподавания на родном языке, с правом приглашения в качестве преподавателей и не российскоподданных.

В 1906 году состоялся 3-й Всероссийский мусульманский съезд, определивший концепцию реформы образования, предусматривающую автономию нации в делах просвещения. Предлагали открыть в каждом татарском селе начальные школы с преподаванием на родном языке. Депутат 2-й Государственной думы Садри Максуди выдвинул требования о том, что во всех школах, где учатся дети мусульман, их религия и родной язык должны преподаваться в обязательном порядке; в школах для мусульман преподавание всех предметов, кроме русского языка, должны вестись на родном языке учащихся.

Чтобы яснее представить отношение государства к так называемому «инородческому» образованию, стоит привести выдержки из выступления депутата Думы социал-демократа Г.А.Алексинского 22 марта 1907 года. ***«Мусульманские общества возбудили вопрос о том, чтобы государство давало им вспомоществование на устройство своих школ, на что один из крупных российских чиновников ответил в официальном документе: «Желание мусульманских обществ исходит из того соображения, что мусульмане несут те же самые государственные налоги, что и прочее население империи, и поэтому государственная касса должна уделять известные, необходимые средства***

***на образование мусульманского юношества; но в данном случае мусульмане заблуждаются, будто они вносят в государственную кассу сумму, равную пропорционально контингенту христианского населения. Мусульмане вследствие канонических предписаний не употребляют спиртных напитков, что, разумеется, ни один христианин не ставил и не поставит им в какой-нибудь моральный недочет. Тем не менее в общенародной экономии мусульманами сберегается до 70 000 000 р. Государственной кассе совершенно безразлично, вследствие каких побуждений плательщиков она недополучает тех или иных сумм. Государственной кассе лишь необходимо сообразовать свои платежи с суммами получений. Сообразуясь с такой необходимостью, государственная касса поступила бы в высшей мере неосторожно, если бы, недополучая с мусульманского населения 10000000 р., расходовала бы в то же время суммы, получаемыми с крестьянского населения на нужды мусульманства»...***

Государственные соображения, резюмирует Г.А.Алексинский, сводятся к следующему: ***«если ты пьешь много водки и приносишь государству доход, то ты вправе получить 7,3 к. на твою душу, на народное образование. Если же тебе Аллах и Коран воспрещают пить водку, то тогда уж не рассчитывай на субсидию государства на образование твоих детей».*** (Государственная Дума. Второй созыв. Стенографические отчеты. 1907 год. Сессия вторая. Т. 1. СПб., 1907. С.951- 952).

Глас вопиющего в пустыне! Государство не сменило и не собиралось менять свою политику по отношению образования мусульман России. Садри Максуди еще не раз поднимал вопросы инородческого просвещения. Приведем выдержки из его выступления в III-Думе 12 мая 1911 г.

***«...во всех сметах неземских губерний есть особый параграф расходов, озаглавленный «пособием церковно-приходским школам», между тем «...большинство неземских губерний, это – губернии инородческие, инославные. Следовательно, суммы земские собираются со всего населения – как с православного, так и инославного. Я считаю, господа, расходование таких крупных сумм на нужды только православного населения несправедливым с экономической точки зрения. Мы, представители инославных, не можем не протестовать против такого расходования земских сумм. Во всех земских губерниях, господа, мусульмане всегда встречают отрицательное отношение, когда они обращаются в земские собрания с ходатайством об открытии школы, о каком-нибудь пособии мусульманским учреждениям. Из общих земских сумм мусульманам или ничего не остается или остаются гроши, пора это прекратить»*** (Государственная Дума. Третий созыв. Стенографические отчеты. 1911 г. Сессия четвертая. Ч.Ш. СПб., 1911. С.4237).




Даже в такой обстановке государственного противодействия татарская национальная система образования продолжала развиваться в прогрессивном направлении, к 1913 году в Казанской губернии действовали 967 татарских школ и медресе, в их программу была включена грамматика татарского языка.

Для обсуждения вопросов инородческого образования в мае 1916 года в Уфе был созван земский съезд, на котором были подвергнуты критике земская и правительственная школы. Ставилась задача при содействии благотворительных обществ всемерно развивать татарскую общеобразовательную школу с преподаванием на родном языке.

Выдающийся татарский просветитель Закир Кадыйри писал: ***«Чтобы сохранить национальное понятие и собственное «я», надо учить на родном языке не только в начальной школе, но и в средних и высших учебных заведениях. Этого не было прежде, но надо ввести сейчас. И это должен сделать народ. Вместе с этим, доминирующая русская нация обязана дать возможность учить нашу молодежь в различных учебных заведениях родному языку... Значение обучения на родном языке возрастает. Эта цель надолго останется нашим идеалом».***



*26 апреля, в день родного языка, ученики школы «Яктылык» г.Самара*

**ГДЕ ВИТАЕТ ДУХ ИЛЬМИНСКОГО?**

Наверное, не было бы необходимости совершать столь пространный экскурс в историю становления и развития татарской национальной школы с преподаванием на родном языке, если бы эта проблема потеряла актуальность в наши дни. Вопрос сохранения языка – это вопрос сохранения нации. И любое движение одних в сторону ущемления права языка на существование вызывает бурную реакцию и противодействие других.

Хотя, о чем могут быть споры? Есть же статья 26 Конституции РФ, которая гласит: ***«Каждый имеет право на пользование родным языком, на свободный выбор языка общения, вос-***

***питания, обучения и творчества»,*** приняты законы о языках народов РФ, об образовании… Чего проще: исполняй законы и живи и радуйся…

Но мы порой забываем, что живем в стране, где подзаконные акты начисто попирают конституционные установки. Об этом с трибуны Всемирного Конгресса татар говорил мой друг, тогда еще первый заместитель председателя исполкома ВКТ Рамис Сафин:

***«Несколько лет назад Министерство образования и науки РФ вместо национальной школы ввело понятие «школа с этнокультурным компонентом». Мы наивно полагали, что изменение названия не отразится на сути национальной школы. А когда Государственная Дума Российской Федерации убрала из Закона об образовании понятие «национально- региональный компонент», стало понятно, что все это было придумано только с одной целью - окончательно развалить национальную школу.***

***Да, при всех недостатках тоталитарного режима, советская система образования считалась одной из лучших в мире. Она позволяла стране держать передовые позиции по многим направлениям научных исследований и разработок. Её составной частью была национальная школа, которой мы по праву гордились. Она цементировала наше общество, способствовала взаимопониманию народов, к взаимопроникновению их культур. Чем же она не угодила современным реформаторам образования, которые в последние годы целенаправленно проводят линию на разрушение национальной школы?»***





Для полноты характеристики сложившейся ситуации приведу еще и выдержки из доклада М. Шаймиева на совещании Министерства образования Российской Федерации: ***«Ситуация с преподаванием на родном языке меняется еще больше не в лучшую сторону, к сожалению. Я говорю в данном случае о татарском языке… На этом фоне в конце 2007 года произошло событие, которое вызвало серьезную настороженность и недоумение, по большому счету как у нас, так и в других регионах, республиках: был принят Федеральный закон №309, фактически отменивший законодательную гарантию сохранения и развития национальных языков и культур. По сути, из законодательства оказались изъяты и переведены в нормативную плоскость важнейшие положения, при отсутствии которых практически невозможной становится реализация субъектами их прав, предоставленных законами Российской Федерации «Об образовании» и «О языках народов Российской Федерации». Видимо, кому-то показалось, что языки народов Российской Федерации недостаточно быстро исчезают. Значит, решили ускорить, кому-то хочется ускорить это процесс. Родной язык не выбирают, с ним рождаются. Это язык мамы. А мама у каждого человека любой национальности единственная… По сути, сегодня законодательные нормы подменяются рекомендательными письмами департамента Министерства образования и науки Российской Федерации, а также предложениями различных экспертных групп».***

Но вот недавно прочитал сообщение о заседании Экспертного совета Комитета Госдумы РФ по делам национальностей по вопросам языковой политики, которое прошло в Москве 9 ноября. Члены совета приняли ряд рекомендаций, изложенных в обращении к председателю Комитета **Гаджимету Сафаралиеву.** Среди них есть и такое:

**- отнести государственные языки республик в системе школьного образования к дополнительному образованию с изучением их на добровольной основе;**

Экспертные рекомендации у нас обычно впоследствии принимают силу закона. По поводу этой рекомендации скажу одно: Дожили! Дополнительное – значит платное. Добровольное – значит никакое. Похоже, что в здании, где заседали эксперты, витал дух Ильминского…

А вот еще один образчик чиновнического рвения (отнюдь не радения!) Министерство связи и массовых коммуникаций РФ усмотрело угрозу межнациональным отношениям в России со стороны тех, кто создает и поддерживает интернет-сайты на языках народов РФ. Об этом говорится в официальном письме за подписью заместителя министра **Ильи Массуха,** которое поступило в организационный комитет конференции «Языки меньшинств в компьютерных технологиях: опыт, задачи и перспективы». Заместитель министра признает, что «создание иных информационных ресурсов и информационных систем на других языках народностей РФ законодательством РФ не ограничивается». И делает удивительный кульбит: «если такие ресурсы не являются образовательными, несут в себе угрозу появлению разобщенности народов РФ и может быть использовано для создания сайтов экстремистской направленности».

Как видим, простор для чиновничеcкого радения безграничен. Вот и поговори с такими о национальных школах, языках. Тут и экстремизм «пришить» могут…



# ОНЫТЫЛМАС МӘГЪРИФӘТЧЕ

***1930 елда Ульяновск шәһәрендә татар педагогия техникумы ачылды. Өлкә җитәкчеләре бу уку йорты өчен язучы И.А. Гончаровның өч катлы өен сайлаганнар. Училищеның директоры итеп А.Х. Казаков билгеләнә, ә завуч вазифасын Пенза шәһәре педучилищесында эшләгән, анда сигез ел тәҗрибә туплаган Хәмзә Йосып улы Долотказинга йөклиләр.***

**Минзакир НУРЕТДИНОВ**

Долотказин Хәмзә Йосып улы 1890 елда Пенза губернасы, Инсар өязе, Зур Аклан авылында крестьян гаиләсендә туа. Хәзер - Мордовия республикасы. Хәмзә 1898-1907 елларда татар урта мәктәбендә укый. 1907 елда аны Уфа шәһәренең данлыклы “Галия” мәдрәсәсенә кабул итәләр. Ул елны мәдрәсәдә җәдитчелек (гарәпчәдән тәрҗемәсе яңа) киң тарала. Җәдитчеләр тормыштагы торгынлыкны тәнкыйть итәләр. Халык кайгысын кайгыртып, караңгылыктан чыгу юлларын күрсәтәләр. Мәдрәсә уку планында дөньяви предметлар белән тулыландыру мәсьәләсен күтәреп чыгалар. Укытуда схоластикадан алынуга басым ясыйлар.

1913 елда шәкертләр забастовка күтәрәләр. Аның белән комитет рәисе Долотказин җитәкчелек итә. Мәдрәсәдән 64 шәкерт куыла. Алар арасында чыгарылыш сыйныфында укыган Долотказин да була.

1913-1916 елларда Хәмзә өч айлык башлангыч мәктәп укытучылары әзерләү курсларында укый. Мөгаллим исеме алган егетне Усра өязенең земствосы каршындагы мәктәпнең мөдире итеп билгелиләр. Долотказин өяз җитәкчеләре каршында яңа мәктәп төзү мәсьәләсен күтәреп чыга. Проблем озакка сузылмыйча, уңай хәл ителә. Авыл халкы Хәмзә Йосып улына рәхмәт белдерә.

1917 елның гыйнвар аенда егет шинел кия. Оренбург шәһәрендәге пехота полкында хезмәт итә. Февраль революциясеннән соң, Долотказинны полк солдатлары депутатларының комитет әгъзасы итеп сайлыйлар. Ул, полк мәктәбенең укытучысы буларак, солдатларны укырга, язарга өйрәтә.

1917 елның августында Хәмзә үз авылына кайта. Долотказин Октябрь революциясен туган авылында каршы ала. Анда китапханә ача. Авылдашлары каршында сәяси темаларга чыгышлар ясый.

1918 елның мартында яңадан Уфага әйләнеп килә. Мөгаллим хезмәтенә җене кагылган шәхеснең миен өзлексез бер уй бораулый: педагогия институтында уку һәм югары белем алу.

Ниһаять, милләттәшебез максатына ирешә: югарыда күрсәтелгән елның сентябрендә Уфа педагогия институтының бусагасын атлап керә.

1919-1922 елларда Уфа шәһәрендә совет гаскәрләре һәм аклар арасында сугыш бара. Колчак гаскәрләре Долотказинны кулга алалар. Гаепләү өчен сәбәп булмавы ачыклана. Студентны азат итәләр.

1922 елда тырыш егет институтны тәмамлый. Ул урта мәктәп биология укытучысы исеме ала. Авылда дипломлы мөгаллимне җылы каршы алалар.

Июльдә Пенза республикасының беренче партия секретаре мөгаллим белән күрешә һәм аңа татар педагогия техникумының мөдире итеп билгеләнүе турында белдерә. Республиканың татар мәктәпләрендә латин графикасыннан рус азбукасына күчү процессын тизләтергә куша. Долотказин секретарьга шундый җаваплы вазифаны ышандыру өчен рәхмәт әйтә. Милләттәшебез бу гамәлне 1930 елга кадәр үти.

1930 елда Пенза татар педагогия техникумында сигез ел эшләп, шактый

бай тәҗрибә туплаган шәхесне Ульяновск татар педагогия техникумына күчерәләр. Анда ул завуч булып эшли. Биология дәресләрен алып бара.

Җәмгыять эшендә актив катнаша.

1937 елда Долтказинны педтехникум директоры итеп билгелиләр.

1941 елның 22 июнендә фашист Германиясе, сугыш игълан итмичә, Советлар Союзы чиген басып керә.

Илебездә Бөек Ватан сугышы башлана.

Август аенда дошман гаскәрләре Мәскәүгә якынлаша. Министрыкларны башка шәһәрләргә күчерәләр.

Советлар Союзы хокүмәте «Диңгез флоты» министрлыгын Ульяновск шәһәренә күчерү турында карар кабул итә. Ульяновск өлкәсе җитәкчеләре министрлыкны татар педагогия училищесына урнаштылар.

Куйбышев өлкәсе җитәкчеләре татар педагогия училищесын Камышлы авылында кабул итәләр. Уку йорты Камышлы татар педагогия училищесы статусы ала. Камышлыда да директор вазифасын Долотказин үти.

Хәмзә Йосып улы училищеда замана таләпләренә җавап бирердәй башлангыч мәктәп укытучылары әзерләп торган методистлар коллективы туплый. Шулардан рус теле белгечләре, Россиянең атказанган укытучылар - Копылова З.Х., Макарова Н.Г., Коновалова А.Г., тарих галиме Акчурин А.З., педагогика, психология белгечләре Ганиева С.И., Хәсәнова С.М., химик һәм географ Минһаҗев И.Ф., физик Копылов А.П., математиклар Гулыманова А.Я., Җәббаров С.Х. һәм башкалар.

Студентлар Хәмзә Йосып улы белән күчеп килгән укытучыларны җылы искә алдылар һәм алалар. Болар Субаевлар гаиләсеннән татар теле белгече Абдулла Насретдин улы, биолог Әсма Хәмидулла кызы, татар һәм рус теле мөгаллимәсе Фәридә Абдулла кызы, Әбдерәшитовлардан татар теле методисты Сылу Галим кызы, тарих белгече Зиннәт Сафи улы. Соңгылары Муса Җәлил белән таныш була. Алар Оренбургта бергә укыганнар.

Камышлы педучилищесын Долотказин Х.Й. җитәкләгән елларда 2000 студент тәмамлый. Алар Куйбышев (Самар), Ульяновск, Пенза өлкәләренең татар мәктәпләрендә укыталар.

Камышлы татар педагогия училищесында укыган студентлар тирән белем алалар, башлангыч мәктәп укытучысының психикасын үзләштерәләр, отышлы методлар, алымнарны үз итәләр, практикада кулланалар.

Шенталы районының Денис авылы егете Нигъмәтуллин Сәлимҗан 1944 елда алты айлык педагогик курсларда укый, 1948 ел Камышлы татар педагогия училищесын тәмамлый, туган авылында башлангыч сыйныфларда укыта, Казан педагогия институтында укый, аны уңышлы тәмамлый, рус теле укыта, үзе белем алган мәктәптә директор вазифасын үти, җиде ел район мәгариф бүлеге мөдире булып эшли.

Ульяновск өлкәсе, Карсун районыннан Борһанов Бари да Камышлы педагогия училищесын тәмамлый, читтән торып Казан педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты факультетында укый, аны вакытында тәмамлый, урта мәктәптә укыта. Карсун районының мәгариф бүлегенең мөдире булып эшли. Аңа, мәгариф системасында ирешелгән уңышлары өчен, Россиянең атказанган укытучысы иseме бирәләр.

Камышлы районы яшьләренең күпчелеге мәгариф чыныкканлыкны үзләренең педагогия училищесында алдылар. Күпләргә таныш Гайшә апа Шәфигуллина Камышлы педагогия училищесының базовый мәктәбендә эшләде. Аның кызлары Фәнүзә, Әлфия, Фәния Камышлы татар педагогия училищесында укыдылар. Фәнүзә, училищены тәмамлагач, урта мәктәпнең башлангыч сыйныфларында укытты. Әлфия педагогия институтын тәмамлады, тарих белгече. Фәния тарих фәннәре кандидаты, доцент. Педучилищеда апалы-сеңелле Фәридә, Нәсимә Әхмәтҗановалар укыдылар. Алар да югары белем алдылар.

Камышлы татар педагогия училищесын тәмамлаучылар "Мәгариф отличнигы", "Өлкән укытучы", "Атказанган укытучы" исемнәренә ия булдылар, грамоталар, дипломнар белән бүләкләнделәр.

Долотказин "1941-1945 елларда данлыклы хезмәт күрсәткәне өчен" медале, "В.И. Ленинның тууына 100 еллык юбилее" медале, күп санлы мактау грамоталары белән бүләкләнә.

Долотказин Х.Й. Камышлы авылында 38 ел яшәде. Аның өчен Сок елгасының уң як ярында шаулап үсә торган каеннар, күзен кызарып пешкән чияләр, татлы җир җиләге якын иде. Хәмзә Йосып улы Камышлы авылын кече ватаны итеп санады.

Камышлы халкы танылган мәгърифәтчене сагынып искә ала.





# АРУ-ТАЛУ БЕЛМӘС УКЫТУЧЫ АПА

***Ана теле укытучысы... Нинди матур, күңелгә якын сүзләр! Ә укытучы мөлаем йөзле, ягымлы, йомшак телле, гадел дә булса, бу инде икеләтә күркәм.***

**Миләүшә ГАЗИМОВА**

Самарның “Яктылык” мәктәбендә татар теле дәресләреннән белем бирүче, югары категорияле укытучы Әхмәтзыя кызы Нурзидә Фәйзуллина нәкъ шундыйлардан.

Нурзидә апа кешеләрне тиз арада үзенә җәлеп итүе белән аерылып тора. Аның нурлы күзләре, эчкерсез елмаюы, тирән акылга ия булуы тирә-юнендәгеләргә тирән тәэсир итә. Нурзидә апа белән танышкач, аның якты образын күңел түренә салып куясың.

Әйе, чыннан да, аны күпләр ярата. Ә бар кешегә дә беркайчан да ярап бетеп булмый. Иң мөһиме - укытучы апа булып, аны укучылары ярата.

Тормышта күзәтелгән нәрсә: кечкенәдән нужа күреп үскән һәм күп авырлыклар кичергән кешеләр, гадәттә, миһербанлы, гадел, кешелекле, саф күңелле, башкаларга карата ихтирамлы булалар. Нурзидә апа белән аның озын гомере турында сөйләшеп утыргач, бу ханымның да ни өчен шушындый сыйфатларга ия булуына төшендем. Ул кичергән авырлыклардан биек тау өелер иде. Әтисез калу, матди яктан авырлыклар кичерү, якын кешесенең аның өметләрен акламавы...

Әле Бөек Ватан сугышына кадәр Татарстанның Түбән Норлат авылыннан бер унбишлләп гаилә, тормышта азрак җиңел яшәп булмасмы дип, Төньяк Кавказ якларына чыгып киткәннәр һәм Нальчик шәһәреннән ерак булмаган урман хуҗалыгына барып урнашканнар. Нурзидә апаның әби-бабасы һәм энисе Зәмзәмия дә шул мөһаҗирләр арасында була. Сугыш вакытында алар барчасы да немец оккупациясендә калалар. Зәмзәмиягә ул чакта бары 11 яшь була.

Нурзидәнең дөньяга килгән җире - Нальчик шәһәре. Аның әтисе Әхмәтзыя – Башкортостан татары. 50нче еллар башында Нальчикта хәрби хезмәттә була ул. Һәм аннан соң биредә яшәп кала.

Нурзидә апаның әти-әнисе нәкъ шушы шәһәрдә танышалар да инде. Чибәр, чая, уңган Зәмзәмиягә Әхмәтзыя бер күрүдә гашыйк була. Мәхәббәт диңгезенә чумган яшьләр озакка сузмыйча, өйләнешәләр.

Әхмәтзыяга эшеннән баракта бер бүлмә бирәләр. Кызлары туганчы, яшь гаилә шунда яши.

Әнисе һәм әтисенең назын бертигез тоеп үскән бала – бәхетле бала. Тик менә Нурзидәгә әтисенең итәгенә утырып назлану түгел, “әти” сүзен әйтергә дә насыйп булмый, чөнки, кызганычка, матур гына башланып киткән гаилә тормышы ирнең хыянәте аркасында чәлпәрәмә килә.

Әнисе кызын берүзе үстерә. Баланы ашатырга, киендерергә акча табар өчен, Зәмзәмия, ике айлык Нурзидәне яслегә биреп, эшкә чыга. Сугыш баласының белеме булмый, билгеле. Шуңа күрә аңа шәһәр урамнарын яшелләндерү оешмасына урнашырга туры килә.

Кызына дүрт яшь тулгач, язмыш Зәмзәмияне чыгышы белән Татарстанның Апас районы Дәвеш авылы кешесе - Нәгыймулла исемле ир-ат белән кавыштыра. Шулай Нурзидә, үги булса да, әтиле була.

Ә 1958 елда майның унтугызында аның энесе Газинур дөньяга килә.

“Бу көнне мин бик яхшы хәтерлим. Һава торышы искиткеч иде. Шушы көнне беренче тапкыр Нальчикка танылган җырчы Илһам Шакиров килде. Мин әтием һәм әнием белән аның концертына бардым. Ә кайтканда матур көн кинәт бозылып, бик каты яшен яшьнәп, көчле яңгыр ява башлады. Аңардан качып йөгергәндә әниемнең тулгагы (схватка) тотынды һәм аны хастаханәгә



1958 ел. Нальчик. Нурзидә әти-әнисе һәм бертуган энесе Газинур белән

алып киттеләр. Шулай әнем Газинур туды. Ә исемен аңа әтием кушты. Ул вакытта Габдрахман Әпсәләмовның “Газинур” дип аталган китабы басылып чыккан гына иде әле. Әти шушы китапны укып чыккач, улына Газинур исемен кушарга булган да инде”, - дип исенә төшерә Нурзидә ханым.

50нче еллар уртасында Нурзиданең бабасы: “Үлсәм, туган җиремдә җирләнним”, - дип, туган авылы Түбән Норлатка әйләнеп кайта. Аның артыннан Нурзиданең әти-әниләре дә шунда юл тоталар.

Шәһәрдә туып-үсеп, рус балалар бакчасына йөргән кызчык татарча бер генә сүз дә белми. Түбән Норлат мәктәбенә укырга кергәч, укытучыга аның белән гел русча сөйләшергә туры килә. Ә тора-бара Нурзидә, киресенчә, рус телен бөтенләй онытып, татарча гына сөйләшә башлый.

Беренче сыйныфта укыган 45 бала арасында кыз иң яхшы укучы була. Шуның өчен Нурзиданең фотосурәте Мактау тактасында эленеп тора.

Авылда яшәгәндә Нурзиданең сеңелләре - Нурания, Назирә, Фәридә, энеләре - Нәбиулла, Исмәгыйль (хәзер мәрхүм) туа. Җиде балалы гаиләдә өй эшләре дә арта. Шулай да кыз барысына да өлгерә. Мәктәптә дә бик актив була. Биредә үткәрелгән барлык чараларда, авыл клубында куелган концертларда катнаша.

“Безнең пионервожатый Флюра апа Тямаеваның “монтаж” дигән яраткан сүзе бар иде, - дип елмаеп сөйли Нурзидә апа, - һәрбер бәйрәм уңаеннан монтаж төзеп, салкын, ягылмаган клубта колхозчыларны бәйрәмнәр белән тәбрикли идек”.

Нурзидә, әнисенә охшап, матур итеп җырлый. Әнисе аңа татарча да, русча да бик күп җырлар өйрәтә. Аеруча “Катюша”ны бик оста башкара кыз. Шуңа күрә аңардан барысы да шушы җырны сорыйлар. Татарчаларны башкара башласа, аңа: “Татарча кем дә җырлый ала, син безгә “Катюша”ны давай!” – диләр.

“Шулай беренче сыйныфтан алып, миннән “Катюша”ны җырлаталар иде”, - дип көлә Нурзидә ханым.

Кышкы каникулларда мәктәп балаларын берәр җиргә экскурсиягә алып бара торган булалар. Ә гел “5”гә укыган Нурзидәне беркая да җибәрмиләр, чөнки бу вакытта аңа төрле предметлар буенча район олимпиадаларында катнашырга кирәк була.

Өченче сыйныфта Нурзидәне пионерга кабул итәләр. Кыз өчен бу көн зур бәйрәмгә әверелә, чөнки ул күптән пионер булырга хыялланып йөри. Әнисе кызыл галстук алгач, Нурзидә аны һәрвакыт тантаналы төстә, дулкынланып бәйләп куя торган була. Ә беренче тапкыр бәйләгәч, бу көнне ул хәтта галстугын салмыйча да йокларга ята. Аннан соң да һәрвакыт галстуктан йөри.

Яхшы укыганы өчен мәктәп директоры ике ел рәттән Нурзидәгә “Дуслык” дип аталган җирле колхозның авыл җәйләвенә (лагерь) юллама (путевка) бүләк итә. Колхозчыларның яхшы укучы балалары өчен оештырылган була бу җәйләү. Тик һәрвакыт икекеч көннән: “Син колхозчы баласы түгел!” – дип, кызны өенә кайтарып җибәрәләр.



“Мендәремне кочаклап, елый-елый кайтып китә идем”, - дип, әле бүген дә шушы гаделсезлекне күз яшьләрен тыя алмыйча исенә төшерә Нурзидә апа. Күпләр мактап искә алган социализмда да баланы рәнҗетерлек җитәкчеләр булган икән.

Түбән Норлатта яшәгәндә, әтисе тимер юлда, ә әнисе төзелештә Норлат шәһәренә йөреп эшлиләр, шуңа аларны “аерым хуҗалык” кешеләре (единоличники), дип йөртәләр дә инде.

Хәтта авылның колхозчылар яшәгән урамнарына электр кертсәләр, аерым хуҗалык кешеләре урамын урап узалар. Шуңа күрә Нурзидәгә мәктәпне керосин лампасы яктысында тәмамларга туры килә.

Сигезенче сыйныфтан соң, кыз Арча педагогия училищесына укырга керә. Аны шунда ук комсомолларның җитәкчесе итеп сайлап куялар. Биредә Нурзидә пионервожатый һәм башлангыч сыйныфлар укытучысы булырга әзерләнә.

Шунысы да игътибарга лаек – училищеда милләттәшебезне татар теленнән якташларыбыз, Камышлы районының Байтуган авылыннан чыккан танылган шәхесләр, “Әлифба”ны төзегән ирле-хатынлы Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитова укыталар.

Педучилищеда авылларда белем бирәчәк студентларны универсаль укытучылар итеп әзерлиләр. Алар төп фәннәрдән башка, шулай ук физ-



культураны да, музыка дәресләрен дә укытырга тиеш булалар. Шуңа күрә аларны музыка коралларында уйнарга да өйрәтәләр. Укырга кергәндә матур итеп җырлап күрсәткән моңлы тавышлы Нурзидәне скрипкада уйнаучылар классына билгелиләр. Тик кыз укытучыга бу уен коралында уйнарга теләмәвен белдерә. Тегесе моның сәбәбен сорагач, ул: "Безнең авыл клубында скрипка юк, баян гына бар, шуңа күрә минем шушы музыка коралында уйнарга өйрәнәсем килә", - дип җавап бирә. Шуннан соң аны танылган җырчы Айдар Фәйзерахмановның олы абыйсы – Марсель Фәйзерахманов алып барган баян классына күчерәләр.

Актив, тиктормас кеше буларак, педучилищеда Нурзидә хорга да йөри, төрле чараларда да катнаша. Аларның хоры Казанда чыгыш ясап, беренче урын ала. Студентларны хәтта телевидениегә дә чакыралар.

Пионервожатыйга укыган кеше учак яга, палатка куя белмәсә, нинди пинервожатый була ди инде?!

Шуңа күрә Нурзидәләрне икенче курстан соң, озын-озак походка алып китәләр. Урманда аларны учак ягарга, ботка, аш пешерергә, палатка куярга өйрәтәләр. Хәтта төнлә урманда студентлар үз курсташларының йокыларын саклап, чиратлашып кизү дә (дежурство) торалар!

Арча педучилищесын тәмамлагач, Нурзидә читтән торып Казан дәүләт педагогия институтына укырга кереп, татар мәктәпләрендә рус теле укытучысы һөнәрен үзләштерә башлый һәм Түбән Норлат авылында рус телен һәм музыка дәресләрен укытуга керешә.

1975 елда ул авылдашына кияүгә чыга, һәм алар Куйбышев шәһәренә күчеп киләләр.

"Биредә миңа эшкә урнашуы авыр булды. Татар мәктәбе юк иде, рус мәктәбенә укытырга барырга курыктым. Шуңа күрә алдан заводка гади эшче булып урнашырга туры килде", - дип сөйли Нурзидә ханым.



Заводта бер ел эшләгәч, ул вакытта өлкә укытучыларының белемен камилләштерү институты белгече Минзакир абый Нуретдинов ярдәме белән



ул балалар бакчасында тәрбияче булып эшли башлый һәм шушы дәвердә педагогия институтын бик яхшы билгеләргә генә тәмамлый.

Тормышы шулай әкрен генә җайланып китә аның. Ире фатир сатып ала. Нурзидә дә өйләре янында урнашкан балалар бакчасына күчә. Кызлары Резеда туа. Ул да бүген Самарда үз тормышы белән яши.

Декрет ялыннан соң, Тарасов исемендәге заводның (КАТЭК) балалар бакчасына эшкә урнашкан Нурзидә ханым ул вакыттагы бер вакыйганы исенә төшерде:

"Менә бит тормышта нинди кызыклы хәлләр була. Бүген безнең "Яктылык" мәктәбендә 3нче сыйныфта Әмир исемле малай укый. Аның әтисе Наил Садыков мин эшләгән бакчага йөрде. Мине анда барысы да Надежда Ахметовна, дип атап йөртәләр иде. Мөдиребез аны русча бик начар белеп, татарча гына сөйләшкәне өчен, минем группага бирде. Беренче көнне үзеннән дә зуррак чәчәк бәйләме тоткан



Наилнең янына килеп: “Надедушкина Ахметовна, здравствуйте”, - дигәнен еш кына елмаеп искә алам.

Бервакыт татар концертына баргач, Нурзидә апа Минзакир абый Нуретдиновны очрата. Ул аны Харидә Дашкина һәм Асия Сәйфетдинова белән таныштыра. Бу 1993 елның сентябрь башлары була. Шунда Минзакир әфәнде Нурзидә Әхмәтовнага бер кичке мәктәп нигезендә татар бүлеге ачылуын хәбәр итеп, аңа анда татар телен укытырга тәкъдим итә. Шулай язмабызның героинясы Самарның 12нче кичке мәктәбе каршында ике сыйныфтан торган татар бүлегендә укыта башлый.

Тора-бара кичке мәктәптә тагын берничә сыйныф ачыла, татар бүлеге киңәя бара. Бирегә укытучылар – Гөлчәчәк Нуруллина (завуч та булып эшли), Гөлҗиһан Мәхмүтова, аннан Радик Газизов, Нурзидә апаның бертуган сеңелесе Фәридә Зиннәтуллина киләләр.

1997 елда Харидә Дашкина тулы татар мәктәбен ачу турында сүз кузгата һәм укытучыларны балалар тупларга ярдәм итәргә сорый. Татар милли хәрәкәте активистлары Шамил Баһаутдин, Әминә Шәмси һәм укытучылар, җиң сызганып, эшкә керешәләр. Татар фамилияләре язылган исемлек белән өйләр буенча йөреп, ата-аналарны балаларын татар мәктәбенә укырга бирергә өндиләр.

“Шулай ике катлы мәктәбебез ачылды. Харидә апа аңа “Яктылык” дип исем бирде. Ул шушы исемне биргәндә Самарда яшәүче татар балаларының, яктылыкка омтылган кебек, ана телен өйрәнергә, татар милләтенә, татар тарихына, әдәбиятына, мәдәниятенә омтылуларын күздә тоткандыр, мөгаен. Харидә апа бу исемне дөрес кушкан”, - ди Нурзидә Әхмәтовна.



Укытучының Самарда ана телен укытуына 20 ел тулды. Татар теле һәм әдәбиятыннан тыш, ул бирегә 10 ел якшәмбе мәктәбендә дә укыткан. Татар телен, тарихын, мәдәниятен өйрәнергә теләүче төрле яшьтәге, төрле милләттәге кешеләргә белем биргән. Олысына да, кечесенә дә кызыклы, файдалы дәресләр үткәрер өчен бөтен мөмкинлекләрен кулланып эшли укытучы. Ә ул күп нәрсәләрне белә. Шуңа күрә аны шаярып: “аяклы энциклопедия”, дип атап йөртәләр.





2007 елда Нурзидә Фәйзуллина Камышлыда өлкәбезнең татар теле укытучылары арасында үткәрелгән «Ел укытучысы» бәйгесендә икенче урынга лаек була.

Тормыш сәбәпләре аркасында ире белән аерылган Нурзидә ханым нәкъ якшәмбе мәктәбендә заманында Самарның төрле дәвалау үзәкләрендә баш врач, ә хәзер психотерапевт булып эшләүче икенче ире Мәгъруф Гыйльмияров белән таныша да инде. 12 декабрьдә аларның бергә гомер итүләренә 10 ел тулды. Язмам герое ире турында сөйләгәндә: “Ул – минем яраткан, хөрмәт иткән, кадерле, якын кешем. Төпле, акыллы, белемле ир, зур хәрефтән язарлык шәхес”, - дип җылы сүзләр генә куллана.

Нурзидә Фәйзуллинаны укучылары да бик яраталар. Ул да аларны чын күңеленнән сөеп, үзләренә: “улым”, “кызым”, - дип эндәшә. Укытучы үз белемен даими рәвештә камилләштерә бара. Мәктәптә төрле бәйрәмнәр, чаралар да оештыра һәм аларны һәркем өчен кызыклы итеп үткәрергә тырыша.

Бүгенге көндә “Яктылык”ның мөдире Радик Газизов мәктәп радиосын алып баруны да Нурзидә апага тапшырган.

Укытучы мәктәп тормышына чумып эшли. Балаларны олимпиадаларга, бәйгеләргә әзерли ул. Укучыларында шигырьләр, хикәяләр язарга сәләтләрен күреп-сизеп алгач, аларның бу сәләтләрен үстерү өчен бар көчен куя, ничек булса да үзләрен кызыксындырырга тырыша.

Нурзидә Фәйзуллинаның укучылары аның җитәкчелегендә проектлар әзерләп, башка төбәкләрдә узган фәнни конференцияләрдә еш кына призлы урыннар яулыйлар. Казанның “Зирәк тиен” интеллектуаль уен-конкурсында да, “Мин татарча сөйләшәм” конкурс-акциядә дә, “Илһамлы каләм” бәйгесендә дә алар үз осталыкларын күрсәтәләр. “Татарстан - Яңа гасыр” каналында барган “Тамчы шоу” интеллектуаль балалар тапшыруында кат-

нашкан Нурзидә апаның укучылары Казаннан беренче урынны яулап кайталар. Укытучы сүзләренчә, бу җиңүдә командаларының капитаны, бүгенге көндә 11 сыйныфта белем алучы Лилия Миннебаеваның хезмәте зур.

Тынгысыз җан булган Нурзидә Әхмәтовна мәктәптә "Аргамак" дип аталган шигырь сөючеләр түгәрәге дә оештырган. Шигърият кичәләре үткәреп, ул балаларны татар теленең, әдәбиятының матурлыгын күрергә өйрәтә.

"Үз вакытында "Аргамак"ка йөргән укучым Наил Вәлиев мәктәпне тәмамлагач, 7 – 8 елдан соң очрашу кичәсенә килде. Шунда ул миңа: "Апа, Сез миндә татар әдәбиятына, татар шигъриятына мәхәббәт уяттыгыз. Рәхмәт Сезгә", - диде. Әгәр дә мин үзем укыткан 100 баланың берсендә генә булса да ана телебезгә мәхәббәт уята алганмын икән, димәк, шуның өчен генә дә эшләргә кирәк, димәк, мин юкка укытмыйм", - ди укытучы.

Милләттәшебез дәресләрдә дә, алардан тыш чараларда да укучыларны бөек шәхесләребез, танылган якташ шагыйрьләребез, язучыларыбыз, композиторларыбыз белән таныштыра. Кызыклы, күңел түренә үтеп керерлек сценарийлар төзеп, Нурзидә ханым балаларга татар теленең матурлыгын, моңлылыгын күрсәтеп, аларга карата соклану уята.

Аеруча мәрхүм якташыбыз, танылган шагыйрь, урын өстендә ятып торып, авызына каләм кыстырып, рәсемнәр ясаучы, шигырьләр, хикәяләр язучы Гакыйль Сәгыйровны якын итә ул.



Әле Арча педучилищесында укып йөргән чакта шагыйрьнең "Тормыш җиле" дип аталган китабын сатып алган студент кызга җыентыктагы бер шигырь аеруча күңеленә кереп кала, чөнки ул Нурзидәнең шушы чактагы кичергән хисләренә, тойгыларына тәңгәл килә.

"Барысын, барысын өзелеп
сагындым мин,
Сагынганнар микән алар да?
Эх, ашкынып, туган якларыма
Кайтыр идем җәйге айларда!" – дигән шигъри юлларны укыгач, нечкә күңелле кызның авылын, якыннарын сагыну хисләре тагын да ныграк сизелә. Шуңа күрә дә бу шигырь аның хәтеренә уелып кала.

Һәр елны мәктәптә укытучы якташ шагыйребез Гакыйль Сәгыйровка



багышлап, әдәби-музыкаль кичәләр, шигърият бәйгеләре үткәрә, ачык дәресләр бирә.

Укучыларының мәктәпне акыллы, тәртипле, белемле кешеләр булып тәмамлавы – укытучы өчен иң зур бүләк. Шулай ук югары органнар тарафыннан да хезмәтенә лаеклы бәя бирелүе дә укытучының күңелен күтәрә торган күренеш, әлбәттә. Нурзидә апа үзенең бүләкләр сандыгында Татарстан фән һәм мәгариф министрлыгының "Мәгарифтәге казанышлары өчен" күкрәк билгесен, Самар Губерна Думасы Мактаунамәсен, Самар шәһәре мәгариф департаментының, Бөтендөнья татар конгрессының рәхмәт хатларын, Совет районының халык мәгарифе хезмәткәрләре профсоюз оешмасының Мактаунамәсен һәм башкаларны кадерләп саклый. Ә быел ноябрьдә Радик Газизов җитәкләгән "Яктылык" мәктәбе администрациясе һәм укыту-



чылар коллективы, Самар шәһәренең мәгариф департаменты, Бөтендөнья татар конгрессы президиумы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы карары белән аңа "Татарстанның атказанган укытучысы" исеме бирелде. Бу карар Татарстанның Президенты Рөстәм Минниханов тарафыннан расланды.

Нурзидә Фәйзуллина шәһәребезнең милли хәрәкәте эшләрендә дә актив катнаша, укучыларын да моңа җәлеп итә. Шулай ук шәһәребезнең "Сәлам", "Бердәмлек", элек чыгып килгән "Азан" газеталарына төрле темаларга мәкаләләр яза.

Әхмәтзыя кызы Нурзидә Фәйзуллинага 29 декабрьдә 60 яшь тула. Күпләр бу чорда пенсиягә китеп, өйдә утыралар. Нурзидә апа исә мәктәптә укытуына бик шат, шуның өчен Ходай Тәгаләгә рәхмәтләрен әйтеп бетерә алмый ул. Аның күңеле һаман яшь. Димәк, әле алдагы елларда да эшлисе дә, эшлисе генә аңа.

Шунысы куанычлы – милләттәшебезнең әнисе бүгенге көндә, шөкер, исән-сау, Түбән Норлат авылында яши, аңа 82 яшь. Сеңелләре дә, апалары да Нурзидә белән һәрвакыт күрешеп, аралашып, аның уңышларына шатланып гомер кичерәләр.

Ярдәмчел, юмарт, һәр кешенең яхшы якларын гына күрергә омтылган Нурзидә апаның хезмәте – аның яшәү рәвеше, бәхет чыганагы. Мөгаллимә үз укучыларына биргән белеменә күңел җылысын, мәхәббәтен дә кушып укыта. Ул - гомеренә ару-талу белмәс Укытучы апа, милләтебезне саклаучы мөгаллимә.



ГОД ОСНОВАНИЯ 1974

# Кулинария
## НА РЕВОЛЮЦИОННОЙ

ПРАЗДНИЧНЫЕ ТОРТЫ И ПИРОЖНЫЕ
ПО ИНДИВИДУАЛЬНЫМ ЗАКАЗАМ

ГОТОВЫЕ ИЗДЕЛИЯ ИЗ МЯСА, РЫБЫ, ПТИЦЫ,

САЛАТЫ И ГАРНИРЫ

ОХЛАЖДЕННЫЕ И ЗАМОРОЖЕННЫЕ
ПОЛУФАБРИКАТЫ

БОЛЬШОЙ АССОРТИМЕНТ СВЕЖЕЙ ВЫПЕЧКИ

ПРИНИМАЕМ ЗАКАЗЫ НА ПИРОГИ ОТ 2-Х КГ

ГОРЯЧИЕ ОБЕДЫ В ОФИС С ДОСТАВКОЙ

ОБСЛУЖИВАНИЕ БАНКЕТОВ И ФУРШЕТОВ

Тел.: 260-10-60, 260-15-60
ул. Революционная, 142



# Рафаэль БАГАУТДИНОВ: «Главным богатством Камышлинского района является талантливый и творческий народ»

***По итогам социально-экономического развития за 2012 год Камышлинский район занял 6 место среди муниципальных образований Самарской области. Всего четыре года назад район в данном рейтинге занимал последнее место. О том, как удалось улучшить экономические показатели, об итогах уходящего года и перспективах дальнейшего развития мы беседуем с главой Камышлинского района Рафаэлем Багаутдиновым.***

**Данияр САЙФИЕВ**

***– Как удалось выбиться в число лидеров?***

– Это результат планомерной работы во всех сферах деятельности района. Большой рывок мы сделали в модернизации систем здравоохранения, образования и культуры. Так, в 2011 году поликлиника в Камышле была капитально отремонтирована и соединена теплым переходом со зданием центральной районной больницы, которая также была модернизирована. После капремонта открыла двери 1 сентября школа в селе Байтуган. В начале следующего года в Камышле планируется ввод в эксплуатацию блока «А» образовательного центра, где будет размещена школа. В перспективе завершение строительства блока «Б», где будет функционировать сельскохозяйственное среднее профессиональное учебное заведение. В этом центре предполагается два больших спортзала, бассейн и стадион. Поэтому этот образовательный, культурный, спортивный комплекс имеет большое социальное значение, так как заниматься здесь будут не только учащиеся, но и все жители района.

Рейтинг составляется в том числе и с целью определения недостатков, на устранении которых муниципалитетам необходимо сосредоточиться. Наш минус – отсутствие крупных инвестиций, в том числе в сельскохозяйственное производство. Из 34 тысяч гектаров земли в районе обрабатывается только 22 тысячи. Для того чтобы оставшиеся 12 тысяч га не простаивали, в настоящее время совместно с министерством сельского хозяйства разрабатывается проект привлечения инвестиций в развитие животноводства. Это позволит создать новые рабочие места. На современном крупном предприятии будет интересно работать молодежи, которую мы стремимся оставить на селе. Но пока, к сожалению, из шести тысяч человек трудоспособного населения треть работает за пределами района. Чтобы вернуть трудовые ресурсы, надо создавать рабочие места.

***– Означает ли это, что среднестатистическому камышлинцу стало жить лучше?***

– Согласно рейтингу, к заслугам района можно отнести достойное содержание дошкольных и школьных образовательных учреждений, а также работу по строительству спортсооружений. В муниципалитете действительно нет очереди в детские сады. Но это вовсе не связано с провалом в демографическом графике. Мы, наоборот, стали замечать подъем рождаемости. Тут и материнский капитал сыграл роль, и условия жизни в районе. Очевидно, что молодым семьям очень важно знать, что у них не будет проблем с устройством в садик, что дети потом в школе получат доступное и качественное образование. И с этим нет проблем и в районном центре, и в близлежащих селах. Детские сады и школы ремонтируются. В них работают дополнительные курсы и кружки.

***– В конце каждого года принято подводить итоги. Каковы они для Камышлинского района? С чем район входит в год грядущий?***

– Приоритеты в работе администрации выстраивают, прежде всего, сама жизнь, а также проблемные вопросы и закон. Мы добросовестно исполняем те полномочия, которые определены муниципальному району Федеральным законом. И работа всех структур администрации это, прежде всего, работа с населением. Она включает в себя не только быстрое реагирование на заявления и жалобы жителей, но и контроль за функционированием всех служб, от которых зависит жизнедеятельность района.

Не скажу, что всё было просто. Много сил и времени ушло на решение таких проблем, где приходилось задействовать не только внутренние административные резервы, но и активно выходить на уровень правительства области.

Благодаря финансовой поддержке в районе начались определенные подвижки в строительстве. Мы участвуем в программе по переселению из ветхого и аварийного жилья, продолжаются капитальные ремонты. Привлекаются средства на строительство и ремонт дорог. Модернизируется сфера ЖКХ. Прошли существенные изменения в сфере образования. В районе выполнен большой объем работ по благоустройству населенных пунктов. Эта работа будет продолжена и в будущем году. Несмотря на ряд проблем, относительно стабильно работали в уходящем году отдельные службы района. Надо отметить, серьезно развивается в районе малое и среднее предпринимательство в сфере именно сельскохозяйственного производства. Наш район участвует во всех федеральных и областных программах, разрабатывает собственные программы поддержки, в том числе малого бизнеса. Совместно с департаментом предпринимательства мы создали фонд микрофинансирования предпринимателей. За счет этого бизнес индивидуальных предпринимателей стал крепнуть, хозяйства укрупняются, создавая дополнительные рабочие места для сельчан. Лицом малого бизнеса района является семеноводческое хозяйство «Байком-Сервис» в селе Байтуган. Оно постоянно расширяет обрабатываемые площади, приобретает технику, строит сооружения по очистке семян и производственные здания. Предприятие соблюдает высокую культуру земледелия, использует современные подходы к применению удобрений и средств защиты растений. Высокопродуктивными семенами «Байком-Сервис» обеспечивает фермеров всего района. В этом году мы разработали программу поддержки хозяйств, использующих семена высокой репродукции. 50% от стоимости семян мы компенсировали предприятиям из районного бюджета. Показательным хозяйством в животноводстве является КФХ Ильшата Каюмова. Этот предприниматель постоянно увеличивает поголовье КРС, и надои молока в его хозяйстве самые высокие.

Күмәк хуҗалык таркалып куйса да, авылыбыз халкы югалып калмады. Алар эштә уңган, тырышып-тырмашып көн күрә. Шулар арасында фермер хуҗалыклары, җир эшкәртеп, чәчеп, көзен мул уңыш җыеп алалар. Терлек асрап, авыл продукциясен җитештерәләр. Менә алар: Ринат Әбүсәетов, Илдус Минхәеров, Рәис Рәҗәпов, Минәсхәт Халиков һәм башкалар. Өстәвенә, күп итеп кош-корт, яшелчә, җиләк-җимеш үстереп тә файда күрәләр», - дип, мине авыл белән таныштырды.

Рәшит Хәертдинович белән аралашкач, без аның белән авыл буйлап чыгып киттек.

Авыл үзәгендә төзелгән бик матур, зур Мәдәният Сараеның ишеген ачып, эчкә үттек. Биредә без "Сердәш" исемле ансамбльнең репетиция ясап яткан чагына туры килдек.

– Хәзер авыл халкы көзге эшләрне тәмамлап, кышкы ялга туктады. Без ансамлебез белән бәйрәмнәрдә концертлар, матур чаралар үткәреп, авылдашларыбызның күңелләрен күтәрәбез. Чөнки авыл кешеләре өчен без мәдәният учагын тергезүчеләр булып саналабыз, – дип сөйли ансамбль җитәкчесе Резидә Шәкүрова.

– Мин үзем дә ансамбльнең һәвәскәр артисты. Җырларга, биергә бик яратам. Шуның өчен кичләрен яшьләр өчен дискотека, төрле уеннар оештырабыз. Концерт программабыз белән башка җирләрдә дә чыгыш ясап кайтабыз, – дип сүзгә кушыла Мәдәният Сарае җитәкчесе Рәсилә Әбүсәетова.

Дөрестән дә, бу бина бик матур, заман таләпләренә туры килерлек итеп төзелгән. Артистларның милли костюмнары өр-яңа, музыка аппаратуралары да җитәрлек. Мәдәният Сараеның ачылуы 2009 елда билгеләп үтелгән.

Шушы бинада авыл китапханәсе урнашкан. Рушания Кашапова китапханәче булып эшли. Биредә барлыгы ун мең китап бар. Авылда 370



Авыл Мәдәният Сараеның «Сердәш» ансамбле




Ябылган мәктәп бинасы



*Авылның беренче имамы Әсхәт ага Мусин*

кеше китап укырга ярата икән.

Китап сөючеләр арасында өлкән яшьтәгеләр генә түгел, яшьләр дә русча, бигрәк тә татар китаплары белән кызыксыналар икән. Тик шунысы эчне пошыра: татарча китаплар бик аз кайтарыла икән.

Татар Әбдекие авылында элемтә үзәге бар. Әле яңа гына көзге айларда фельдшер-акушер пункты төзелеп, кулланышка тапшырылган. Авыл халкының шатлыгы чиксез. Чөнки исәнлек тормышта беренче урында тора бит. 20 елга якын биредә хезмәт итүче Шәһидә Тимергалиева көн дими, төн дими, төрле һава шартларына карамастан, тәүлекнең төрле вакытында авыруларга беренче ярдәм күрсәтә, уколлар кадый, районнан дарулар алып кайтып бирә.

Тагын авылда Нәсимә Сафина җитәкчелегендәге социаль үзәк эшләп тора. Биредә 14 хезмәткәр 65 әби-бабайның картлык тормышын җиңеләйтә. Зур ярдәм күрсәтеп, читтә яшәүче балаларын алыштыра.

Сабан туе элек-электән бөек татар халкының милли бәйрәме булып саналган. Ә ат чабышыннан башка бу бәйрәмне күз алдына да китереп булмый торгандыр. Габделхәй белән Рәмзия Вәлиевлар озак еллар чабыш атлары асрыйлар. Габделхәй әфәнде Татарстанда, Самар өлкәсе авылларында үткәрелгән Сабан туйларында, Камышлыда, Галидә үткәрелгән ат чабышы ярышларында катнашып, призлы урыннар яулаган, макталуга, зур хөрмәткә лаек булган. "Татар иренең йөрәгендә иярле ат ятар", – дигән борынгы бабайлар сүзе аңа бик тә туры киләдер, минемчә. Ә гомере буе чабыш атлары асраучы Габдарман абый Закировның исеме, үзе мәңгелек йортка күчсә дә, телдән төшми.

Манарасы айлы мәчетләрне
Читләп уза җилләр, давыллар.
Хәбилләре, Равилләре белән
Горурлана безнең авыллар, – дип яза

җирле шагыйрь Рөстәм Нуретдинов. Әйе шул. Һәр татар авылы кешеләре үзендә туып-үскән, тирә-якка даны таралган бөек шәхесләре белән горурланып яши бит.

" Хәбил Хаҗи улы Бикташев мәктәптә укыганда бик гадел, туры сүзле, үз максатына ирешүчән укучы иде. Ул данлыклы керәшчеләр нәселеннән. Аның



*Чабыш атларын асраучы Габделхәй белән Рәмзия Вәлиевлар*

әтисе Хаҗи да тирә-юньдә танылган көрәшче иде. Хәбилдәге ир-егетләргә бирелә торган асыл сыйфатлар – бабасы да әтисеннән күчкәндер", – дип көрәш батырын барлый Татар Әбдекие авылы мәктәбендә 40 ел укучыларга белем бирүче (авыл мәчетенең беренче имамы), авыл аксакалы Әсхәт ага Мусин. Дөрестән дә, минемчә, гади татар авыллары бик күп югары шәхесләрне дөньяга бүләк иткән. Шулар арасында

Хәбил Бикташев, көрәшче буларак, "Атказанган спорт остасы", Европа, СССР чемпионы, "СССРның атказанган тренеры" исемнәренә, Хәрби эчке эшләр майоры (майор внутренних войск) дәрәҗәсенә, ә Равил Исхак улы Кашапов – доцент Поволжской государственной Академии физической культуры и спорта Республики Татарстан, 16-кратный чемпион РСФСР, двухкратный чемпион мира в беге на 100 км, награждён почётным знаком "За заслуги в развитии Олимпийского движения России", дип аталган мактаулы исемнәргә лаек булганнар.

Ә бүгенге көндә Казан шәһәрендә югары уку йортында белем алучы Айдар Рамил улы Лотфуллин яшүсмерләр арасында шахмат уйнау буенча "Европа чепмпионы" исемен яулаган.

Менә инде язмам ахырына таба якынлашты. Татар Әбдекие авылында тормыш итәр, яшәр өчен бөтен мөмкинлекләр дә булдырылган. Биредә зәңгәр ягулык өйләрне җылыта, электроэнергия, телефон бар, югары тизлектәге интернет эшләп тора, кәрәзле телефон өчен биек антенна бастырылган. Җирле үзидарә җитәкчесе Рәшит Хәертдин улы Зөлкарнәев, авыл кешеләре рәхәт тормышта яшәсен өчен, көчен кызганмый. Тик шунысы аянычлы: быел авылдагы урта мәктәп ябылган. Алдагы елларда аның тормышы, мәктәп җитәкчесе Расих Гани улы Шаһвәлиевның, авыл кешеләренең мәктәпне яптырмас өчен җан атып йөрүләре турындагы язмаларым "Бердәмлек" газетасы битләрендә басылып чыккан иде инде.



Авыл белән танышып йөргәндә Расих әфәнде белән мәктәпкә кереп чыгарга уйладык.

– Мәктәпне быел ук ябарлар, дип уйламаган, башлангыч мәктәп итеп калдырырлар, дип көткән идек. Чөнки закон буенча кечкенә балаларны юлда йөртергә ярамый, дигәннәр иде. Мине җитәкче эшеннән азат итеп, мәктәпне Денис авылы мәктәбенә беркеткәч, аны бөтенләй ябып ук куйдылар. Хәзер инде укучылар һәр көнне иртән-иртүк автобуска утырып, чит авылга барып, укып кайтырга тиеш булдылар. Югыйсә, мин мәктәпкә лицензия, пожар сигнализациясе (400 меңгә төште) ясаткан идем инде. Соңгы елда биредә җылы бәдрәфләр дә булдырылган иде бит”, – дип эч пошулары белән уртаклашты Расих Гани улы.

Расих әфәнде белән сөйләшә-сөйләшә әле кайчандыр шатлыклы балалар шау-шуыннан тынып калган коридор буйлап атлыйбыз. Менә монда заман таләпләренә җавап бирерлек сыйныф бүлмәләре, ашханә, менә монда музей бүлмәсе. Бирегә кергәч, кайчандыр тырышып–тырмашып җыйган күңел җәүһәрләренә күз салам. Менә монда әбиләребез киеп йөргән бала итәкле, матур итеп тегелгән күлмәкалъяпкычлар эленеп тора. Аларның җырлый-җырлый икмәк урган ай ураклары, басуга тартып йөри торган бала арбасы. Әнә стенага Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарның рәсемнәре эленгән булган. Аларның сурәтләре: без мәктәпләрне ябып, туган авылыбыз таркалсын, милләтебез югалсын өчен гомеребезне корбан иттекмени, дигән сыман, әрнеп карап торалар төсле тоелды миңа. Менә монда гомерләре буе яшь буынга белем биреп, олы тормышка аяк бастырган укытучылар исемлеге: Самания Нуретдинова, Кыям Гайсин, Исмәгыйль Еремеев, Зәйтүнә Еремеева, Әсхәт Мусин һәм тагын әллә кемнәр.

Мәрхүм Самания апа Нуретдинованың тамырлары данлыклы язучы Гаяз Исхакыйга барып тоташа, дип авылдашларыннан ишеттем. Менә шуларны уйлап аласың да, күр инде, әкрен генә таркалып баручы татар авыллары белән бергә аның тарихы да юкка чыга бит, дип уфтанып куясың.

Татар Әбдекие үзенең балта осталары белән дә данлыклы.

Шуларның берсе Тәлгать Фаваризов улы Радик белән урамда такталар шомартып торалар иде. Без сөйләшеп торганда, мин алардан авылда Самар өлкә Сабантуе үткәреләчәге, аларның бу хакта ни уйлаулары турында кызыксындым. Тәлгать әфәнде: ”Әйе, без бу турыда ишетеп кинәндек инде. Чөнки авыл кешесенең дә матур итеп ял итәсе килә бит. Сабан туе булса, күтәренке рухта авылыбыз тирәләре, урамнар чистартылыр иде. Бәйрәм булмагач, чит җирләрдә яшәүче туганнарыбыз кунакка да кайтмый башладылар. Алар: «Авылның яме китте. Ул шундый тыныч, әйтерсең лә тирән, авыр йокыга талган», - диләр. Тикмәгә генә: “Авыл кешесе бер Сабан туеннан икенче Сабантуена кадәр яши, дип әйтмәсләр, иде”, - диде.

Авылларның язмышына
Тәэсир итә күп нәрсә,
Авылыма васыятем -
Әбдеки! Мәңге яшә! – дигән җирле шагыйрь Рөстәм Нуретдиновның шушы шигъри юллары бик тә урынлы булыр иде, минемчә.

Әйе шул. Төрле вакыйгаларга бай булган яңарыш чорында яшибез. Шулай булса да, үзебезнең милли гореф-гадәтләребез, Ислам динебез, телебез, мәдәниятебез югалмыйча, татар авылларының гомере озын булып, киләсе матур җәй аенда Әбдеки авылы читендәге түгәрәк күл буенда үткәреләчәк Сабан туе мәйданында очрашырга язсын иде!



*1990 елда төзелгән мәчет бинасы*



# БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ МӘЧЕТ ТӨЗЕЛЕШЕН ТАТАР ХАТЫНЫ ҖИТӘКЛӘДЕ

***Тарихта беренче мәртәбә Тольятти шәһәрендә 1997 елда февральнең 7ндә, Ураза гаете көнне, тантаналы шартларда мәчет ачылды. Россия киңлекләрендә беренче мәртәбә мәчет төзелешен татар хатыны Роза Кәримова җитәкләде. "Туган тел" исемле Самар өлкә татар җәмгыяте шул уңайдан Роза Кәримованы "Самар өлкәсенең мәшһүр татары" итеп игълан итте. Төзелешкә бәйле вакыйгаларны Роза Кәримова белән бергә искә төшерәбез.***

**Шамил БАҺАУТДИН**

Роза Кәримова – һөнәре буенча укытучы, психолог. Җирле "Туган тел" җәмгыятенә нигез салучыларның берсе һәм аның рәисе.

Милли хәрәкәттә гаиләдән йә ире, йә хатыны катнаша. Роза ире Ирек белән бергәләшеп, милләт йөген җилкәләренә алган затлар.

90нчы еллар уртасы һәм бигрәк тә азагы - Самар өлкәсендә җинаятьчелек чиктән ашкан чор. Аның оясы Тольяттида иде. Сәбәбе дә гади – АвтоВАЗ. Кайда байлык – шунда криминал. Ул елларда җинаятьчелек төркемнәре дә милли төс алды: грузин, таҗик, чечен, татар төркемнәре. Шушы авыр чорда татар хатыны Роза Кәримова мәчет салу мәшәкате белән янып-көеп йөрде һәм төзелешнең очына да чыкты.

**– Роза ханым, тирән тарихка кереп китик әле. Мәчет салу идеясы ничегрәк туды?**

– Мин аны беркайчан онытмыйм. Тольяттиның "Юбилейный" Мәдәният Сараенда Идел буенда динебез Ислам кабул итүгә 1100 ел үтүгә багышлап, конференция уздырдык. Шул тантанада шәһәребезнең иң өлкән, иң дәрәҗәле шәхесе - имамыбыз Габдулла Гәйнетдинов Тольяттида мәчет салырга кирәклеген әйтте.

Ә чынында, сүзне "Туган тел" җәмгыятенең оешуыннан башларга кирәк. Самарда "Туган тел" җәмгыяте оешуга безгә җәмгыятьнең директоры Рәшид Абдуллов һәм аның урынбасары Шамил Баһаутдин килделәр. Бер төркем иптәшләр белән бик матур карарлар кабул иттек һәм җиң сызганып, эшләргә дә тотындык.

Самарда Сабан туе уздыралар, карап кайтабыз да үзебездә уздырабыз. Самарда Нәүрүз уздыралар, карап кайтабыз да үзебездә уздырабыз. Самарда "Уйнагыз, гармуннар!" уздыралар, карап кайтабыз да үзебездә уздырабыз.

Иптәшләребез белән сөйләшеп, мәчет салырга карар кылдык. Мин җәмгыятьнең рәисе идем.

Икенче мөһим очрашу байларыбыз белән узды. 1994 ел. 7нче гыйнвар. Байларыбыз "Туган тел" карарын хупладылар. Ышаныч тагын да арта төште.

**– Сүз белән гамәл арасы күпме вакыт алды?**

– Шәһәр мөселман җәмгыятен оештырдык. Аннары мәчет салырга җир алдык. Шул мәшәкатьләргә өч ел гомер китте.

**– Кабинетлардан кабинетларга кәгазьләр тотып кем чапты?**

- Ирем Ирек Кәримов.

**– Россиядә җир алу бик кыен. Урыс шовинистлары һәрвакыт аркылыга төшәләр һәм атакайлар тарафыннан терәк табалар. Тольяттида каршылыклар булдымы?**

– Аллаһыга шөкер, Ходай Тәгалә үз ярдәменнән ташламады. Ул вакыттагы район башлыгы Анатолий Степанов, бернинди каршылыксыз, җир бирү ризалыгы документына кул куйды. Степанов чыгышы белән Татарстаннан иде. Татарларга мөнәсәбәте яхшы булды. Монда Ирек Сыйтдыковның хезмәте гаҗәеп зур булды. Гыйбадәтханәнең проектын Али Тугушев башкарды.

**– Роза ханым, кәгазьләргә куллар куелган. Эш башлар өчен шунда ук акча кирәк бит.**

– Мәчет төзелешенә матди ярдәмне күпләр күрсәтте. Һәр кеше үзенең мөмкинлегенә карап, өлеш кертте. Барчасына да рәхмәттән башка сүзем юк.

Һичшиксез, шәһәрнең Центральный район башлыгы Анатолий Степановның ярдәмен даими тоеп яшәдек. Соңрак Капорцев та ярдәм итте.

Мәчет тулысынча халык акчасына салынды. Гарәпләр дә, төрекләр дә бер тиен дә бирмәделәр. Без сорамадык та.

**– Мәчет төзелешендә ай кую тантанасы аерылып тора. Айны кайчан куйдыгыз?**

– 1994 елда мартның 23ндә җир казу эшләре башланды.

1996 ел. 15нче ноябрь. Тарихта беренче мәртәбә тәре шәһәрендә ай калыкты.

**– Роза ханым, кырыс холыклы, таләпчән ирләр белән ничек эшли алдыгыз, һәм ул елларда Сезгә нинди көчләр дәрман биреп торды?**

– Искә төшерергә дә куркып утырам. Аны мин хәсрәт тә дип әйтмәс идем. Төрле уйлар, төрле мөнәсәбәтләр аша узарга туры килде. Ходай Тәгалә миңа көч биреп торгандыр инде. Мин үземне бәхетле хатын, дип исәплим. Тирә-юнемә татар йөрәкле, күңел

түрләрендә динебез Ислам оеткысы калган бәндәләрне җыя алганмын. Командабыз көчле булды.

Артка борылып карыйм да күрәм – ул еллар гаҗәеп сихри көчкә ия булган. Бер-беребезгә дәрт өстәп торганбыз. Җәмгыятебездәге егермегә якын ир вә хатын бер гаилә булып, дөрләп иҗат иттек. Эшләдек сүзе генә туры килмәс – дөрләдек.

Төп көч ул татар милли хәрәкәтенең ашкынган дулкыны булды. Самарда оешкан "Туган тел" җәмгыяте дә безнең киңәшчегә әйләнде, фикердәшләр булдык. Җәмгыять рәисе Фатых углы Рәшид Абдуллов үзенең ярдәмчесе Шамил Баһаутдин белән безнең чараларга килми калмаслар иде. Бертуктаусыз телефон аша элемтәдә тордык. Самар, Сызран, Тольятти, Похвистнево "Туган тел" җәмгыятьләре зур бер команда булып эшләдек, бер-беребезнең бәйрәмнәренә йөрештек. Туганлашып беттек.



Эш шунда ки, без мәдәни тормышны һәм дини юнәлешне аермадык.

Шулай да мәчет салу үзе олуг мәшәкать икәнен төшендек.

Тольятти – ул яшьләр шәһәре, уртача 30-32 яшьлекләр эшләдә. Аның тарихында мәчет салу гына түгел, бу хакта фикер йөртү дә булмаган. Дөрес, шәһәрнең Киров урамындагы 20нче йортка картлар намазга йөрде. Ул картлар сөйли иде: "Балалар, сез менә "Туган тел"дә йөрисез. Бер кеше табып, шәһәрдә мәчет салдырасы иде".

**– Ә менә мәчет салуга ниндирәк этәргечләр булды соң?**

– Оеткысы 1989 елда салынган, дип уйлыйм. Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан Казаннан Фаяз Хуҗин һәм Гамирҗан Дәүләтшин килгәннәр иде. Хәзер икесе дә зур галим булып җитте, тарих фәннәре докторлары. Халык белән очрашканда җитди сүзләр сөйләнде. Алар халыкны канатландырып китте.

Фаяз белән Гамирҗан киткәч, Тольяттига Роберт Батулла килде. Хәзер ул Рабит инде. Батулла көчле оратор һәм милли җанлы акыл иясе буларак, хисләргә ялкын өстәде. Халыкка чыгар өчен аудитория кирәк иде. Мәктәптә татар телен укытырга рөхсәт алдым. Киттем Казанга. Бер олау татар теле әсбаплары төяп кайттым.

74нче мәктәп мөдире Вячеслав Загорскихка рәхмәтебез чиксез. Ул бернинди каршылыксыз татар телен укытырга рөхсәтен бирде. Миннегөл Мөбинова белән йорттан-йортка йөреп, ата-аналарны балаларын татар теле дәресләренә йөртүләрен сорадык. Һәр гаиләдә аңлату эшен алып барырга туры килде. Шулай сыйныфлар тупладык.

**– Сыйныф белән генә ерак китә алмыйсың бит...**

– Радиода эшләүче Алексей Орлин янына бардым. Ул - Казанда укып чыккан, бик акыллы егет. Радио аша татар һәм урыс телләрендә мәчет төзү нияте турында сөйләдем. Бу беренче мәртәбә зур аудиториягә мөрәҗәгать итү булды.

**– Болар барчасы да – мохит тудыру. Мәчет салуны конкрет нәрсәдән башладыгыз?**

– Мәчет салу җирдән башлана. Бу мәшәкатьне үз өстенә Али Тугушев алды. Аңа Ирек Сыйтдыйков һәм бабайлар да булышты. Шулай итеп, Ларин урамындагы 22нче, 23нче, 24нче йортлар мәчет биләмәсенә әйләнде.

Али Тугушев "Туган тел" җәмгыятендә икенче урынбасар иде. Ул Уфадан мәчеткә проект алып кайтты. Аны бабайлар кулына тапшырды. Шуннан чын төзелеш башланып китте.

Мин эшли торган мәктәпкә бер төркем бабайлар килде. Габдулла хәзрәт миңа: "Балам, җирне дә алып бирдегез, проектны да кулга тоттырдыгыз. Төзелеш артыннан чабып йөрергә бер кеше кирәк бит. Роза, шул мәшәкатьне үз өстеңә ал әле", диде.

"Туган тел" утырышын җыеп, тагын киңәштек. Хисле чыгышлар күп булды. Ә үз өсләренә алучы юк. Бабайлар да шомга төште, чөнки ул елларда җирне башта бирәләр, аннары тартып алалар иде. Ризалаштым.

Ул елларда Ставрополь районының баш архитекторы булып Ринат Бикташев эшләде. Ул мондый фикер әйтте: "Әйдәгез, АвтоВАЗның генераль мөдире Владимир Васильевич Каданниковка хат язабыз. АвтоВАЗда эшләүче Ирек Кәримовка айлык эш хакын түләп торсын, ә ул мәчет төзелеше белән генә шөгыльләнәчәк". Халкым: "Әйткән сүз – аткан ук", ди бит. Хат яздык. Озак көттерми җавап та килде.

**Тольятти җирлегендә беренчеләрдән булып "Туган тел"дә җиң сызганып эшләделәр**

Әхмәдиев Исмәгыйл
Әминев Исмәгыйл
Әминева Әлфия
Әминев Әхмәт
Әминев Фәезхан
Аблатипова Наилә
Вәлиева Лилия
Гыйлаҗева Рәшидә
Гыйниятова Хатиҗә
Зыятдинов Фәрһәд
Зыятдинова Миннури
Зәһретдинов Наил
Зәһретдинова Халидә
Заһидуллина Роза
Зыятдинов Тәлгат
Исмәгыйлев Кирам
Кәримова Роза
Кәримов Ирек
Латыйпов Габбас
Мөһитова Миннегөл
Насыйрова Луиза
Насыйров Наил
Нурмөхәммәтов Рәшид
Сыйтдыков Ирек
Саниева Гөлшат
Тугушев Али
Туймакаев Равил
Хәйруллин Хәким
Хәйруллина Тәнзилә
Хуҗакаев Сәгыйт
Хөсәенов Нурислам
Хисаметдинов Харис
Чумаков Рәфыйк
Ярмиев Нурмөхәммәт

Каданников безнең фикерне хуплады. Ирек төзелеш мәйданында мәш килде, кичләрен икәүләп, шәһәр буйлап, офисларда очрашулар үткәрәбез. Кем нәрсә белән, ничек ярдәм итә ала төзелешкә.

Мин алдан телефон аша әзерлек эшен алып барам. Сөйләшү сәгатен билгелим. Бизнестагы, аңа якын һәр татар кешесен барлап, барчасы белән дә очрашам. Алар бик төрлеләр бит. Холыклары, тәртипләре төрле. Йөрәкләрендә милли хисләре булмаганнарына тулы бер лекция укып чыгасың.

Һәр очрашу – ул йөрәгеңне сыгу, үзеңне сындыру, стресс алу. Алла язмасын кеше каршына барып, нәрсәдер сорап йөрергә. Моңардан да авыр нәрсә юк. Байлар байлардан сорау – ул әле табигый. Ә менә хәерче мәктәп укытучысы акча сорап бара байларга. Аның башына әллә нинди уйлар килүе бар бит.

**Күпләп матди һәм рухи ярдәм итүчеләр:**

Шәһәр мэры Сергей Жилкин
"ВАЗ" генераль директоры Владимир Каданников
Габдулла Гәйнетдинов
Шамил Диниулов
Сөләйман Утюшев
Әсхәт Хәмгыйлев,
Әсхәт Хәлиуллов,
Урал Шәрипов,
Мәкатдисә Зөнәгетдинова,
Сабирҗан Әюпов,
Мөдәррис Исмәгыйлев,
Минхәер Ишмөхәммәтов,
Шәүкәт Әхмәтҗанов,
Әсгат Билалов,
Гакыйл Якупов,
Марат Латыйпов,
Хафиз Моталлапов,
Марат һәм Линар Булатовлар,
Фәнис Шәйхетдинов,
Бари Миначетдинов,
Фәнил Зиангиров,
Салават Хөснетдинов,
Рафаил Вәлиуллов,
Рәфис Шакиров җитәкчелегендәге "Агрострой" фирмасы,
Рөстәм Әсфаганов,
Владимир Кожухов.

**– Төрле холыклы, төрле биеклектәге байларны ничек берләштерә алдыгыз?**

– Бәлки, хатын-кыз һәм укытучы булуым да тәэсир иткәндер. Ходай Тәгалә кешесенә карата сүзен дә исемә төшереп торды. Һәрберсенә аңлата идем. Барчабыз да балалар үстерәбез. Милләтебезнең киләчәге, телебез һәм динебезнең язмышын бәйнә-бәйнә сөйләргә, һәр офиста вәгазь укырга туры килде.

Аллага шөкер, күбесенең күңеле әле динебез Исламнан бизмәгән иде. Мин аларга татар баласының үз милләтенә хезмәт итәргә тиешлеген төшендерә алдым. Тик мәчет аша, тик телебез аша гына халкыбызны күтәрә алабыз, татарны милләт буларак саклап кала алуыбызны аңлата алдым.

Гаҗәеп зур эшләр башкарылды. Бергә чапкан бабайларның күбесе инде мәңгелеккә күчте. Урыннары оҗмахта була күрсен. Эшкуарларның да төрлесе төрле якка таралуы мәгълүм. Элемтәдә торучылары да бар.

**– Мәчет ачу тантанасы ничек узды?**

– 1997 ел. 9 февраль. Ураза бәйрәме көне. Тольятти шәһәрендә беренче мәртәбә мәчет ачылды.

Абдул-Кәрим хәзрәт Тәҗетдин Коръән укыды. Тантананы мин үзем алып бардым.

**– Бүгенге көндә Тольяттиның татар милли хәрәкәтендәге милли әйдаманнарны ничек бәялисез?**

– Милли хәрәкәткә өр-яңа буын килде. Булдыклылар. Алар өчен шатланып торабыз. Һәр заманның үз авырлыгы, үз проблемнары. Безнең чорда да шәһәр түрәләре белән мөгамәләбез яхшы иде. Алар безне, без аларны аңлашып яшәдек. Башкача мөмкин дә түгел.

Түрәләр арбасына утыра алу – бик читен эш, ә инде шунда үз җырыңны җырлау тагын да читенрәк. Заманында утыра да алдык, үз җырларыбызны көйли дә алдык, Аллаһыга шөкер. Мәчет төзелде. Мөселманнарыбыз тәре шәһәрендә Ислам рухын таратып яши. Тольяттиның борынгы исеме – Ставрополь. Ә ул исем – тәре шәһәре дигәнне аңлата.

Заманында бирегә калмыкларны көчләп чукындырып китереп утырткан булганнар. Еллар белән ул калмыклар тәреләрен калдырып, күбесе качып беткәннәр.

Бүгенге Тольятти мәчетле һәм Ислам нурлы ак шәһәр. Намазга басучылар көннән-көн арта бара. Хәзрәтебез дә сокланырлык. Борынгы болгар бабаларыбызның рухлары шаттыр, Аллаһы теләсә. Алар нигез салган асыл динебез Ислам алар йөргән җирләрдә генә түгел, алар аяк басмаган җирләрдә дә чәчәк ата. Динебез Ислам - киләчәкле дин.

Түгәрәкләп, шуны әйтәсем килә: "Әгәр кеше үзенең эшенә чын күңелдән ышана икән, ул моңа башкаларны да ышандыра ала".


# АССОЦИАЦИЯ СОДЕЙСТВИЯ ТАТАРСКИМ ПРЕДПРИНИМАТЕЛЯМ САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ

Организована в апреле 2011 года. Основная цель создания ассоциации – консолидация татарских предпринимателей для взаимовыгодного сотрудничества, их объединения в рамках единого делового и информационного пространства; содействие в организации новых направлений деятельности; сохранение (возрождение) национально-культурных традиций, самобытности и религии татарского народа.

В руководство Ассоциации избраны авторитетные, успешные предприниматели из г.г. Самара, Тольятти, Сызрань, Новокуйбышевск, Камышлинского и Похвистневского районов.

Председателем правления Ассоциации избран доктор экономических наук **Шакуров Ильяс Гумерович.** Членами правления являются **Галимов И.М., Латыпов Р.М., Хакимова Ф.Ф., Шайдуллин М.И., Киямова Р.Г., Хабибуллова Н.А.**

**Члены Общественного совета:** Абдрахимова М.М., Замальдинов Г.Р., Мухаметшин В.Г., Сафин И.Х., Аюпов Х.М.

По всем вопросам обращаться по тел./факс: **953-56-95, 956-34-33**
E-mail: **Tatbizsamara@yandex.ru** Сайт: **www.samtatdelo.ru**

**АССОЦИАЦИЯ – открытая организация и приглашает предпринимателей к сотрудничеству по разным направлениям бизнеса. В Настоящее время региональные Ассоциации работают в Ульяновской, Оренбургской областях. В Татарстане в 2010 году создана Всемирная Ассоциация содействия татарским предпринимателям.**



Мәчеттә Корбан бәйрәме. 2010 ел

# Энҗеләребезне барлап торыйк

**Самарның Ленин проспектында урнашкан өлкә яшүсмерләр китапханәсе быел үзенең 40 еллыгын билгеләп үтә. Беренче 27 елында аның белән милләттәшебез Разия Гомәр кызы Букина җитәкчелек итте.**

*Эльмира ШӘВӘЛИЕВА*

Шушы китапханәнең сайтын ачып укысагыз, аның астында бердәнбер комментарий күрә аласыз. Ул да булса татар кешесе Илдар Усмановтан:

– Мин өлкә яшүсмерләр китапханәсе белән 1974 елда таныштым. Ленин урамы буйлап барганда зур хәрефләр белән язылган «Өлкә яшүсмерләр китапханәсе» сүзләрен күреп алдым һәм, бер дә икеләнмичә, иркен һәм зур бина ишеген ачып кердем. Анда нindидер эшлекле, шул ук вакытта җылы, йөрәккә ятышлы атмосфера хөкем сөрә иде. Шундук язылаcы, аның тыныч китап уку залларында үз кеше буласы килеп китте.

Мин шулай эшләдем дә. Әмма, хыялланганча, тыныч кына китап укып утырулар сирәк туры килде, чөнки атна саен уздырылучы шагыйрьләр, язучылар белән очрашулар, музыка коллективлары куйган концертлар, конференцияләр, диспутлар һәм башка чаралар яшь буын вәкилләрендә зур кызыксыну тудырып, заллар гел тулы була иде.

Еллар үтте. 1983 елда миңа, инде Волжский яшүсмерләр колониясендә тәрбияче булып эшләгәндә, тагын китапханәгә керергә насыйп булды. Анда эшләүче танышларым белән сөйләшеп киттек, бирeдә үткән бәхетле яшьлегемне искә төшереп алдык. Кинәт башыма бер уй килеп, безнең колониядә тәрбияләнүче яшүсмерләр өчен дә шигърият кичәсе уздыруда булышуларын сорадым. Китапханә мөдире Разия Гомәр кызы Букина моңа бик шатланып риза булды.

Билгеләнгән вакытта без Елга порты янында очраштык. Китапханәчеләрнең кулларында магнитофон, проигрыватель, китаплар... Елганы кичкәч, Рождественода безне йөк машинасы көтә иде. Шуның әрҗәсенә төялдек тә, машина сикәлтәле урыннарда сикерткәндә көлә-көлә, колониягә юнәлдек.

Балалар безне мич ягып, клубны җылытып, көтеп торалар иде инде. Шундый матур кичә булды бу! Ничек итеп тәртип бозарга дип карап кына торучы яшүсмерләребезнең күңелендә бу көнне нindидер рухи чәчәк бөреләнгәндәй булып китте. Алар тормыш матурлыгын, әдәбият тирәнлеген, тел байлыгын аңладылар сыман. Колониядә тәрбияләнүчеләрнең соравы буенча, бу кичәләрне берничә тапкыр уздырырга да туры килде әле.

Мин үземнең һәм ул вакытта колониядә тәрбияләнүчеләр исеменнән быел 40 еллык юбилеен бәйрәм итүче китапханәне котлыйм һәм, соңлап булса да, аның элеккеге директоры Разия Букинага, бүгенге директоры, ә ул вакытта гади китапханәче булып эшләгән Светлана Косолаповага һәм барлык хезмәткәрләренә чиксез рәхмәтләремне җиткерәм...

Менә нindи җылы, чын йөрәктән чыккан рәхмәт сүзләре бит. Соңгы унөч елда пенсиядә яшәүче һәм җитмеш яшьлек юбилееның бусагасында торучы Разия Гомәр кызы Букинага бүген шушы сүзләрне ишетү – яратып, бөтен күңелен биреп эшләгән эшенә зур бәя бирү була түгелмени?

Ә санап карасаң, мондый сүзләрне әйтүчеләр бихисап. Менә Разия Букина турында мәкалә язуымны белгәч, тормыш иптәшем дә аңа үзенең рәхмәт сүзләрен җиткерергә ашыкты. Җитмеш бишенче елда трамвай-троллейбус клубында Александр Матяев җитәкчелегендәге классик гитаралар

ансамблендә уйный иде ул. Әле күптән түгел генә оешкан һәм популярлык яулап өлгермәгән ансамбльгә китапханә сәхнәсен биреп, тулы зал халык җыю – Самарда гитара музыкасын популярлаштыру эшенә саллы өлеш кертү иде бит ул. Разыя ханым кебек алга карап фикер йөртүче кешеләр булганга күрә, хәзер Самарны Россиянең гитара сөючеләр каласы, дип атыйлар. Чит илләрдән гастрольләргә килеп йөрүче музыкантлар да безнең филармония залы тулы булуга бик гаҗәпләнәләр. Шушы популярлыкның яшүсмерләр китапханәсендә башланганын белсәләр иде алар!

Дөрес, беренче вакытта яңа ачылган китапханәнең үзен дә таныту кирәк булган. Моны яхшы аңлаган яшь директор һәм аның дүрт кешедән


Валерий Афанасий улы Букин, инженер-конструктор.

торган кечкенә генә коллективы мәктәпләргә, техник училищеларга, институтларга, заводларга йөреп, халыкны китапханәгә килергә өндиләр, анда кызыклы чаралар уздырылып торуы турында сөйлиләр, методик үзәк буларак, аның фонды байлыгы турында да әйтергә онытмыйлар. Бу эшнең нәтиҗәсе бик тиз күренә: тиздән яшьләр ташкын булып агыла башлыйлар һәм үзләренә бирегә белем дөньясы, иҗади фантазия, рухи байлык чыганаклары ачалар.

Разия Букина җитәкчелегендәге китапханәнең эшчәнлеге беренче көннән үк укучылар мәнфәгатьләренә буйсындырыла. Чөнки яшьләр, тормыш авангарды буларак, гел яңалыкка омтылалар. Шуңа күрә китапханәгә дә, әйдәп баручылар санында булу өчен, яшьләр оешмалары белән бәйләнештә булырга туры килә. Анда гел яңа идеялар һәм башлангычлар туып кына тора. Шундый чараларның берсе – «Татар китабы бәйрәме». Аны үткәрү өчен Самарга Татарстан Республикасының яшүсмерләр китапханәсе кунакка чакырыла. Казанлылар «Дуслык күпере» форматында уздырылган бу чарага китаплар, кассеталар, картиналар төяп килгән теплоходтан төшеп, шәһәр белән танышалар. Аннары хезмәттәшләр эш буенча аралашар, биредәге китапханәчеләр кунакларга үзләренең татар китаплары күргәзмәсен күрсәтәләр, эш тәҗрибәсе белән урталашалар. Ә соңында Татарстанның «Алтын каләм» конкурсында җиңү яулаган яшь әдипләрнең чыгышларын тыңлыйлар, ул вакытта бик популяр булган Искәндәр Биктаһировның концертын карыйлар.


Разия (курчак тоткан) әнисе Мөнибә, сеңелесе Мөршидә, бертуганнары Әхмәт һәм Госман белән.

Ә 1998 елда, махсус шушы программа өчен Сорос фондыннан акча бирелгәч, биредә «Төрле милләт яшьләренең аралашу үзәге» дә ачыла. Татар яшьләре, мәсәлән, «Яшь язучылар клубы»н оештыралар. Аның җитәкчесе Фәрхәт Мәхмүтов белән бергә китапханәчеләр якташ шагыйребез һәм рәссам Гакыйль Сәгыйровка, Самарның танылган рәссамы Нурхәтим Биккуловка багышланган кичәләр, мөфти Вагыйз хәзрәт Ярullин, ул вакытта «Радио – 7» редакторы Шамил Баһаутдин кебек кешеләр белән очрашулар, Булгар җирләренә сәяхәт итү кебек чаралар уздыралар. Разыя ханым Фәрхәт Мәхмүтовның оештыручы ролен аерып күрсәтте – сәләтле, акыллы, тәртипле, яшьләр арасында абруй яулаган кеше, дип бәяләде ул аны. Әйе, Фәрхәт бүген дә татар яшьләре, татар иҗтимагый оешмалары өчен бик күп файдалы эшләр башкара.

Кырык ел дәверендә яшүсмерләр китапханәсе башкарган эшләрне санап үтүе дә кыен. Китапханәнең 30 еллыгына багышлап чыгарылган «Библиоstory» китабын укып чыгу өчен генә дә миңа өч кич кирәк булды. Ә калган ун елда башкарылган эшләрен санасаң?..

Китапханәнең беренче директоры Разия Букина биргән темп, ул өйрәтеп калдырган эшләр әле бүген дә дәвам итә. Китапханә, интернет чорына яраклашып, укучыларына төрле форматтагы китаплар тәкъдим итә, шулай ук чаралар үткәреп, учреждениене укучылары өчен кызыклы итү өчен көрәшә.

Ә милләттәшебез төрле сәбәпләр аркасында 56 яшендә лаеклы ялга чыга. Тулы көчкә чабып баручы тулпар атка туктавы ничек кыен булса,


Разия студент чагында



Разия ханымга да ялга чыгуы авыр бирелә. Ул башта бик күңелсезләнә, әлбәттә. Ташып торган энергиясен, ике институт тәмамлап, гомере буе китап арасында яшәп туплаган белемен кая куярга белмичә аптырый. Ләкин аның тугры дусты, авыр вакытларында җилкәсен куеп, бөтен эшләрендә дә ярдәм итүче тормыш иптәше Валерий Афанасьевич, кызы Жанна һәм оныклары Юлия һәм Марат аңа бу авырлыкны җиңәргә булышалар. Мин Жанна белән очрашып, әнисе турында берничә сүз әйтүен үтенгәч, аның күзләре очкынланып китте: «Мин әнинең эш һәм өй арасында өзгәләнүен яхшы хәтерлим. Ул бөтен эшкә дә чын күңелен биреп эшли, һәм башкача булдыра да алмый иде. Ничек барысына да өлгергәндер, белмим.

Шундый тыгыз эш графигы һәм өй эшләре арасында ул әле француз телен өйрәнергә дә өлгерә иде. Өйдә француз телендәге китаплар, сүзлекләр, пластинкалар, нindидер карточкалар пәйда булды. Мин кечкенә чакта аның бу мавыгуына сәерсенеп карый идем. Ә хәзер аңладым. Шул вакыттан бирле 30 ел гомер үтте, һәм минем өемдә дә китаплар, сүзлекләр, дисклар һәм карточкалар пәйда булды... Мин дә, ниһаять, инглиз телен өйрәнүгә алындым.

Илдә үзгәртеп кору чоры барганда өскә – кием, ашарга – ашамлык булмаганда да әнием барысыннан да матуррак киенә, тәмле ашлар пешереп ашата иде. Аның шкафында күп урынны шләпәләр, шарфиклар, брошкалар алып торды һәм тора да. Ә күзләренә сөрмә ягуда мин аңа әле дә тиңдәш була алмыйм. Хәзер инде минем кызым да буйга җитеп килә, һәм аңарда көннән-көн ачыграк булып әбисенең матур чалымнары күренә...

Элек фитнес заллары юк иде бит әле бездә. Ә исән, көчле, сыгылмалы булу теләге ул вакытта да булгандыр. Көчле рухлы кешеләргә моның өчен киртәләр юк. Иртән йөгереп керү, аннары гимнастика ясау, атнасына бернichә мәртәбә йога белән шөгыльләнү әле дә безнең әти белән әнинең көн тәртибеннән төшми. Әни «хәрәкәттә – бәрәкәт» принципы буенча яшәде һәм яши дә. Кайчакта без бу темага шаяртып та алабыз, әмма ул беркемгә дә карамый, үз эшен дәвам итә. Чөнки аның тормыш планнары әле дә зурдан. Ул бит хәзер шигырьләр



*Оныклары Юлия...*

иҗат итә.

Ә оныклар белән шөгыльләнүне тормышының иң мөһим эше, дип саный. Тик ул аларга сокланып карап кына утырмый, гел нindидер чараларга, музейларга, түгәрәкләргә йөртеп, рухи тәрбия бирә. Әбиләре аларны ярата дип әйтү генә аз. Ул аларга бөтен күңелен бирә», – дип сөйләде.

Әйе, рухы һәм тәне сәламәт, тел байлыгы, тормыш тәҗрибәсе булган кешенең башы эшләми тора алмый. Менә Разия ханым да башта эшсез калу аянычыннан, аннары мавыгып китеп, шигырьләр иҗат итә. Аның ике җыентыгы да басылып чыккан инде. Кызына, тәрбия темаларына, туганнарына һәм, гомумән, яшәеш темаларына язылган юллар арасында иң матурлары гомере буе сокланып, сөеп яшәгән тормыш иптәшенә – Валерий Афанасьевич Букинга багышланган.

*Я живу, когда ты только рядом,*
*Никого в этой жизни не надо.*
*Нет тебя, ты опять вдаль уехал.*
*Дом молчит, нет ни звука, ни смеха.*
*Мы в разлуке, но знай, мое счастье,*
*Никому не отдам своей страсти,*
*Я останусь тебе верной самой*
*Твоей лучшей, прекрасной гранд*
*дамой.*

*Не сомкнутся пока мои веки,*
*Ты мой рыцарь всегда и навеки.*
*Это лучшая в мире награда -*
*Согреваться в лучах твоих*
*взглядов!*

...Интеллигент яшьләр кая очраша ала дип сорасагыз, филармониядә, дип бертавышка җавап бирерләр иде алар. Алтмышынчы елларда Куйбышевка концерт белән танылган пианист Святослав Рихтер килгәч, билетлар, әлбәттә, булмый. Озын чиратта басып торучы Валерий кызны шундук күреп ала. Үзе чибәр, үзе килешле итеп киенгән, күзләре нур чәчеп тора. Кыз билет сатучының тәрәзәсенә шакып: «Син Данияме? – дип сорый. – Дания булсаң, син минем апайның дусты бит. Зинһар, бир инде миңа бер билет», – дип үтенә, һәм кассир хатын түзми, бирә. Биленә кадәр касса тәрәзәсенә кереп китеп, беркем дә ала алмаган дефицит билетны алып чыккан кызны күзәтеп торган Валерий сокланып: «Бу кыз минем хатын булырга тиеш», – дип уйлап куя. Ходайның бармак белән төртеп күрсәтүе булган, күрәсең. «Бер генә минутка да рус милләтендәге Валерага кияүгә чыгуыма үкенмәдем. Чибәр, акыллы, ярдәмчел кеше минем ирем. Ул булмаса, китапханәм дә бул-



*...һәм Марат*

мас иде. 27 ел буена «Кузнецов» оешмасында конструктор булып эшләгән акыл иясенә китапханәбезгә ярдәм иткәндә гади хезмәтче дә, йөк ташучы да, водитель дә булырга туры килде. Ә аның акыллы фикерләре эшемдә күп ярдәм итте», – дип сөйләде тормыш иптәше турында Разия ханым.

Китапханә директорына еш кына Мәскәүдә һәм зур илнең башка шәһәрләрендә үткәрелгән семинарларда, конференцияләрдә, юбилей чараларында катнашырга туры килә. Шундыйларның берничәсе аның күңелендә тирән эз калдырган. Мәсәлән, Мәскәүдә уздырылган Рәсүл Гамзатовның юбилее. Зур бинаның икенче катында урнашкан залда булачак очрашуга ашыгучы халык ташкыны баскычта кулын тотып утыручы кызны күрми, ага да ага. Разия ханым гына иелеп, ни булды, дип кызыксына. Кыз йөгереп төшкәндә абынып егылган да, баскыч тоткычындагы тимергә бәрелеп, кулын ярган. Ярадан аккан канны туктатыр өчен Разия куллары белән пасслар ясый башлый. Ул моңа «Эрудит» түгәрәгендә экстрасенс курслары үткәндә өйрәнгән, һәм үзендә дәвалау көче ачкан. Бераздан кан агуыннан туктый, һәм кызчык бу дәвалаучы апаның кем икәнлеген, ничек шулай дәвалый алуы турында сораша башлый. Разия ханым елмаеп, кызны башыннан сыйпый да, бер сүз дә әйтмичә, очрашу залына ашыга.

Рәсүл Гамзатовның юбилей кичәсе аңарда шундый тәэсир калдыра ки, шул мизгелдә аның башында шигъри юллар туа, һәм ул аларны Гамзатовка укып багышлый. «Мин үзем күп хатын-кызларга шигырьләр яздым, ә Сез, Разия ханым, миңа шигырь багышлаган беренче хатын-кыз», – дип, рәхмәтләрен әйтә танылган шагыйрь.

Ә Кайсын Кулиев белән очрашу Кавказда, Нальчикта үткән киңәшмә вакытында була. Разия Гомәровнаның татар кешесе икәнен белгәч, Кайсын Кулиев аның белән татар телендә сөйләшә башлый. Аптырап карап торган хатынга: «Без бит барыбыз да болгарлар, Кобрәт хан нәселеннән чыккан токымнар», – дип, безнең татар түгел, болгар икәнебезне аңлатып бирә. Шуннан бирле Разия ханым Идел буе татарларының тарихы, Чыңгыз хан явы белән кызыксына, бу турыда күп әдәбият укый. Шул белеме аның


Кияеве Рафаэль һәм кызы Жанна

әле яңа гына каләм астыннан чыккан «Мистер хан» поэмасына да салынган. Ул миңа поэманың беренче юлларын гына укып күрсәткән иде:

*Сколько лун ты проплакала*
*Всеми брошенная Оэлун,*
*Как ушел или в ад, или в рай*
*Твой единственный муж Есугай...*
*Написали тебе на роду:*
*«За красавца пойдешь, Чиледу,*
*После свадьбы поедешь домой,*
*И тебя украдет там другой».*
*Для охоты заехал в тот край,*
*И в возок заглянул Есугай,*
*Он пронзен был твоей красотой,*
*И помчался дорогой крутой*
*Крикнул братьям: «Седлайте коней!*
*Отобьем, только быстро, за ней!»*
*Чиледа был как воин хорош,*
*Но куда от троих ты уйдешь?..*

Поэманың җыр кебек яңгыраган юллары матур бит, әйеме? Тик китапны бастырып чыгарырга пенсионерларның акчасы аз шул...

...Җитмеш яше тулып килүенә карамастан, Разия ханым әле дә бик актив тормыш белән яши. Аның шушы энергиясен, белемен, тормыш тәҗрибәсен татар оешмалары эшенә җигеп җибәрсәң, үсеп килүче яшь буын татарларына нинди үрнәк булыр иде! Разия апа кебек татар зыялылары, кызганычка, сирәк туа һәм татар җәмәгатьчелеге аларны беркайчан да күз уңыннан чыгармыйча, энҗе бөртеген саклаган кебек сакласа иде.


Китапханәдә милләтара аралашу үзгән ачу мизгелләре

# УЛЬЯНОВСКИЙ ЦЕНТР НАЦИОНАЛЬНОЙ КУЛЬТУРЫ ОТКРЫТ ДЛЯ ВСЕХ

***У этого дома – особая притягательная сила. Расположенный на одной из самых оживленных улиц Ульяновска – проспекте Нариманова, он стал своим домом для тысяч татар, населяющих город на Волге. Здесь, начиная с самого парадного подъезда с величественным памятником основоположнику татарской поэзии Кул Гали до просторного фойе, зрительного зала с большой сценой, музея татарской культуры и просвещения, многочисленных студийных и репетиционных комнат, царит неповторимый, присущий только нашему народу яркий национальный колорит…***

***Ирек РАУФОВ***



*Директор ТКЦ Р.Х. Сафина всегда рада гостям*

**В ЕДИНОЙ ДРУЖНОЙ СЕМЬЕ**

Кинотеатру «Октябрь», как и другим подобным «нерентабельным» объектам, в постперестроечном хаосе была уготована незавидная участь. Кинопрокат рухнул, оставив пустовать и разрушаться выстроенные в советские времена кинотеатры. Одни из них в приватизационной горячке прибрали к рукам деловые люди, открыв в них ночные клубы, торговые точки, офисы, а другие, как кинотеатр «Октябрь», требовавшие немалых вложений для перепрофилирования, остались невостребованными. Городская власть легко рассталась со ставшим обузой для бюджета объектом, передав его в областное ведение. А правительство области, идя навстречу пожеланиям многочисленной татарской общественности, передало здание Областному государственному учреждению культуры (ОГУК) «Центр народной культуры» с целевым назначением для Центра татарской культуры, предварительно проведя капитальный ремонт и реконструкцию всего здания.

– Наш город, как и вся область, многонациональный по своему составу. Татары по численности занимают второе место после русских, – рассказывает заместитель председателя Ульяновской областной татарской культурной автономии Почетный гражданин Ульяновской области Рифкат Файзуллович Ахмедуллов. – У нас 67 населенных пунктов с преобладанием татарского населения или просто татарских сел. Есть и уникальный чисто татарский Старокулаткинский район.

Татары вписали немало страниц в славную историю нашего края. Это – родина великого поэта Габделжаббара Кандалый, выдающегося татарского философа и просветителя Закира Кадыйри, основоположника татарской диалектологии профессора Л.Заляя, народного артиста СССР Г.Шамукова, народного артиста Республики Татарстан Ф.Туишева, основателя первого татарского театра в Симбирске Б.Тарханова, поэтов С.Урайского, Х. Сайфетдиновой-Шаммасовой, С.Сунчалея, Д.Фатхи… У нас свято чтят их память. Достаточно сказать, что пять улиц областного центра носят имена деятелей татарской культуры. Несколько мемориальных досок, установленных в Ульяновске и селах области, напоминают жителям о наших славных земляках-татарах. В 2013 году в области широко отмечался 135-летний юбилей выдающегося татарского просветителя, историка, философа, публициста и общественного деятеля Закира Кадыйри. Прошла научно-практическая конференция, посвященная его жизни и деятельности с участием ведущих уче-






*Памятник Кул Гали на площади перед ТКЦ*



*Губернатор Ульяновской области С.И. Морозов оставил первую запись в книге отзывов музея культуры и просвещения татар Симбирского края*



*Методист ТКЦ Л.Ш. Каримова приглашает на праздник «Сембелэ»*



*За чашкой чая разговор получается душевнее*

ных России и зарубежья, вышла книга «Закир Кадыйри. Возвращение к истокам», блестяще прошла защита кандидатской диссертации Р.К. Вильдановой о З.Кадыйри в Приволжском Казанском федеральном университете. В память о нем установлена мемориальная плита на здании бывшего медресе, а на родине З.Кадыйри в селе Абдуллово Чердаклинского района создана мемориальная зона, там же установлен величественный памятник знаменитому земляку. Правительство области приняло решение о присвоении одной из улиц Ульяновска имени Закира Кадыйри.

Ульяновская татарская культурная автономия пользуется широкой поддержкой областного руководства в деле сохранения и развитии культуры, языка национальных традиций нашего народа, – продолжает Р.Ф. Ахмедуллов. – Открыты татарские гимназии и школы с преподаванием татарского языка, первыми в России начала выходить областная татарская газета «Эмет», транслируются регулярные телевизионные передачи «Чишмэ», работает и свое татарское радио. Есть в городе татарская библиотека. При содействии УОТКА и газеты «Эмет» издаются книги местных авторов. Для них областная культурная автономия учредила две литературные премии – имени Г.Кандалый и С.Урайского. На грант Министерства культуры РТ открыт уникальный музей татарской культуры и просвещения Симбирского края. Понятно, что такое не было бы возможным без всемерной поддержки со стороны областного руководства, которое считает одной из приоритетов своей деятельности развитие национальных культур, сохранение добрых межнациональных отношений. Это подтверждается и тем фактом, что ТКЦ финансируется из областного бюджета.

### ДОМ, ГДЕ СОГРЕВАЮТСЯ СЕРДЦА

Наверное, нет в нашей области человека, который не знал бы в лицо эту миловидную женщину. «Наша Рамиля» – так с любовью и уважением отзываются люди о **Рамиле Хайдаровне Сафиной,** Заслуженном работнике культуры Республики Татарстан, редакторе и ведущей очень популярной в народе телепрограммы «Чишмэ», директоре областного Татарского культурного центра. Человек огромного таланта и обаяния, прекрасный организатор, всей душой прикипевшая к делу национального возрождения, она, как никто более, воплотила в себе лучшие черты татарской интеллигенции.

Хотел написать, «мы встретились с ней в обычный день», но сразу же осекся – в этом Доме обычных дней не бывает, ни один из них не похож на предыдущие. Только что прошел праздник «Сембелэ», до этого встречали высоких гостей из Татарстана и областного правительства на открытии музея татарской культуры и просвещения, неделей раньше прошла межрегиональная конференция учителей татарского языка. Сейчас готовимся к празднику «Каз өмэсе» («Гусиное перо»). На очереди традиционный музыкальный фестиваль «Сембер карлыгачлары» («Симбирские ласточки»)… Не берусь перечислять все мероприятия, проводимые в стенах этого Дома. Приведу только слова уважаемой

в Ульяновске Асии-апа Мулюковой, руководителя женского объединения «Ак калфак»: «Это дом, где согреваются сердца».

Послушаем, что говорит хозяйка дома – наша Рамиля:

– Деятельность Центра татарской культуры широка и многогранна. Я не стану перечислять все мероприятия, организованные и проведенные в этих стенах и за ее пределами – это заняло бы много времени и места в вашем уважаемом журнале. Скажу только, что у нас в 7 клубных формированиях постоянно заняты более 250 человек – активистов и подвижников национальной культуры. Это народный коллектив песни и танца «Сембер», молодежная вокальная группа «Чак-чак», детский вокальный ансамбль «Колокольчики», взрослый и детский танцевальные коллективы, любительский клуб по изучению татарской культуры, шахматный клуб «Ак тулпар». Все кружки у нас бесплатные. Возглавляют их настоящие энтузиасты, прекрасные профессионалы, как Заслуженная артистка Республики Татарстан, Заслуженный деятель культуры Ульяновской области Альфия Рамазанова, хореографы Ирина Хабарова, Юлия Ярославцева. Солист ансамбля «Сембер» Рамиль Сируков стал призером Дельфийских игр России 2010 года.

Мы много работаем над возрождением и развитием национальной культуры, старинных обрядов и обычаев и, конечно же, большое внимание уделяем современному искусству и национальному творчеству. Дом татарской культуры стал методическим центром для работников культуры татарских сел области, мы регулярно проводим с ними семинары и практические занятия. Совместно разрабатываем сценарии проведения различных праздников – Сабан туя, фестивалей, смотров талантов, конкурсов «Татар гүзәле», «Татар егете» и др.



*Председатель УОТКА Р.Ф. Сафин встречает гостей на открытии музея татарской культуры и просвещения*



*В шахматном клубе «Ак тулпар»*

С большим успехом проходят у нас традиционные дни татарской литературы и культуры, выставки местных художников. Вы, наверное, заметили, что особо тщательно мы выстраиваем работу с молодым поколением. Ведь именно молодежи предстоит в дальнейшем определять облик татарской нации. Мы всегда работаем в тесном контакте с молодежной организацией «Яңа дулкын». В целях координации и активизации молодежного движения мы дважды за последние годы провели международные форумы татарской молодежи, в которых участвовали более 1000 молодых людей из нашей области и других регионов РФ. Из мероприятий межрегионального масштаба могу назвать конференцию учителей татарского языка и другие.

В ЦТК проводятся не только татарские праздники, у нас желанные гости представители всех национальностей, проживающих в Ульяновской области. Свои мероприятия в наших стенах проводят представители еврейской, азербайджанской и других общин.

– Для многих жителей города разных поколений Центр татарской культуры стал вторым домом, – сказала методист Лилия Каримова. Достаточно побыть в ЦТК всего лишь несколько часов, чтобы убедиться в истинности ее слов.



*Хыял тамчылары*

# БӨЕК ҺӘМ ЗАТЛЫ ТОРМЫШ КИЧЕРГӘН БАБАМ



***Бабам вафат булуга менә инде 5 ел да үтеп киткән. Кулыма бабамның җыентыгы (альбомы) эләкте. Бу җыентыкта бабай һәм әбинең яшь чактагы фотосурәтләре генә түгел, ә гәҗитәләрдә алар турында язылган мәкаләләр. Ә аларның саны бикхисап! Шул язмаларны укып, бабам турында күп мәгълүмат белдем һәм аның турында язарга исәплӘдем.***

**Гүзәл ӘМИРОВА**

Гыйзам бабай Камышлы районының Иске Ярмәк авылындагы иң актив шәхесләрнең берсе булган. Ул үз авылына күп изге эшләр күрсәткән, гомере буе халык белән аралашып, халыкка хезмәт итеп яшәгән кеше, ә Мәрзия әбием – аның бердәнбере, ышанычы, тераге, киңәшчесе булып гомер кичергән.

1925 елның 26 июнендә Иске Ярмәкнең ярлы крестьян гаиләсендә Гыйзам җиденче бала булып дөньяга килә. Авылда 7 сыйныфны тәмамлый. Теләге һәм сәләте зур булса да, төрле сәбәпләр аркасында аңа укуын дәвам итәргә туры килми.

Биредә узган ачлы-ялангачлы балачаклары, юктан да ямь табып узган яшүсмер еллары – алар өчен иң якты хатирә булып сакланганнар. Аларның йөрәкләрендә тирән эз калдырган ачы сугыш хәсрәтен күрү, окоплар казу насыйп була.

Әнә шул 1941 елның салкын кышында, аякка чабата киеп, Идел елгасының уң ярында окоп казыганда Гыйзамның күзе Мәрзиягә төшә дә инде.

1942 елның февралендә чаклы яшүсмер Гыйзам ачлы-туклы көенә төрле авыр эшләр башкара. Бигрәк тә туң җир казулар интектерә.

Алар шулай ук айлар буена урман кисәләр.

Гыйзам яшьли трактор йөртергә өйрәнеп, соңрак колхоз эшләрендә көнетөне эшли. Бу авыр эшләрне 16-17 яшьлек кызлар, егетләр, картлар һәм балачагалар башкарганын уйласаң, тәннәр чымырдап китә. Мин бәләкәй чакта ул еллар турында әбием безгә сөйли иде:

- Без, олы буын кешеләре, сугышның ачысын татып күрдек. Әлегә хәтле күп еллар үтсә дә, күңелдәге төерләр таралып бетмәгән. Мин үзем Бөек Ватан сугышы елларында, дусларым белән зур кыенлыклар күрдем. Кышның зәмһәрир суыкларында үзем кебек яшь кызлар белән мине Павловка станциясе янында окоплар казырга җибәрделәр. Туйганчы ашарга булмады, аякларыбызга тула оек белән чабата, осләребезгә тузып ямалып беткән бишмәтләр киеп, туң җирне казыдык. Ач-ялангач килеш үсмер кызлар үзләренә гомерлек чирләр алдылар бу суык кышта. Бетләр теңкәбезне корытты.

Авылдаш кызларым сугыштан соң да колхозда хезмәт иттеләр. Хәзер аларның күбесе гүр иясе инде, шулай да без, исәннәр, аларны күз яшьләре белән искә алабыз, сәдакаларыбыздан, догаларыбыздан калдырмыйбыз. Сугыш елларында, окоп казыганда иңгә-иң терәлеп җылынган дус кызларым белән мөнәҗәтләр дә чыгарган идек. Бүген дә шул юлларны күңел түремдә йөртәм.

Әбием окоп казучы кызлар арасында иң кечесе булган. Үз башыннан үткәргән шул вакыттагы кыенлыкларга багышлап шигырь язган:

Җәен-кышын яшел тора
Нараткай дигән агач.
Без авылдан чыгып киттек,
Бәхеткәйләр булмагач.
Ах, авыр да окоп казу,
Бик арыйбыз кич белән.
Көннәр үтә туң җир казып,
Сагындыра кич белән.
Авыр эштән күлмәк чери,
Чабаталар да туза.
Безнең яшьлек гомеребез
Бигрәк заяга уза.

Бу шигырьне җыр итеп тә җырлаганнар.

Сугыш үзенә ир-егетләрне суыра торгач, чират Гыйзамга да килеп җитә. Исән-сау, таза, яшәү дәрте, көче ташып торган егет, сугышта үлеп калуын абайлап, туганнары белән бәхилләшсә дә, аннан кулсыз кайтачагын күз алдына да китермәгәндер.

42 елның декабрендә хәрби комиссарияттан повестка килә.

Ульян өлкәсе Сенгилей шәһәрендә яшь солдатлар курсын тәмамлый, аннары Инза шәһәрендә кече командирлар (сержантлар мәктәбе) курсларында укый.

Белорусс фронтының 81нче укчы дивизиясенең 601нче укчы полк составына җибәрелә. Белоруссия, Украина фронтында сугышта. Белоруссиянең Гомель шәһәрен фашистлардан азат итүдә катнаша.

1944 елның 25 гыйнварында Белоруссиянең Жлобин шәһәре өчен барган дәһшәтле сугышларда сержант Сәлахов каты яралана. Аны сугышчан дусты, якташы, Чулпан авылыннан Кави углы Мингали госпитальгә озата. «Бәлки, җирдә озак ятсам, кан күп югалтып үлгән дә булыр идем, - дип искә ала ветеран. - Ә менә мине үлемнән алып калган Мингали үзе сугышта һәлак булды, кайта алмады», - дип көрсенеп сөйли иде бабам.

Госпитальдә аңа катлаулы операция ясыйлар. Алты ай буена Тамбов, Алма-ата хәрби госпитальләрдә дәвалангач,

“Сугышка яраксыз!” дигән язу белән 19 яшьлек гарип егет 44 елның июлендә туган авылы Иске Ярмәккә кайтып төшә.

Гыйзам бабам сул җиңенең бушлыгына озак күнегә алмаганын бик еш искә ала иде.

Үзендә рухи көч табып, төшенкелеккә бирелмичә, тиз арада ул авыл эшләренә җигелә. Кыр эшләре бетүгә ул фермага эшкә килә. Шунда Мәрзияне очратып, сүзката, һәм алар аралашып китәләр. Ярты ел чамасы очрашып йөргәч, туй ясыйлар.

Шул гомер эчендә баштан ниләр генә узмаган да, ниләр генә кичерелмәгән. Төп йорттан мунча кадәр генә өйгә чыгу, шунда бераз яшәп, йортны зурайту, каралты-кура кору, бәхетсезлек килеп чыгып, ул йортларның янып бетүе, авылдашлары, колхоз ярдәме белән яңа урында яңа өй салулар. Гыйзам ага кулсыз булганлыктан, авырлыкның калын башы Мәрзия әбиемә төшә. Нужаны бергә җигелеп тартканга гына, тормыш авырлыклары җиңелеп бара.

Гел кеше арасында эшләгәнгә, рухи яктан көчле һәм аралашучан булганга, Гыйзам үзенең физик кимчелегенә көрсенми. Мәрзиягә өйләнгәч, трактор бригадасында хисапчы булып эшләгән чагында, 1946 елның язында Камышлыда 6 айлык бухгалтерлар курсларын тәмамлап кайта һәм колхозда бухгалтер ярдәмчесе булып эшли башлый, ә инде 1949 елда аны колхозның баш бухгалтеры итеп билгелиләр. Иң кыен чорда хуҗалыкта хисап эшен алып бару җиңел булмый. Беренче өч балсының бер-бер артлы үлүләре аларны хәсрәт дәрьясына чумдыра.

Мәрзия фермада хисапчы булып эшләвен ташлап, төрле эшләргә күчә, чөнки гаиләдә ун ел эчендә бер-бер артлы дүрт бала туа, аларны карау, йорт тирәсендәге эшләр аның җилкәсенә төшә. Гыйзам һәрвакыт җаваплы урыннарда хезмәт итә. 1953 елдан 1962 елга чаклы Ярмәк балалар йорты бухгалтеры, аннан соң 1977 елга кадәр Коминтерн исемендәге колхозның баш бухгалтеры булып эшли.

Өлкәдә беренчеләрдән булып яңалык – “журнальная система учета” ысулы кертә. Бу Коминтерн исемендәге колхозда исәпнең торышын кискен яхшыртырга мөмкинлек бирә. Байтак колхозлардан аңа тәҗрибә өйрәнергә киләләр. Күп тапкырлар ул районда да, өлкәдә дә иң яхшы бухгалтер булып таныла.

Лаеклы ялга чыккач та, бабам тик тормый. Сугыш инвалиды булуына карамастан, җаваплы эшкә алына, сигез ел газ участогы мөдире булып эшли.

Авылдашларын газ балоннары белән тәэмин итә. Ә аның бу вазифаны ничек башкаруын ярмәклеләр яхшы беләләр. Бередә тәртип урнаша, аңлашмаучылыклар тәмам бетә, иң мөһиме - халыкны газ балоннары белән тәэмин итүдә өзеклекләргә чик куела.

Кайда гына булмасын, нинди генә эшне үтәмәсен, үз вазифасын зур җаваплылык белән, җиренә җиткереп башкару Гыйзамның гадәтенә әверелә. 1987 елда Иске Ярмәктә сугыш һәм хезмәт ветераннары оешмасы төзелгәч, аны ветераннар оешмасы рәисе итеп бертавыштан сайлылар.

Оешма һәм аның советы планлы эшли башли. Гыйзам ветераннарга, аларның мөмкинлекләренә һәм сәләтләренә карап, йөкләмәләр бирә белә, аларның үтәлешен вакытында тикшерә. Яшь буынны патриотик һәм хезмәткә мәхәббәт рухында тәрбияләү бурычларын да истән чыгармый ул. Ярдәмчесез калган картларны һәм карчыкларны утын белән тәэмин итү, алар өчен авылда махсус йорт (интернат) төзү, ветераннарның өйләренә телефон кертү кебек мәсьәләләрне хәл итүдә дә аның өлеше бик зур булган.

Авылның, авыл халкының социаль көнкүреш шартларын үстерүгә көч куя. 1992 елда авылның көнчыгыш өлешендә гипсоблоктан кибет салуны булдыра. Бу - Гыйзам бабамның күп еллар моны юллап йөрү нәтиҗәсе. Еракта урнашкан кибетләргә барып йөрергә вакыты булмаган яки хәле җитмәгән пенсионер картларга һәм карчыкларга зур уңайлык килә.

Күп еллар элек билгесез сәбәпләр аркасында Иске Ярмәк авылы мәчете нигезенә кадәр яна. Озак еллар картлар аерым бер йортка гыйбадәткә йөриләр. Манаралы мәчет булмау аларның күңелләренә тынгы бирми. Картлар яңа мәчет салу турында хыяллана. Авыл советына мөрәҗәгать итеп, мәчет төзер өчен җир-урын алына. Ә бу изге эшне оештыруга Гыйзам бабам алына. Капиталь төзелеш бүлеге аша килешүләр, проект-смета документлары булдыру эшләрен башкара.

Уфада урнашкан Россиянең Европа өлеше мөселманнарының Дини нәзарәте белән элемтәгә кереп, төзелешкә ярдәм итәргә ризалыкларын ала. Мәчет төзүдә авыл халкы зур матди ярдәм күрсәтә.

Өендә ярты сүздән аңлаучы, киңәшчесе, терәге Мәрзиясе булмаса, аңа актив тормыш позициясендә булу бик читен булыр иде. Гаиләдә тынычлык, дүрт балага төпле тәрбия бирү күбесенчә Мәрзиясе җилкәсендә бара. Аңа ышанганга күрә дә, Гыйзам бабам җәмәгать эшләрендә актив катнашып яшәде дә.

Галләм углы Гыйзам Сәлахов түбәндәге дәүләт бүләкләренә ия була:

“Хәрби хезмәттәге батырлыклары өчен” беренче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены, “Жуков”, “Германияне җиңгән өчен” медальләре, Мактау кәгазьләре, “Фронтовик 1944 - 1945” исеме һәм күп данә юбилей медальләре.



# ӘТИСЕНЕҢ КАБЕРЕН ЭЗЛӘП УЗГАН ГОМЕР

***“Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел”, - ди халкым. Әйе, зиратта кабер янында кылган догаларга мәрхүмнең рухы шатлануын истә тотып, кеше берникадәр юаныч ала. Тик тормышта үз якыннары кайда җирләнгәнен белмичә, хәтта аларның каберен дә күрергә насыйп булмаган кешеләр дә бар. Шундыйларның йөрәге тагын да катырак өзгәләнә, хәсрәт тагын да тирәнрәк күңелне тырный. Аларның сүзләренчә, мондый кешеләр үзләрен күк белән җир арасында калгандай хис итәләр. Бигрәк тә сугыш кырларында хәбәрсез югалган солдатларның каберләре әлегә кадәр билгесез булып кала.***

**Миләүшә ГАЗИМОВА**



Чыгышы белән Татарстанның Чирмешән районы, Кармыш авылыннан булган, яшьтән Самарда яшәүче милләттәшебез Габдулла Нотфуллинга да язмыш шундый өлеш чыгара.

Әтисе Нотфулла Хәбибуллин Бөек Ватан сугышына киткәндә 7 яшьлек малай атасы белән аерылырга теләмичә, аны авылдан биш чакрым ераклыкка озата бара. Иренең алдагы билгесез язмышын уйлап, күз яшьләрен түгеп калган әнисен дә юатырга тырыша кечкенә Габдулла. Хәтта ул вакытта 10 айлык кына булган энесе Шәмсулла да әтисенең озакка китүен сизгәндәй бик каты елап җибәрә.

Нотфулла ага балаларын бик яраткан. Ул хәтта улы Габдуллага үз исемен фамилия итеп яздырган. Шулай малай, әтисе кебек, Хәбибуллин түгел, ә Нотфуллин фамилиясен йөртә.



Сугышка киткән әтиләреннән 1945 елның апреленә кадәр берничә дә хәбәр булмый. Ә апрель башларында, ниһаять, озак көттергән хат килеп төшә. Ике аягы да каты яраланып, үзенең Көнчыгыш Пруссиядә госпитальдә ятуы турында яза Нотфулла ага. Ә соңрак килгән тагын бер хатына хәтта яраланган солдатның каны да тамган була. “Инде үземне бүтән күрә алмасагыз, каныммы гына булса да күрегез”, - дип, тиздән үләсен сизептер инде, якыннары белән хушлаша ул. Һәм шуннан соң билгесезлек...

Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Габдулланы эшчеләр әзерли торган мәктәпкә (ФЗО) алалар. Кемеров өлкәсендә тау сәнәгате (промышленность) мәктәбендә укыгач, аны Ерак Көнчыгыштагы Приморский краенда урнашкан Артем шәһәренә шахтага җибәрәләр. Биредә өч ел эшләгәннән соң, туган җирләренә әйләнеп кайткан егетне 1955 елда армия сафларына алалар.

Азәрбайҗандагы Кусары шәһәрендә авиамеханиклар мәктәбен тәмамлый ул. Аннан солдатны Орел шәһәренә җибәрәләр. Знче гвардия полкында башта самолет механигы, аннан өлкән механик, техник булып хезмәт итә Габдулла. Яхшы хезмәте өчен аның фотосурәте Мактау тактасында эленеп тора. Нотфуллинның званиесе югары булмаса да (кече сержант), аңа җаваплы вазифалар йөклиләр.

Армиядән соң, егет Куйбышев (бүген Самар) шәһәренә килеп урнаша. Әнисе Мөшәрәфәне (ул бик динле, укымышлы кеше була) һәм Шәмсулланы да бирегә алып килә.

Хатыны Сания белән бергә гомер итүләренә дә 54 ел узып киткән инде. Алар өч кыз – Әлфирә, Асия, Лилияне тәрбияләп үстергәннәр. Бүгенге көндә Нотфуллиннарның җиде оныклары бар. Шәмсулла энесе дә өйләнеп, ике кыз үстергән.

Яшь чакта тормыштагы күп кенә кыйммәтләрне аңлап бетермиләр. Шу-

лай 40 яшенә җиткән Габдулла абыйны этисенең кайда җирләнгәнен белмәве борчый башлый. Һәм ул, тәвәккәлләп, аның каберен эзләргә керешә. Күп еллар дәвамында архивларга хатлар җибәрә, башка төрле юлларны да кулланып карый.

Подольскийның үзәк хәрби архивыннан Габдулла абыйга түбәндәге эчтәлекле җавап хаты килә:

“Этиегез 1945 елда Польша җирендәге Бартошица шәһәрендә каты яралардан һәлак булган”.

Шушы хәбәрдән соң, Габдулла абыйның инде сүнеп барган өмете яңадан дөрли.

Кызлары (бигрәк тә олысы Әлфирә бик зур ярдәм күрсәтә), кияүләре, оныклары белән бергә Нотфулла абый каберне эзләп табарга зур көч куялар.

Алар Варшаваның католик чиркәүләренең берсенә ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр. Анда эшләүче атакай Бартошица чиркәвендәге дин әһеленә шалтыратып, белешмәләр алуга керешә. Күп тә үтми, Нотфуллиннарга бу атакайдан хат килеп төшә.

“Миңа бу мәгълүматны биргән Польшаның Бартошица шәһәре чиркәвенең атакае сүзләренчә, анда Кентшинский урамында урнашкан шәһәр зиратында бөтендөнья сугышларында һәлак булган солдатларның каберләренә аерым урын бүлеп бирелгән. Уң яклап, икенче аллеяда, Хәбибуллин Нотфулла исемле кешенең кабере бар. Ул сез эзләгән кабер булырга тиеш”, - дип язылган була анда.





Шуннан соң зур өметләр баглап, бик нык дулкынланып, Габдулла абый юлга җыена башлый. Кызы Әлфирә чит ил паспортларын алу, визалар ясату белән шөгыльләнә. Ә 2013 елның 24 маенда, ниһаять, ничәмә еллар көткән бәхетле көн килеп җитә. Бу көнне Габдулла Нотфуллин энесе Шәмсулла һәм кызы Әлфирә белән сәфәргә чыгып китәләр. Башта Санкт-Петербургка, аннан Калининградка очалар алар. Ә аннан Бартошицага 58 чакрым гына.

Габдулла абыйлар, әле зиратны эзләп тапкач та, андагы 16 солдат кабере арасында кайсысы этиләренеке икәнлеген белә алмыйлар. Шуңа күрә икенче көнне анда Нотфулла Хәбибуллин турында мәгълүмат биргән атакай белән бергә баралар. 1945 елда биредә җирләнүчеләр арасында бер генә мөселман кешесе булуы атакайның хәтерендә калган.

Газиз этиләренең каберен күрсәткәч, Габдулла абый бер үк вакытта шатлыклы да, кайгылы да күз яшьләрен тыя алмый. Зираттагы каберләрнең чисталыгы, тәртиптә тотылуы да куандыра аларны. Тик менә кабер өстендәге тәре генә борчуга сала.

Үзләренә бик зур ярдәм күрсәткән атакай турында исләре китеп сөйлиләр Габдулла ага белән аның хатыны Сания ханым.

- Шушындый игелекле кешеләрне сирәк очратырга була. Ул безгә бер дә авырсынмыйча, зур теләк белән булышты, - диләр алар.

Ерактa урнашкан зиратка барганда машина да сорамаган, Габдулла абый рәхмәт йөзеннән биргән сәдакаларны да алмаган атакай.

2014 елда Нотфулла Хәбибуллинга 100 яшь тулган булыр иде. Ә Габдулла бабайга киләсе елның гыйнварында 80 яшь тулачак.

- Минем юбилейга ничәмә еллар эзләгән этиемнең каберен табу – бик шатлыклы, зур бүләк. Аллаһыга шөкер, хәзер минем дә җаным тынычлана төште, этиемнең рухы аның кабере янында кылган изге догаларга куангандыр, иншаАллаһ.

“Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел” дип, бик дөрес сүзләр әйткән икән халкым, - ди әле бүген дә ачы югалту хисе аралаш бәхетле тойгылар кичерүче Габдулла бабай Нотфуллин.

***Подписывая документ об окончании курсантками школы пилотов подготовительных курсов в Энгельсе, командир женского авиаполка Марина Раскова заметила: «Ольга Александровна Санфирова, 1917 года рождения. Татарка. Может, ошибка?» «Никак нет, товарищ майор, все правильно!» - ответила Ольга.***

*Рашид ШАКИРОВ*



# Свет угасшей звезды

Родилась она 19 апреля (2 мая) 1917 года в г. Самаре в семье рабочего. Здесь и жила до завершения учебы в седьмом классе, испытав все прелести и трудности детско-юношеского возраста, первую влюбленность. В середине 1930-х годов вместе с родственниками переехала в г. Новый Ургенч Узбекской ССР, где окончила среднюю школу.

Перебравшись в Россию, Ольга трудилась на Коломенском машиностроительном заводе Московской области и одновременно занималась в местном аэроклубе, увлекшись, как и множество других молодых людей того времени, авиацией. Отучившись в Коломенском аэроклубе, работала в Управлении санитарной авиации в Москве.

С 1940 года была пилотом Московского отряда специального применения, а затем летчиком-инструктором 78-й учебной эскадрильи Западно-Сибирского управления гражданской авиации в г. Татарске Новосибирской области. 24-летняя девушка обучала молодых парней летному искусству. К тому времени она налетала уже 1500 часов.

Когда началась война, Ольга в первый же день обратилась в военкомат, но ее не призвали. Попасть на фронт помог случай. Герой Советского Союза М. Раскова начала формировать женские авиачасти. По мобилизации ЦК ВЛКСМ пять летчиц из 78-й учебной авиационной эскадрильи были откомандированы в ее распоряжение.

Из Москвы девушек отправили в г. Энгельс Саратовской области. Здесь в военной авиационной школе пилотов (ЭВАШП) они проходили курс теоретической и практической подготовки. Летчиц разделили на 3 группы: истребители, дневные бомбардировщики и ночные бомбардировщики. Ольга попала в третью группу. Ее командиром оказалась Евдокия Бершанская, с которой Ольга познакомилась еще в Батайской авиашколе, где та была инструктором.



*Группа летчиц 46 полка*

Зная возможности и умения выпускницы этой авиашколы, Бершанская ставила девушку в пример другим. Ольга действительно летала хорошо, не терялась, не торопилась. К тому же у нее были организаторские способности, она умела находить общий язык с каждым. Улыбчивая и добрая, при необходимости девушка могла быть строгой и справедливой. Учтя это, Бершанская назначила ее заместителем командира эскадрильи.

14 марта 1942 года Ольга Санфирова вступила в ряды КПСС. Но вдруг – ЧП. Около аэродрома арестовывают человека, у которого находят фотографии самолетов и летчиц. Шпион приручил Дружка – собачку, очень привязанную к Ольге, и, прикрепив к шее собаки фотоаппарат, снимал аэродром. Не успели стихнуть разговоры об этом, как два самолета эскадрильи разбиваются во время ночных тренировок и четыре летчицы погибают. А Ольга с Зоей Парфеновой, которую зам. комэска «вывозила» в тренировочном полете, пролетели под линией высоковольтных проводов и, задев за них, разбили машину. Санфирова попадает в госпиталь. Трибунал в Энгельсе признал виновной ее, поскольку Ольга отвечала за полет, и дал девушке десять лет лишения свободы. Всплыло и то, что Санфирова скрыла наличие

в своем роду богатого дедушки. В итоге, когда 23 марта 1942 года полк улетел на фронт, Ольгу оставили «для подтверждения диагноза».

Командование полка написало письмо начальнику ЭВАШП, в котором просило помочь Санфировой вернуться в полк, чтобы в боях ис-




купить свою вину. И в мае того же года она попала на фронт.

Война для Санфировой началась в 588-м ночном легкобомбардировочном авиаполку (затем он станет 46-м ночным бомбардировочным авиаполком) в период битвы за Северный Кавказ. Вначале она была зачислена командиром экипажа «У-2», чуть позже – командиром звена. Ольга влилась в число «ночных ведьм» – именно так фашисты называли советских летчиц, совершавших ночные боевые вылеты и бомбивших позиции противника на легких «У-2» («По-2»).

Небольшие самолеты бесшумно проникали в неприятельский тыл и, низко пролетая над вражескими позициями, наносили бомбовые удары. Девушки нежно назвали свои машины «ласточками», но широко известное их название – «Небесный тихоход». До войны на нем училась летать молодежь в аэроклубах, и никто не мог подумать, что этот самолетик будут использовать в военных целях. Он был сплошь из фанеры, обтянутый перкалью и имел четыре бомбодержателя под нижними плоскостями.

Лишь под конец войны летчицы получили парашюты, и в кабине штурмана был поставлен пулемет, а до этого не было никакого оружия, кроме пистолетов ТТ.

Каждый вылет на «По-2» был сопряжен с опасностями. Летать приходилось на высоте 400-500 метров. В этих условиях ничего не стоило сбить тихоходные «По-2» даже из крупнокалиберного пулемета. И нередко самолеты возвращались из полетов с изрешеченными плоскостями.

С. Алексеевич в своей повести «У войны не женское лицо» приводит слова штурмана А.С. Поповой: «...Девушки делали по 12 вылетов за ночь. Прилетишь и не можешь даже из кабины выйти, нас вытаскивали».

А штурман Г. А. Беспалова, отметившая в 2012 г. свое 90-летие, вспоминает, как немцы устроили охоту на тихоходы. Как только «По-2» попадал в лучи прожекторов, тут же появлялся «Мессершмитт» и старался сбить «русфанер» вместе с экипажем. За это была обещана награда – 25 тыс. марок.

«В нашем авиаполку было четыре эскадрильи (по десять самолетов в каждой), одна из которых учебная, – говорит Галина Артемьевна. – Всего около трехсот человек, из них восемьдесят летчиц и штурманов. Определенного количества вылетов в задании не было: вылетали, кто сколько мог. Как правило, около пяти раз за ночь, но случалось и больше десяти. Наш груз – четыреста килограммов мелкоосколочных и зажигательных бомб». Фашисты утверждали, что эти женщины – бандиты, выпущенные из тюрем. А они до войны были студентками различных вузов, гражданскими летчиками, комсомольским работниками.

Вместе со своим штурманом Руфиной Гашевой Ольга стала одной из лучших в полку, который был единственной боевой частью за всю историю Великой Отечественной войны, полностью состоящей из женщин.

Когда в феврале 1943 года 46-й авиаполк был преобразован в гвардейский, Ольга стал заместителем командира эскадрильи, а потом и командиром эскадрильи с присвоением воинского звания капитан. Она участвовала в боях за оборону и освобождение Северного Кавказа, в Новороссийско-Таманской, Керченско-Эльтигенской, Крымской и Белорусской наступательных операциях. Не раз экипажу Санфировой приходилось совершать посадки на подбитом самолете и ночами пробираться к своим, где их считали пропавшими без вести. Был случай, когда они добирались до полка трое суток.

Однажды во время разведполета, спасаясь от немецкого истребителя, Ольга посадила самолет прямо на поле. Потом сумела взлететь на нем, спасла офицера штаба.

Санфирова отличалась не только бесстрашием, но и находчивостью. Вот один из случаев: когда бои шли на территории Польши, полк устроили в поместье. От многодневных дождей земля размякла, и твердой площадки рядом с поместьем не хватало для разгона самолетов. Тогда Ольга предложила поднимать самолеты по-другому. Девушки повисали на крыльях и хвосте машины, летчик давал газу, и после этого самолет отпускали. Освободившись от «груза», тот взлетал после короткой пробежки. Используя это «ноу-хау», девушки летали всю ночь.

Ольга не обольщалась своими успехами и никогда не хвасталась пилотажным искусством, да и вообще избегала разговоров о полетах. Если же кто и спрашивал ее: «Как слетала?», она коротко отвечала: «С таким штурманом, как Руфина Гашева, плохо не слетаешь».

А Руфина любила летать с Санфировой. Она не раз в полете восхищалась ее мастерством, умением уходить от опасности. Сколько раз попадали они под свет прожекторов, под огонь зенитной артиллерии врага. Казалось, что нет выхода, что гибель неизбежна. Но выход находили. В минуты опасности Ольга преображалась. Она бросала самолет то вправо, то влево, делала невероятные развороты, искусно маневрировала среди разрывов снарядов. И опасность отступала. Но без ранений не обошлось – однажды осколок попал Ольге в ногу, выше колена.

Комэск всегда помогала молодым летчицам, заботливо

«вывозила» малоопытных штурманов. Будучи справедливым, требовательным командиром, она воспитала десятки летчиц. В детстве боявшаяся темноты, Ольга стала асом ночных полетов.

По характеру требовательная и волевая, внешне она была очень женственна. Ее темно-карие бархатистые глаза излучали ласкающий свет, в уголках губ всегда таилась теплая улыбка. Подруги называли ее по-разному: Ляйля, Лейла, Леля, и девушке это очень нравилось. Даже своей внешностью Ольга напоминала героиню восточной сказки: темные глаза, черные густые кудри. «Лейлу все любили в полку, я даже ревновала ее к нашим общим подругам, – вспоминала Герой Советского Союза Магуба Сыртланова. – Закрою глаза и вижу ее – стройную, с застенчивой улыбкой, слышу ее мягкий, ласковый голос».

Гвардии капитан О. А. Санфирова совершила 630 боевых ночных вылетов на уничтожение живой силы и укреплений противника с боевым налетом 875 часов, сбросила на противника 77 тонн бомбового груза. При этом было уничтожено до двух взводов пехоты, 1 склад, 2 артиллерийские точки, 2 переправы, 5 автомашин, 3 пулеметные точки, вызвано 135 сильных взрывов и 78 очагов пожаров. Разбросала 700 тыс. листовок над расположением войск противника. Для поддержки наших частей, блокированных на Эльтигенском плацдарме, сбросила 25 мешков с боеприпасами и продовольствием. На счету эскадрильи, которой командовала Санфирова, 3270 боевых вылетов.

На гимнастерке Ольги засверкали ордена Красного Знамени, Отечественной войны 1-й степени, Александра Невского и медали.

В ночь на 13 декабря 1944 г. Санфирова совершила свой последний боевой вылет. С штурманом Гашевой она выполнила задачу: бомбы легли прямо на цель – на станцию Носельск к северу от Варшавы. Самолет приближался к линии фронта, когда начался зенитный обстрел. Снаряд попал в бензобак, и «По-2» загорелся. Ольга сумела «вытянуть» машину за линию фронта, но пламя охватило и фюзеляж. Летчицы вынуждены были спрыгнуть на парашютах и приземлились на нейтральной полосе в 800-х метрах одна от другой, но обе – на минные поля. Руфина,



*У знамени 46 полка*



*Инструктаж*

осторожно ощупывая противотанковые мины, доползла до советских позиций. А Ольга, услышав русские голоса, пошла навстречу им, но... наступила на противопехотную мину.

Утром солдаты принесли ее тело, уложили на повозку, накрыли брезентом. У нее была оторвана нога, разворочен правый бок. Похоронить Ольгу решили на советской территории, в городе Гродно. Машину с гробом отважной летчицы сопровождали девять человек.

16 декабря его установили в горкоме комсомола. Сюда потянулись местные жители. Они несли в руках еловые веточки и побеги герани. Под звуки траурного марша двигалась по улицам похоронная процессия. Ее сопровождал «По-2», летевший над самой землей. Могила была вырыта в центре городского парка. На склоненное полковое знамя, на лицо комэска медленно опускались снежинки. Подруги отсалютовали из личного оружия гвардии капитану Ольге Санфировой, любимому командиру, воспитателю, другу.

23 февраля 1945 года за мужество и воинскую доблесть, проявленные в боях с врагами, она посмертно удостоена звания Героя Советского Союза.

Именем Ольги названы улицы в г. Самаре и белорусском Гродно. 8 мая 1985 г. в сквере около самарского Дома молодежи открыта 10-метровая стела героине. Бюст Санфировой установлен в городе Коломна, а на здании аэроклуба – мемориальная доска. На братской могиле в г. Гродно есть плита с именем Ольги, ее имя носила комсомольская организация Гродненской средней школы № 8.

По словам М. Сыртлановой, Лейла писала стихи на татарском языке и заносила их в свой альбом. Вот строчки из ее последнего стихотворения:

***Быть может, я угасну,***
***Как звездочка в ночи,***
***Но будут литься с неба***
***Прощальные лучи.***

Пророческими оказались эти стихи. Свет угасшей звезды... Звезды страны, татарского народа.



Что ж, все правильно, так и есть. Но если мы будем уповать только на судьбу, рассчитывать на ее предопределенность и сами не будем прилежны, организованны, мобилизованы, толку от нашей жизни будет мало. И не видать тогда успеха в виде достойной жизни, авторитета и доброго имени. А вот хорошие исходные данные, помноженные на старания, упорный труд и, может быть, чуточку везения (от судьбы, действительно, никуда не денешься) как раз и дают, как правило, высокий результат.

Эти отвлеченно философские выводы в полной мере относятся к Шамилю Салимгереевичу Хисамутдинову – одному из самых известных представителей



# ДОБРЫЕ ДЕЛА ТВОРЯТСЯ ТАМ, ГДЕ ИХ ДЕЛАЮТ

***Сколько раз в жизни нам приходилось слышать выражение о том, как влияют на судьбу человека его корни. Иногда это называют еще наследственностью или природной предрасположенностью. А еще на ум приходит известная пословица насчет яблока, которое падает недалеко от яблони...***

**Шамиль ГАЛИМОВ**

татарской общественности Самарской области, руководителю преуспевающей строительной фирмы, активному участнику благотворительных акций и спонсору национально-культурных мероприятий. И поэтому рассказ о его становлении как человека, бизнесмена и общественного деятеля совершенно логично будет начать с предков.

... Шамиль застал своих дедов уже в весьма преклонных годах, но с ясной памятью и, конечно, огромным опытом и знанием жизни. Фаляхетдин-бабай (по отцу) был участником Первой мировой войны, Февральской революции в Петрограде (служил в Кронштадте), после этого вернулся в Самару, а потом – в родную деревню Мулловку. Имел блестящее духовное образование, которое получил в Уфе и Бухаре. Его хозяйство было зажиточным, поэтому с началом коллективизации Фаляха Хисамутдинова раскулачили, попал в тюрьму и чудом спасся от ссылки в далекие края. На фронтах Великой Отечественной погибли два сына. После войны несколько десятилетий был в Мулловке муллой, аксакалы вспоминают, что одной только пятничной хутбы (специальной проповеди, которая читается перед главным для мусульман намазом) имел в своем багаже три десятка. Закончил свой земной путь в 102 года.

Такая же славная биография у деда по матери. Шагит-бабай Нураев воевал в 1904-1905 гг. против японцев на Дальнем Востоке, а в 1914 году его призвали га германскую войну. Отвоевал, вернулся на родину. После революции встал на сторону Советской власти, был бойцом знаменитой 25-й Чапаевской дивизии. Он прославился (уже в истории своего родного села) еще тем, что во время эпидемии септической ангины весной 1944 года остался на всю деревню практически единственным трудоспособным мужчиной и, хотя ему было уже больше 60 лет, копал могилы для погребения жертв страшной болезни. Уставал до изнеможения, валился с ног, но продолжал копать – так и схоронил несколько десятков человек. Умер, когда ему было далеко за 90.

Общение с дедами было Шамилю не в тягость. Наоборот: он старался почаще бывать с ними, получить от них как много больше, учил молитвы, внимательно слушал рассказы о былых временах и учился уму-разуму. И еще ухаживал за ними как мог - мытье дедов в бане входило в негласные должностные обязанности Шамиля. Забегая вперед, следует сказать, что позже, когда Шамиль Салимгереевич стал тем, каким мы его теперь все знаем, отец часто повторял: тебе помогают и те добрые дела и благословение дедов. Наверняка это правда.

Отец Салимгерей-ага, 1927 года рождения, солдат последнего военного призыва. Но воевать не довелось, зато служил очень долго – восемь лет в войсках МГБ СССР. В мулловском колхозе был бригадиром, учетчиком, главным экономистом, управляющим отделением, а также председателем сельсовета... Мать, Хадича-апа, кроме повседневной тяжелой физической работы в поле и на ферме, многие годы была вдобавок участковым инспектором Госстраха. Сами работали днем и ночью и детей приучили к тому же.

... После 8 классов восьмилетней школы в Мулловке Шамиля отправили доучиваться в Куйбышев. Почему? А потому, чтобы по-русски лучше научился говорить, поглубже узнал городскую жизнь, в которой придется жить и как можно быстрее сделал первые шаги во взрослую самостоятельную жизнь. Он вообще

всегда был самостоятельным, никогда не полагался на других, жил и живет по принципу: "Пусть будет тяжелее, зато сам, своим трудом".

После досадной случайности не попал на учебу в Ставропольское высшее военное училище летчиков. Прошел все комиссии, и экзамены казались вполне преодолимыми, но вышла путаница с вызовом... Словом, опоздал. Не всегда все удавалось с первого раза: поступил в техникум связи и понял, что ошибся и что это – не его профессия. Оставил после второго курса. Так получалось несколько раз, и не только в учебе и работе. И в личной жизни доводилось отступать и начинать сначала. Ничего не поделаешь – не все зависит от нас. Но то было потом.

А тогда, в восемнадцать лет, появилась первая запись в трудовой книжке - "Издательство "Волжская коммуна" Принят грузчиком". Грузил бумагу и печатную продукцию и ждал, когда заберут в армию. Долго, целых полгода не вызывали, тогда пошел в военкомат сам и сказал: "Хочу служить". В те времена, мы помним, не прошедшие школу жизни в Советской Армии парни считались вроде как не совсем полноценными и заслуживающими уважения меньше, чем те, кто отдал Родине долг.

Для Хисамутдинова служба в артиллерийском полку в Закавказье действительно стала школой жизни. Он прилежно учил военную науку, неистово занимался физподготовкой... Когда пришел в "учебку", весил 64 кг, рост был метр шестьдесят четыре. Через два года соответственно 85 и метр семьдесят восемь. Значит, и здесь два года прошли не зря. Видя, как старается парень, командиры ценили солдата. Сослуживец из Дагестана Султан Магомадов, уходя на «дембель», рекомендовал Шамиля на должность командира взвода.

Строительная профессия для Хисамутдинова началась с самого простого и полезного: после демобилизации он поступил в куйбышевское СУОР-7 плотником. Начальником участка был Джаудат Шарапов (ныне председатель совета Соборной мечети). Освоение же специальности чисто академическим способом – очно, на факультете "Промышленное и гражданское строительство" КуИСИ – продолжалось ровно один курс. "Не мог я, взрослый парень, учиться на деньги родителей, - вспоминает Шамиль Салимгереевич теперь, - не по-мужски было бы это". Пошел работать мастером в стройцех авиационного завода, учебу завершил на заочном отделении. Ценнейший опыт Ш. Хисамутдинов приобрел в знаменитом тресте №11, учился у старших товарищей. Многим секретам научил его, например, уроженец села Ново-Урайкино (Кызылсу) Абдуллажан ага Фахуртдинов, о котором Шамиль Салимгереевич с теплотой говорит до сих пор... В эти годы они строили дома и объекты соцкультбыта в новом Приволжском микрорайоне, на улицах Киевская, Агибалова, воздвигали новые корпуса клиник мединститута. Но не все в жизни бывает по графику и плану...

Ровно двадцать пять лет назад – 7 декабря 1988 года – в Армении случилось страшное землетрясение и за считанные секунды были стерты с лица земли два города Спитак и Ленинакан и множество близлежащих сел, погибли почти три десятка тысяч человек. Братскому народу помогал весь Советский Союз.

В последние дни декабря Шамиль Хисамутдинов и несколько его коллег по тресту «Главсредневолжскстрой» вместе с новогодними поздравлениями получили специальное задание: 2 января вылететь в район бедствия в распоряжение управления «Армюгстрой». Работа в микрорайоне с характерным названием «Малая земля» в условиях человеческого горя, мужества и... многих свидетельств человеческой подлости. Это тоже опыт. Так что у Хисамутдинова и его товарищей в жизни была своя «Малая земля». Их имена, восстанавливавших жилье и объекты соцкультбыта, высечены на мемориальном обелиске в городе Гюмри (бывший Ленинакан).

...Хисамутдинову чаще доводится встречаться и работать с хорошими людьми. Это повелось еще со школьной поры: первая учительница Факия-апа Кимятова, а также - Сахаб-ага Шарипов и многолетний директор школы Юнысабы Зулькарнеев... Все они оказали на Шамиля огромное положительное влияние. Теперь уже почти 15 лет он работает с Зуфаром Гузаировичем Исламовым бессменным главным инженером. И тридцать пять – с Раисом Миннехановичем Нуртдиновым. Солидный и серьезный стаж имеют тесные отношения с Александром Федоровичем Красновым и Александром Петровичем Жабиным, . Габибуллой Рабадановичем Хасаевым (представлять их, думается, не надо). Известный финансист, главный бухгалтер многих крупных предприятий Ильдус Габдрафикович Туктабаев вообще на особом счету: друг детства, восемь лет за одной партой, несмотря на исключительную занятость обоих, обилие произ-



водственных и житейских забот, отношения сохранили первозданную чистоту и непринужденность. Чем вызвано такое постоянство в наше бурное и переменчивое время, догадаться не трудно – открытость, порядочность и, если хотите, верная профессиональная дружба нынче в большом дефиците, и самые умные, практичные и дальновидные стараются их сберечь.

В конце 80-х годов в стране подули новые ветра, и Шамиль Хисамутдинов был в числе тех, кто первым почувствовал их направление и содержание. Чуткий к переменам и в меру смелый, он стал одним из первых членов хозрасчетного строительного объединения при Куйбышевском обкоме ВЛКСМ. В числе инициаторов были также Борис Ардалин, тогда первый секретарь обкома, а в недавнем прошлом председатель Торгово-промышленной палаты и министр правительства Самарской области, Ильяс Шакуров (президент общества «Туган тел» и председатель совета директоров “Ипозембанка”), Минныхан Хасанов и другие.

Через некоторое время – в смутном и противоречивом 1991 году Шамиль Салимгереевич ушел в свободное плавание и создал свою первую строительную фирму “Луч”. Кто посчитает, сколько кирпича и раствора ушло на строительство жилых домов, больниц, общежитий, возведенных рабочими, которые трудятся под руководством Ш. С. Хисамутдинова?! И многие не знают, что строительство – это не только красивые дома, большие окна и запах свежевыкрашенной краски. И только специалисты - что оно начинается с долгих процессов оформления разрешительной документации, рытья котлована, что это грязь, нервы и упорный, напряженный труд. А тут еще непреходящие глобальные проблемы – то дефолт, то мировой кризис, то рецессия… Кто знает, сколько времени, энергии и времени уходит у директора на решение разного рода проблем, которые наваливаются на строительное производство. Сопротивление при этом разного рода обстоятельств почище того «сопромата», который изучается в институтском курсе.

Время показало, что двадцать лет назад тот луч посветил в нужную сторону – все последующие годы наглядно доказали, что курс был выбран правильно. Теперь строительно-монтажная производственная фирма “Элри” - предприятие уже несколько лет носит такое название – одна из наиболее стабильных и эффективных в нашем городе. Скоро, в январе она будет отмечать двадцатилетие. Это - организация нового типа с руководителем нового типа, который в тренингах по системе Дейла Карнеги осваивал организацию строительного дела в условиях рынка, на международных экономических форумах в Германии, Италии, Испании. Иордании, Китае – современные технологии и материалы. Юбилей строительная фирма встречает, как и положено строителям, возводя новые дома – теперь в районе проспекта Металлургов, улиц Советская и Енисейская. Здесь Ш. С. Хисамутдинов и его коллектив строят дома эконом-класса, квартиры, которые действительно стали доступными для сотен горожан.




Не работой и хлебом единым жив человек… Шамиль Хисамутдинов, как наш современник, искренне болеющий за судьбы своего народа, с первых лет национально-духовного возрождения активно участвует в нем. В 1991 году он перечислил в фонд строительства будущей самарской мечети 90 тысяч рублей. Еще теми, советскими. Можно напомнить, что в тот год новая ВАЗовская «шестерка» стоила 16 тысяч.

Ветеран общества “Туган тел” А. К. Надиров вспоминал, как в 1998 году Шамиль Салимгереевич добровольно взял на себя роль координатора финансовой помощи для организации Сабантуя. Это был первый случай, когда с его легкой руки татарские бизнесмены в сборе средств показали небывалую активность, которая не снижается до сих пор. И таких примеров немало – благотворительные акции мечети, взносы для детских домов, помощь ветеранам, инвалидам (независимо от национальности) и так далее. На средства Шамиля Салимгереевича была издана книга о его родном селе, на страницах которой ожила двухсотлетняя история Мулловки. Он постоянно помогает проведению национальных и религиозных праздников. Вот недавно на его средства земляки в Мулловке воздвигли пристрой к мечети. Регулярно средства перечисляются Соборной мечети, на проведение праздников Сабантуй и на другие добрые дела…

Сердце дающего чувствует больше радости, чем сердце того, кто получает – вот исходная позиция человека, который постоянно выделяет часть заработанных средств для нуждающихся.

Дочь Эльмира и сын Ринат, к радости отца, решили продолжить семейную профессию. Эльмира уже добилась немалых успехов, в том числе на международной арене – участвовала в Парижской выставке молодых архитекторов, которая была организована под эгидой ЮНЕСКО.

Ринат осваивал другую часть строительного мастерства не только за чертежной доской на факультете «Промышленное и гражданское строительство» - во время каникул и на практике он работал на объектах. Закончив архитектурно-строительный университет, теперь трудится рядом с отцом. Оба они, как и старший сын Ш. С. Хисамутдинова - Рамиль, пользуются постоянным вниманием и заботой отца, который сделал все, чтобы его дети стали порядочными и хорошими людьми. В последние годы новыми и, наверное, самыми главными адресами любви и дополнительной радостью Шамиля-эфенди стали два внука, возможно, в будущем тоже продолжатели семейной традиции и династии строителей.

… Своих потомков Шамиль Салимгереевич воспитывает так, чтобы не боялись работы, а успеха и счастья добивались трудом, были нужными для своих близких и родных, были им полезны. Пример же того, как строить и вести свою жизнь, у них есть.



# Күңеленең моңлы хисләре шигъри юлларында чагыла

**_Нечкә күңелле кеше генә шагыйрь була аладыр ул. Наилә апа Хөсәенованың шигырьләрен укыганда шундый фикер барлыкка килә. Шулкадәр тирән хисләр, зур кичерешләр, эмоциональ халәт, романтик хыяллар чагыла аның шигырьләрендә!_**

_Миләүшә Газимова_

## Гомер уткән синсез сагышта

_Тәшкән идек инеш буйларына,_
_Табарбыз дип яшьлек эзләрен._
_Безнең эзгә мәңге япкан икән_
_Бөдрә таллар яшел шәлләрен._

_Киек каз юлыннан яуган_
_йолдызларны_
_Әкрен генә кочып алган да,_
_Тибрәндерә инеш-инешкәем_
_Бишегенә салып куйган да._

_Көнләштерен тирә-якта төнне_
_Кочле кулың алды кулымнан._
_Гадәтидәй шул ук тыныч сулыш_
_Яшьлегемдә калган язымнан._

_Оста табиб дәвалаган кебек,_
_Чәчләремнән сыйпап үттең дә._
_Шифа бирдең яраланган җанга,_
_Назлы итеп кочып үптең дә._

_Бер дәшмичә мин сыендым сиңа,_
_Гомер уткән синсез сагышта._
_Хәтерема кагылырга тик син_
_генә хаклы,_
_Газабым да шатлык шул чакта._

"Мин – авыл баласы!" – дип горурланып яза Наилә апа шигъри юлларында һәм аларның күбесе туган ягы – Ульян өлкәсе Иске Мастяк авылының искиткеч матур табигатенә, туганнардан да якынрак кешеләргә әйләнгән күршеләренә, авыл халкына, кадерле туган йортының учагын саклап яшәүче газиз әнисенә багышланган.

Ә инде мәхәббәт темасына күпме шигырьләр язган ул! Аларны укыганда кемнеңдер беренче мәхәббәте исенә төшәргә, кемнеңдер хәләл җефетенә карата сөю хисләре яңарырга, ә әле үз парын тапмаганнарда сөйгән ярларын очратып, бәхет диңгезендә йөзәргә теләк туарга мөмкин.

"Шигырьләрем, сезгә мин җан өрдем", - дип яза Наилә апа үзенең бер шигырендә. Чыннан да, аның күңел байлыгы, йөрәк түрендәге кайнар хисләре шигырьләрендә чагылып җанланалар диярсең. Аларның һәрберсе әйтерсең лә тылсымлылык белән сугарылган. Бу шигъри юлларны бер укысаң, һаман укыйсы килеп тора.

Актуаль мәсьәләләргә, көн кадагына, тормыш проблемнарына да багышлап яза Наилә Хөсәенова. Дин, тәрбия, әхлак, ата-ана белән балалар мөнәсәбәте, тарихи мизгелләр темаларын да читләп узмый ул.

Наилә апа Хөсәеновага шагыйрә буларак кына түгел, ә кеше буларак та сокланам мин. Аның кебек эчкерсез, самими, саф күңелле кешеләр сирәк очрый. Наилә апаны күргәч, кәеф күтәрелеп китә, ул үзенең җылысын, мәхәббәтен җәлләмичә кешеләргә өләшә. Аңардан нур сирпелә, ул тирә-ягын кояш сыман яктырта.



Чибәр, дәртле, тормышка гашыйк, елмаеп кына торучы Наиләапага сокланмыйча, аны чын күңелдән яратмыйча мөмкин түгел. Шуңа күрә аның дуслары да күп, туганнары да үзен үлеп ярата, ә аның белән бер күрешеп аралашкан кешеләрнең бу ханым белән кабат очрашасылары килә.

Наилә Хөсәеновага 15 декабрьдә 55 яшь тулды. Без, татар милли хәрәкәте активистлары, аны чын күңелдән шушы олуг юбилее белән тәбриклибез.

Наилә апаның челтерәп аккан чишмәдәй моңлы күңеленнән агылган илһамы саекмасын иде. Яңа иҗади үрләр сезгә, Наилә апа!

Түбәндә хөрмәтле укучылар Наилә Хөсәенованың шигырьләрен укып, тылсымлы дөньяга чумачаклар.

## Кирәксенми татар үз гармунын

*Эх, юксынып кайтам гармун көен,*
*Ишетермен диеп авылымда.*
*Аны тыңлап үскән яшьлекне дә*
*Очратырмын кебек шул юлда.*

*Юк бит аның моңы, ишетелми,*
*Урамнарда шомлы бер тынлык.*
*Су буенда бака туе гына*
*Шул тынлыкка каршы торырлык.*

*Кайда көең, кайда гармун үзең,*
*Урап чыктым капка төпләрен.*
*Төймәләргә басып, шаян телләреңнән*
*Агылып чыккан бию көйләрең.*

*Син яшисең, бәлки, сарай, келәтләрдә,*
*Бәлки, сандык сине бикләгән?*
*Музейдамы ял итәсең икән,*
*Шулай күпләр сине җирләгән.*

*Кирәксенми татар үз гармунын,*
*Саектырдылармы аның күңелен.*
*Әллә нинди чит, ят тавыш тыңлап,*
*Югалтамы халкым үз-үзен.*

*Әллә инде калды тальян яшәп*
*Печән чапкан урман эчендә.*
*Элек ашлык суккан ындыр киңлегендә,*
*Әллә милләтемнең үлмәс көендә.*

*Йә, бәлкидер, калган аулак өйдә,*
*Кавыштырып ике йөрәкне.*
*Әйдәгезче, эзләп карыйк аны,*
*Белсен иде безгә кирәкне!*

*Табып аны, уятырбыз бергә*
*Йоклап яткан авыл өйләрен.*
*Беләм: халкым сагынып, зарыгып*
*көтә*
*Татар гармунының көйләрен!*

## Сөялләнгән куллар иңнәремне сыйпый

*Мичтән чыккан ипи исе*
*Чолгап алган өй эчен.*
*Әчеләтә пешкән коймагы да*
*Пешерелгән тик безнең өчен.*

*Менә шундый хатирәләр минем,*
*Күзем йомсам, төшә исемә.*
*Балаларым, күз нурларым диеп,*
*Кояш кебек әнием йөзе дә.*

*Ярып пешкән бәрәңгесен куя,*
*Сөтле чәен ясый касәгә.*
*Авыз итегезче урман җиләген, ди,*
*Алып куя балын өстәлгә.*

*Кайнар ипи куя табын өсләренә,*
*Бисмиллә дип кисә икмәген.*
*Ходам, мәхрүм итмә шул*
*хөрмәттән диеп,*
*Авызына каба кисәген.*

*Сөялләнгән куллар иңнәремне сыйпый,*
*Кинәнече сыймый дөньяга.*
*Бала күңеле далаларда, диләр,*
*Юк, минеке - газиз анамда!*

*Күзләремнән шатлык яше тама,*
*Төшергәч исемә шушы мизгелне.*
*Юлга чыгам, әнием, синең янга,*
*Татырга дип, кайнар ипиеңне.*

*Гомерләре озын булсын әнкәйләрнең,*
*Туган җирдә утлар сүнмәсен.*
*Табын тулы хөрмәт булсын һәрбер*
*өйдә,*
*Авылым минем мәңге яшәсен.*

## Авылым картлары

*Авылымнан шомлы хәбәр алдым:*
*Дөнья куйган таныш бер картым.*
*Күз каршымнан үтте шул мизгелдә*
*Алар белән бәйле язмышым.*

*Туфраклары җиңел булсын димен,*
*Нурлы булсын яткан җирләре.*
*Без бер авыл балалары идек,*
*Тик аерды юллар безләрне.*

*Чит җирләрдә узган еллар аша*
*Мин яшәдем сезнең арада.*
*Сезнең белән кичтем кайгы-*
*шатлыкларны,*
*Җан җылыгыз иде янымда.*

*Туган җирнең туфрагына сеңгән*
*Кендек каныбыз, туккән тиребез.*
*Суын эчеп, ипиен ашап үстек,*
*Ислам булды безнең динебез.*

*Һәм шуңадыр һәрбер югалтулар*
*Яра салып китә йөрәккә.*
*Якыннарыма дога кылган чакта*
*Сезнең дә исем минем калебтә.*

*Тыныч ятсын иде сезнең җаннар,*
*Үткән юлыгыз безгә зур үрнәк.*
*Күңелләрдә сез яшәрсез мәңге,*
*Сезнең эздән тайпылмас йөрәк.*

*Тормыш мине чакма ташы итте,*
*Тик шулай да тама яшьләрем.*
*Сез китәсез, хәзер кемнәр дога укып,*
*Җирләр инде авыл кешеләрен?*



# ШИГЫРЬ ЯЗУЧЫ БЕЛӘН ШАГЫЙРЬНЕҢ АЕРМАСЫ НИДӘ?



*Самар төбәгендә поэзия белән кызыксынучылар бар. Шулар арасында әле каләм тибрәндергәннәре дә очрый. Ләкин дә җирле матбугат шигырьләргә урынны зурлап бирә дип, мактана алмыйбыз. Ә бит бу үзенә күрә тел саклауның бер сукмагы. Җыр милләтне ничек сакласа, шигырь дә шулай ук шәхесне әдәбиятка якынайта.*
*Фәрид Шириязданов. Халык катламыннан калкыган ир. Ә инде Иске Ярмәк туфрагында аякка басканлыгын истә тотсак, шагыйрьләр токымыннан, дип әйтәсе килә. Мин аның белән әңгәмә коттым һәм шул сөйләшүнең бер өлешен сезгә дә тәкъдим итәм.*

Шамил БАҺАУТДИН

**– Ир-егетләргәме, әллә хатын-кызгамы шигырь язу җиңелрәк?**

– Женесенә карамый, ул Ходай биргән нигъмәт.

**– Мин икесенә дә бирелгән очракны күздә тотам.**

– Поэзия – ул хислелек. Ул яктан аларда өстенлек.

**– Яхшы шигырь язу өчен нинди параметрлар булырга тиеш?**

– Шигырь язучының теле бай булырга тиеш. Интеллектуал. Тормыш тәҗрибәсе булса, тагын да яхшырак. Коръән таләпләрен үзләштергән шәхес әхлаки кыйбладан тайпылмый.

**– Шагыйрь буларак, Сезгә соклану сыйфаты хасмы?**

– Һичшиксез. Гомеремә дөнья гүзәллегенә, андагы төгәллеккә сокланып яшим.

**– Гүзәллек белән нинди сыйфатны янәшә куяр идегез?**

– Хозурлануны. Офыктагы иртәнге таң нурларына, кызарып кояш баеганга хозурланам.

**– Кайсысы кадерлерәк?**

– Иртәнге кояш нурларын яшәү белән тәңгәлләштерәм, кояш баюны үлемгә. Кояш иңү барыбер күңелгә шом сала. Бу минем шәхсән фикерләрем. Кемдер кояш батуны көтеп ала. Тизрәк йокларга!

Шулай да төннәрен учак ягып, утка карап утырырга яратам. Күңел сафлана һәм йөрәк пакьләнә. Серле шигъри юллар шул мизгелдә туа.

**– "Күңел күзе" дигән нәрсә бар. Ул һәркемдә буламы?**

– Юк. Бу сыйфат – үзе бер хәзинә. Моңа сирәкләр ия. Ул сыйфатка ия булган кешеләр янына башкалар тартыла. Алар кешеләрне ярaталар. Кешеләр дә ул адәмне сөяләр.

"Күңел күз"леләргә яхшы сыйфатлар хас. Шуларның беренчесе – җан сафлыгы.

**– Яраткан шагыйрьләрегездән берсен генә сайлап алыгыз әле.**

– Һади Такташ. "...март җиле җиргә ятып кар ялый". Шул юлларга сокланып бетә алмыйм. Ә "Мокамай" – ул минем яшьлегем гимны.

**– Мин «аракы эчмәсәм, шигырь яза алмыйм», диючеләрне күргән кеше. Сезгә нинди шартлар кирәк?**

– Хисләр ташкыны кирәк. Агымдагы мәшәкатьне онытырга кирәк. Көне буе физик эш башкарсаң, поэтик канатлар күтәрелми.

**– Рифма, ритм дигән нәрсәләр бар. Сүзләрне кирәкле калыбка кертә белү – үзенә бер осталык. Татарда классик шагыйрьләр күп. Шагыйрьләрдән иң авыр аңлаешлысы кем?**

– Дәрдмәнне аңлаган кеше чын поэзиянең нәрсә икәнен белә.

### АВЫЛЫМА КАЙТТЫМ ӘЛЕ

Авылымның саф һавасы
Килешә сулышыма,
Шунда килә гел кайтасы
Күмелеп сагышыма.

Урамының тузаны да
Якын миңа һәрвакыт.
Аны урап узганымда
Күпләр тора баш ватып:

Бу кем инде? Кайдан кайткан?
Кем туганы? Кем улы?
Кемдер бөтенләй оныткан,
Танымады бу юлы.

Кемдер шатланып кул бирә,
Һич танып булмаса да,
Сорашканда күрше-тирә
Хәтерне юлга сала.

Китә зиһенне актарып
Хәтердә казынулар,
Гомернең гүзәл чакларын
Өзелеп сагынулар!

Тезелеп яшьлек еллары
Бер-бер артлы узалар,
Әйтерсең кунак кызлары
Елмаеп кул сузалар.

### АҖАГАН УТЫ

Чикләвекләр өлгергәндә
Аҗаган ут уйната,
Кояш багып төн кергәндә,
Утлы уйлар уйлата.

Әллә гашыйклар утына
Йолдызлар да тартыла?
Парлар янәшә утыргач,
Күк йөзләре тар сыман!

Эч серләрен белергә дип,
Йолдызлар да сузыла,
Җиргә җитә алмыйча тик
Күк йөзенә сызыла.

Бәлки, әле аҗаганда
Яшь йөрәкләр утыдыр,
Мәхәббәтләр яралганда
Уйный күкне тутырып.

## АТ ЮЛЛАРЫ

Күз алдына яшьлек килеп,
Чакыргач болыннарга,
Ат юлыннан үтәр идем
Сихерле урыннарга.

Кызу көнне ат эзеннән
Су ятып эчәр идем.
Җиләкле алан йөзеннән
Чәчәкләр өзәр идем.

Тасмалы ат юлларыдай
Сузылалар хисләрем.
Юкәле тау буйлары да
Чакыралар кичләрен.

Өч тасмалы ат юллары
Боргалана гел бергә.
Тик без генә, җан дусларым,
Таралдык төрле җиргә.

Бәлки инде, ат юллары
Югалгандыр хәзергә.
Шул юлларның сукмаклары
Сызылганнар хәтергә.

Тормыш юлы барышында
Юнәлеш шул бер яклы.
Шул елларның барысыннан
Кадерлим балачакны.

## БӘХЕТ ТОЙГЫСЫ

Бәхет бит ул сөя белү,
Була белү ачык күңелле.
Чын күңелдән көлә белү,
Капласа да болыт күгеңне.

Бәхет бит ул көтә белү
Кыенлыклар үтеп киткәнен.
Сабырлыклар итә белү
Авырлыклар басса җилкәне.

Бәхет бит ул тоя белү
Яшәү ямен, һәрбер мизгелен,
Якыннарың өчен көя белү.
Эшли белү һәрчак изгелек.

Бәхет бит ул тыя белү
Ялган уйлар килсә башыңа,
Зиһенеңне җыя белү
Билгесезлек чыкса каршыңа.

Бәхет бит ул тоту кулда
Чабулаган фикер-уйларны.
Тайпылмыйча уңга-сулга,
Үтә белү туры юлларны.

Бәхет бит ул сыя белү
Якыннарның йөрәк эченә,
Фикерләрне җыя белү
Таянмыйча беләк көченә.

Бәхетсезлек шуны белмәү,
Борын чөеп, кеше күрмәү,
Олыларга сәлам бирмәү,
Бәхет кошын читтә эзләү.

## ИСКЕ ЯРМӘК - ЯМЬЛЕ АВЫЛ

Иске Ярмәк - ямьле авыл,
Җиде йөзгә якын өйләре.
Яңгыратып Юкәле тауны,
Өздерәләр урам көйләре.

Авылымның үз җыры бар,
Биюе дә - исең китәрлек.
Гали абзый гармуны да
Халкыбызны әсир итәрлек.

Моңлы диеп Ярмәк даны
Таралган бит борын заманнан,
Артистларыбызны таный
Ырынбурлар, Уфа, Казаннар.

Сок елгасы дулкыннары
Йөрәкләргә безнең кагылган.
Су өстенең очкыннарын
Җыйгангамы балачагыннан?!

Юкәле тау яннарыннан
Безме үтеп, аны сөймәгән?
Сок елгасы ярларының
Гүзәллеген тоеп үсмәгән?

Кайтыр төсле әле балкып,
Ярмәки дә Ташкент ягыннан.
Халик Садри да кайтып
Төшәр төсле Кашлак тавыннан.

Юкәле тау сихерләре
Аларга шул ныклап эләккән,
Шуңа күрә фикерләре
Ташып чыккан утлы йөрәктән.

Шул сихерләр инде безне
Тартып тора гомер буена.
Шатландырып күңелебезне
Кунак итә Сабан туенда.

## КАРТЛАРГА КАРАШ

Кайберәүләр якын итеп,
Кучтәнәчен арзан хакка
Әнисенә сатып китеп,
Кайтып йөри туган якка.

Кияүләр дә «ати» диеп,
Эшләшәләр арзан хакка.
Борыннарын өскә чөеп,
Булыштым дип кирәк чакта.

Эти-эни кечерәеп,
Мескенәеп ялгыз калгач.
Күзләре дә чекерәеп,
Бөкерәеп картлык баскач,

Киленнәрнең күңеле тик
Тарая шул мескеннәргә.
Улларның да күбесе
Яраклаша киленнәргә.

Калдык-постык кием киеп,
Чирләр баскач, үлем теләп,
Ялгызлыктан җаны көеп,
Саубуллаша дөнья белән.

## КОШЛАР БЕЛӘН ЕЛЛАР КИТӘ

Кошлар китә көзгә кергәч,
Җылы якка өер булып.
Күңел тула шуны күргәч,
Йөрәгемдә төер булып.

Тыңлый-тыңлый тавышларын,
Моңсуланып уйлап торам.
Саубуллашу сагышларын
Һәр ел саен санап барам.

Гомеремнең һәрбер елы
Кошлар белән очып китә.
Күкләрдәге торна җыры
Шул турыда хәбәр итә.

Киткән кошлар кире кайта
Диңгезләрне, чүлләр гизеп.
Югалтулар күп булса да,
Алар кайта газап чигеп.

Тик кайтмыйлар үткән еллар,
Мәңгелеккә китә барып.
Киң булса да узган юллар,
Кайтып булмый атны борып.

## МИН БУРАНДА ТУГАНМЫН

Бураннарда тугангамы,
Өермәләр уйнап торганда,
Көртләр өеп урамнарга,
Ап-ак төскә дөнья чумганда,

Яратам мин бураннарның
Биткә өргән шаян сулышын.
Кагып күңел тузаннарын,
Сызгырынып уйнап узышын.

Уйнаклаган шаян җиле
Куптарганда хисләр буранын,
Кыю уйлар башка килеп,
Туа тора шигырь юлларым.

Яңа карлар сафлылыгына
Сокландым мин гомер буена.
Бәлки, күңел сафлылыгында
Шул бураннар өсти уема?!

Бураннарда тугангамы,
Өермәдә һәрчак уйнадым.
Яшьлек үткән урыннарга
Ашкыналар һәрчак уйларым.

### НИШЛӘДЕҢ СИН, БОЛГАР ИЛЕ?

Ничек мондый көнгә калдың
Чәчәк аткан Болгар иле?
Явыз кяфер богау салып,
Башкаеңа синең җитте?!

Искитәрлек тормышыңны
Куз яшенә, көлгә бутап,
Сокланырлык язмышыңны
Елан булып буды урап?!

Биш йөз еллык җәрәхәтең
Төзәлмичә, каный һаман.
Азатлыкка хәрәкәтең
Шул еланга үлем сыман.

Чага торып иманыңны,
Кисә бара ул телеңне.
Урлап чибәр кызларыңны,
Саташтыра ирләреңне.

Шул аждаһа ыжгырса да,
Ялкын чәчеп тамагыннан,
Бәгыреңне яндырса да
Гасырларың дәвамында,

Бирешмә син, Болгар иле,
Аждаһага каршы торып,
Азатлыкның изге җиле
Искән чакта өмет биреп!

### ТӨНГЕ УЧАКЛАР

Урам тулып атлар чаба
Болыннарга, кырга таба.
Артларыннан тузан тузгый,
Ялларында җилләр уйный.

Борыннары киңәйгәннәр,
Ирек тоеп ирәйгәннәр,
Очкан сыман һава ярып,
Дөбердәтеп елга ярык.

Качкан кебек көндәлектән
Саф һавалы төнгелеккә.
Тынычлыкка чумар өчен,
Үләннәрнең җыеп көчен.

Учакларда уйный ялкын,
Үзәнлектән күккә калкып,
Өстән төшкәч юеш салкын,
Учак ургый төнне талкып.

Төнгелеккә чумган атлар
Үлән җыя вак-вак утлап.
Учак яна атлар саклап,
Төн эченә якты саплап.

Әкренләп томан тугач,
Авыл халкы көтү кугач,
Учак көтә чык ятуын,
Тизләткәндәй таң атуын.

Кире кайта инде атлар,
Эх, чибәрләр, изге затлар,
Көндәлеккә бирер өчен
Төнлә җыйган үлән көчен.

Шул учаклар ялкыннары
Дәрт тудырган ялкыннарым.
Куңелемә җылы бирә,
Кайгы килсә ара-тирә.



### ТУЙ ТӨШКӘНДӘ

Туйлар китә кышка кергәч,
Кыңгыраулар сибә чыңнарын.
Туй күлмәген кызлар кигәч,
Искитәрлек сылу сыннары!

Сөлге аскан атлар чаба
Килен көткән урам ягына.
Салмак кына карлар ява
Бизәк булып атлар ялына.

Көянтәгә чиләк асып,
Килен китә чишмә суына.
Аякларын вак-вак басып,
Сокландырып зифа буена.

Умартадай гөжли халык,
Кайсыбере биеп маташа.
Йөрәкләргә утлар салып,
Гармунчы да ясый тамаша.

Бигрәк ямьле никах туе!
Изге теләк тели бар халык.
Инде яшьләр гомер буе
Яшәсеннәр иде макталып!

### ФӘРЕШТӘ КАНАТЫ

Йөгереп төшкәндә таулардан
Кутәреп җилкәгә кулларны,
Фәрештә канатын саклаган
Вакытлар билиләр уйларны.

Ул чаклар елларга күмелеп,
Тарихка тагылып калдылар.
Шулай да куңелем түренең
Иң якты урынын алдылар.

Җилкәдә фәрештә канатын
Тормышта һәрвакыт тоябыз.
Егылсак, борынны канатып,
Шуңарга таянып торабыз.

Кутәрә ул авыр вакытта,
Җилкәләр өметсез сыгылса,
Сөремле йөзләрне яктырта,
Куңелгә болытлар сарылса.

Кайвакыт җилкәдән фәрештә
Ашкына торгандыр качарга.
Килешсез хисләргә бирешсәм,
Яхшыны юрасам начарга.

Елларым фәрештә аклыгын
Чәчемә сибәләр аз гына.
Уйларым, хисләрем сафлыгы
Торалар фәрештә сагында.

### ЮКӘЛЕ ТАУ - ЯШЬЛЕГЕМ САНДЫГЫ

Хисләрем, ялкынлы хисләрем,
Чабасыз яшьлегем янына,
Учаклар дөрләгән кичләргә,
Сихри Юкәле Тау ягына.

Уйларым сулардай агыла,
Сок буе талларын сагынам.
Чыксам шул каеннар янына,
Баргандай яшьлегем ягына.

Елганың камышлы ярында
Куңелем сагышка сарыла.
Сайраган кошларның җырында
Яшьлекнең моң-зары чагыла.

Яктырта каеннар аклыгы
Уйларны болытлар басканда.
Таң алды ачы төш сазлыгы
Томанга төренеп ятканда.

Саклагыз, Юкәле Тау яннары,
Яшь чакның иң якты хисләрен.
Әтәчләр уяткан таңнарның
Сиреньнәр тараткан исләрен.

Саклагыз, Сок елга ярлары
Яшьлегем атлаган эзләрне,
Куңелне назлаган язларны,
Өзелеп кузләгән йөзләрне.

Юкәле Тау - яшьлегем сандыгы,
Саклый кур иң якты хисләрне.
Беренче тойгылар сафлыгын,
Иң татлы хыялый кичләрне.

Очынып учактан чаткылар
Көл булып үләнгә ятканда,
Уйларым яшьлеккә чаптылар,
Сиреньнәр кук чәчәк атканда.



# ПОЛИЦИЯ ХЕЗМӘТКӘРЕ ЯХШЫ ПСИХОЛОГ БУЛЫРГА ТИЕШ

***Полиция капитаны Гакил улгы Илнур Әхмәтҗанов сигез ел Самар шәһәрендә Эчке эшләр министрлыгының Киров районы бүлегендә эшли. Биредә Илнур башта эзләү бүлегендә оператив хезмәткәр булып хезмәт итә. Аннары аны эзләү бүлеге җитәкчесе итеп билгелиләр. Без милләттәшебез белән аның эше, тормышы турында әңгәмә коттык.***

**Әңгәмәдәш – Миләүшә ГАЗИМОВА**

**– Илнур, полиция хезмәте – иң авыр хезмәтләрнең берсе. Бу һөнәрне аңлап, үзегез сайладыгызмы, әллә берәрсенең тәкъдименә “колак салдыгызмы”?**

– Мин кечкенәдән полиция хезмәткәрләре турында фильмнар карарга яраттым. Андагы геройларга охшарга теләп, полициядә хезмәт итәргә хыяллandым. Шуңа күрә 17 яшемдә полиция мәктәбенә укырга кердем.

**– Үлем Сезнең һөнәрегез янәшәсендә йөри. Курку хисе кичерәсезме?**

– Курку хисе һәр кешегә хас инде ул. Безгә, полиция хезмәткәрләренә, гади куркынычсызлык чараларын үтәргә һәм закон нигезендә эш итәргә кирәк. Курку хисе булса да, яхшыга гына өмет итәбез. Гомумән, полиция хезмәткәре кыю булырга тиеш, шуңа күрә курку хисен җиңәргә тырышам, Ходайдан ярдәм сорыйм.

**– Хезмәтегездә куркыныч янаган чакларда догалар укыйсызмы?**

– Әйе, кечкенә чакта әбием өйрәткән догаларны укыйм.

**– Сез югалган кешеләрне эзлисез. Алар арасында кемнәр күбрәк – ир-атлармы, хатын-кызлармы яисә балалармы?**

– Күбесенчә ир-атлар югала. Алар арасында да күпләре - эчкече кешеләр. Яшьләр арасында да эчүчеләр бик күп. Алар шул сәбәпле еш кына өйләреннән чыгып китеп, берникадәр вакыт югалып торалар.

Әгәр дә инде эчми торган кеше югалса, күбесенчә моның сәбәбе криминаль була. Шулай ук алкоголиклар гаиләләреннән, балалар йортларыннан, интернатлардан качучы малайлар, кызлар еш очрый. Бу балалар качып йөргән чакларында, полиция хезмәткәрләре аларны тапканчы, берәр нинди җинаять кылып өлгерергә дә мөмкиннәр.

Хәтерләре начар булган картларны, психдиспансерда исәптә торган кешеләрне дә эзлибез, югалганнарның мәетләрен генә тапкан очраклар бар.

**– Югалган кешеләрнең органнарын донорлыкка алган очраклар булдымы?**

– Минем эшләү дәверемдә һәм, гомумән, Самар өлкәсендә андый хәлләр очраганы юк, шөкер. Тик югалган кешене эзләгәндә, без бу версияне дә күздә тотабыз.

**– Полиция хезмәткәре буларак, үзегездә психолог сыйфатларын булдыра алдыгызмы?**

– Һәрбер полиция хезмәткәре яхшы психолог булырга тиеш. Җинаятьтә гаепләнүчедән сорау алганчы, без моңа яхшылап әзерләнәбез, аның турында мәгълүмат туплыйбыз, сорауларны алдан күзаллыйбыз. Әгәр дә кеше берәр нәрсәне яшерә, әйтеп бетерми икән, без моны сизеп алабыз. Сорауларны дөрес итеп бирсәң, җинаятьче бутала башлый, шул мизгелдә аның ялганын тотарга була.

**– Җинаятьчеләрне еш эзләргә туры киләме?**

– Әйе, андый хәлләр булгалый. Җинаять кылып, качкан кешеләрне эзләү турында игълан итәләр. Алар бит Самар өлкәсендә генә түгел, башка төбәкләрдә дә качып ятарга мөмкиннәр. Шуңа күрә без еш кына командировкаларга чыгып китәбез. Мәсәлән, минем үземнең Башкортостанга, Мәскәүгә, Санкт-Петербургка, Новосибирскига барганым бар. Минем хезмәткәрләрем Сарытау, Екатеринбург шәһәрләрендә булдылар.

Берәр җиргә барыр алдыннан без андагы хезмәттәшләребезгә бу турыда хәбәр итәбез, һәм алар безгә җинаятьчене эзләүдә ярдәм күрсәтәләр. Безгә дә башка төбәкләрдән полиция хезмәткәрләре мөрәҗәгать итәләр. Без дә аларга булышабыз.

**– Командировкаларга формада йөрисезме?**

– Юк, без, оператив хезмәткәрләр буларак, полиция формасын кизү торуга (дежурство) барганда һәм бәйрәмнәрдә генә киябез. Болай гадәти граждан киемнән йөрибез.

**– Тормышта эти-әниегез киңәшләренә “колак саласызмы”, әллә үз белдеклелегез белән яшисезме?**

– Тормышта мин үзем карар кабул итәм. Тик әти-әниемнең киңәшен һәрхәлдә сорыйм. Алар мине эшләргә түгел, яшәргә өйрәтәләр. Әти-әнине яшәү тәҗрибәсе буенча узып булмый, әлбәттә.

**– Кызлар полиция хезмәткәрләрен яраталармы?**

– Минем йөргән кызым мине ярата (елмая) һәм яхшы аңлый. Гомумән, мин бик күп татар полиция хезмәткәрләрен беләм. Хатыннары яисә йөргән кызлары белән аларның арасында аңлашучанлык һәм мәхәббәт хөкем сөрә. Әлбәттә, полиция хезмәткәрләрен урап узучы кызлар да юк түгелдер. Мин исә бу яктан уңдым.

**– Кызларда нинди сыйфатларга өстенлек бирәсез?**

– Мөселман хатын-кызлары шәригатебезнең әхлаки принципларын һәм кагыйдәләрен үтәргә тиешләр, дип саныйм. Шулай ук ирен, аның әти-әнисен хөрмәт итү мөһим. Хатын-кыз ул гаилә җылысын сакларга, балаларны тәрбияләргә, ә ир акча эшләргә һәм гаиләсе турында кайгыртып яшәргә тиеш.

**– Тормышта үз урыныгызны таптыгыз, дип саныйсызмы?**

– Әйе, полиция хезмәте – минем вазифам. Аллаһыга шөкер, әлегә эшемдә барысы да килеп чыга, шуңа күрә киләчәктә дә үземне полиция хезмәткәре итеп кенә күзаллыйм. Бигрәк тә безнең хезмәт җәмгыятебезгә, дәүләтебезгә файдалы бит. Полиция хезмәткәрләренең бурычы – кешеләрне яклау һәм мин моңа әзер.

**– Яңа ел алдыннан хезмәттәшләрегезгә ниләр теләр идегез?**

– Хезмәтләрендә уңышлар телим. Эшебездә төрле чаклар булгалый. Шушындый авыр вакытларда хезмәтләреннән күңелләре кайтмасын иде. Үз-үзләренә ышанып, сәламәт яшәргә насыйп булсын. Полициядә сәламәтлек – беренче урында. Барчабызны да Ходай Тәгалә үз ярдәменнән ташламасын иде.

***Социализм чорында һәр кешенең кухнясында тәүлегенә 24 сәгать радио тик урысча гына сөйләп торыр иде.***
***Хәбәрләр. Музыка. Һава торышы. Файдалы киңәшләр. Игъланнар һәм башка төр мәгълүмат. Әйе, бу сәясәт иде. Дәүләтнең үз фикерен халыкка җиткезүнең җиңел бер ысулы. Начармы бу? Яхшымы?***

***Шамил Баһаутдин***

# Татар теле җир шарына яңгырый



*«Азатлык»ның Русиядәге хәбәрчеләре. 2010 ел.*

Күпчелек өчен яхшы иде. Гәҗитә-журнал алдырмаган кеше дә күп нәрсәләрдән хәбәрдар булды. Тимер койма артында яшәгән СССРда ике төрле фикер була алмады. Барчасы да сафларга басып бәйрәмгә бара, барчасы да цензура аша узган хәбәрне тыңлый. Эфирда татар сүзен ишетмәс идең! Ниһаять, 1953 елда дөнья киңлекләренә татар телендә тапшырулар башлана. Тик бу радионы рәхәтләнеп утырып тыңлап булмады. Шатыр-шытыр, дөбер-шатыр аша тыңларга туры килде. Аны бастырып килделәр. Азатлык радиосын бастыручы көчле техник чаралар бөтен СССР киңлекләрендә төзелде. Шуларның берсе Самарда эшләде. Бу коточкыч зур чыгымнар таләп иткән корылмалар иде. Коммунистик режим халыкка икенче фикерне ишеттермәс өчен, акчаны җәлләмәде. Заманалар үзгәрде. Ходайның рәхмәте белән динебез Исламны корытучы большевизм да чәлпәрәмә килде. Кайчандыр качып-посып тыңлаган «Азатлык» радиосын Татарстан дәүләт радиосы үзенең дулкыннарында яңгырата башлады. Куандык. Шатландык. Тик озакка бармады бу бәхет. «Азатлык»ны ул дулкыннан кудылар. Хәзер «Азатлык» үзенең тапшыруларын интернетта алып бара.

Самарда 1992 елдан 2002 елга кадәр гөрләтеп “Радио-7” эшләде. Унбер телдә сөйләгән радионың берсе һәм иң көчлесе татар телендәге “Ак бәхет” иде. Ул тапшыруларны мин - Шамил Баһаутдин кызым Наилә белән алып бардым. Ул елларны онытасым юк. Халыкны радио тыңлатырга өйрәтер өчен гаҗәеп зур хезмәт куярга туры килде. Кухня радиосын тыңларга өйрәнгән социлизм баласын радиоалгычлар алдырырга туры килде. Рәхмәт халкыма. Алдылар. Тыңладылар. Ни өчен моңа җентекләп тукталам соң? Заман даими үзгәреп тора, заман белән бергә техник чаралар үзгәрә. Һәр йортка интернет килеп керде! Дулкынны беркем бастырмый. Кабыз. Тыңла, кара һәм укы! Әйе, әйе.



***Самар хәбәрләрен «Азатлык» дулкынында Шамил Баһаутдин ирештерә***

Бүгенге көндә «Азатлык» радиосын интернетта тыңлап та, укып та, карап та була.

Азатлык радиосы (тулы исеме Radio Free Europe/Radio Liberty – Азат Ууропа/Азатлык радиосы).

Азатлыкны Америка Кушма Штатларының Конгрессы финанслый.

«Азатлык» радиосының татар һәм башкорт телендәге тапшырулары беренче мәртәбә 1953 елның декабрендә чыга. Татар-башкорт дөньясы хәбәрләрен урыннарда егермегә якын хәбәрче биреп тора.

«Азатлык» радиосы үз тапшыруларын Чехиянең Прага шәһәреннән алып бара.

1953 елдан 1995 елга кадәр «Азатлык» радиосы үзенең тапшыруларын Германиянең Мюнхен шәһәреннән алып барды.

«Азатлык» радиосының эше чын демократик һәм хокукый җәмгыятьне фәкать мәгълүмат чараларында ирекле эшләве шарты белән генә корып була дигән инануга нигезләнә.

Әйе, «Азатлык» үткен радиолар исемлегендә. Кемдер аны дошман радиосы дип тә әйткәли. Россия киңлекләрендә үзенең тапшыруларын алып барган “Эхо Москвы” «Азатлык»ны да уздыра дип әйтер идем.

«Азатлык» радиосы төбәкләрдәге хәлләрне яктырта. Объектив һәм риясыз мәгълүмат бирә.

**«Азатлык» радиосының сайты:**
**www.azatliq.org**

Татар халкы өчен «Азатлык» радиосы – олуг бәхет. Ул безнең телебезне сакларга, мәдәниятебезне үстерергә, тарихыбызны барларга ярдәм итә. 26 телдә яңгыраган тапшыруларның берсе – татар теле булу - безнең өчен горурлык. Егерме елдан артык Самар татарлары тормышын «Азатлык» дулкынында яңгыратып торуым белән мин - Шамил Баһаутдин - Самар татарларының дәрәҗәсен еракларга ирештерәм. Америка радиосының дулкынында татар милләтенә хезмәт итүемә шатмын.

Интернетта www.azatlig.orgка чыксагыз, рәхәтләнеп татарча тапшырулар тыңларсыз. Туган телебезне өйрәнерсез. 2013 елда япун егете «Азатлык» радиосын тыңлый-тыңлый саф татарча сөйләшергә өйрәнде һәм Казанга килеп, журналистларга саф татарча интервью бирде.

Кемдер әйтер. Мин интернетта эшли белмим дип. Ялкаулык. Бүгенге көндә һәр бала интернетта эшли. Оныгыгызны кунакка чакырыгыз да ул сезне интернетта эшләргә өйрәтер. Моны мин үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм. Мәктәптә укучы оныгым Диләрә мине өч көндә интернетта эшләргә өйрәтте. Рәхәтлеген сүз белән аңлатып бетереп булмый. Сез дөнья киңлегенә чыгасыз. Мин карт инде дип сәбәп эзләмәгез. Самарда Азат абый Надиров интернетны 81 яшендә үзләштерде. Татар картлары һәм татар карчыклары – иң мәгърифәтле һәм акыл ияләре. Без булдырабыз.

*www.azatliq.org*

# Касыймдагы Хан мәчете мөселманнарга кайтарылды

***Касыйм шәһәрендәге борынгы Хан мәчете мөселманнарга тапшырылды. Өлкәнең имам мөхтәсибе әйтүенчә, бу – мөселманнар өчен зур тарихи вакыйга.***

Рязань өлкәсенең Касыйм (Ханкирмән) шәһәрендә XV гасырда төзелгән борынгы Хан мәчетен мөселманнарга кайтардылар. Бу хакта өлкәнең имам мөхтәсибе Рәшит хәзрәт Бултачеев белән сөйләштек.

***– Хәзрәт, әлеге мәчет бинасында хәзер нәрсә урнашкан?***

– Анда хәзергә төбәк музее урнашкан. Бүген мәчетне тапшыру турындагы документларны Русия мөфтиләр шурасы рәисенең беренче урынбасары Дамир Гыйзәтуллин кабул итеп алды.

Тышкы кыяфәте мәчет рәвешендә булса да, анда бернинди дини гыйбадәтләр узмый иде. Музейда Касыйм татарлары экспозициясе урын алган. Хәзер мөселманнарга бирелгәч, инде мәчет ясыйбыз. Шул ук вакытта без музейның калуына да каршы түгел. Бу бина бик зур һәм анда шактый туристлар килә. Алар шулай ук Ислам дине, мәдәниятебез белән дә таныша ала. Без беркемне дә кумыйбыз.

***– Анда мәчеткә дә, музейга да урын җитәме соң?***

– Бу икекатлы бина. 400 квадрат метр мәйданы бар. Шуңа барыбыз да сыябыз. Әлеге мәчет Петр I карары белән җимерелеп, аның бары манарасы гына калган була. 1700нче елларда Екатерина



патшабикә аны яңадан торгызырга боерык бирә. 1938 елда исә ул музейга тапшырыла. Быел әлеге хәлгә нәкъ 75 ел тулды.

***– Билгеле булганча, бу мәчет бинасы федераль дәрәҗәдәге әһәмияткә ия архитектура объекты булып тора. Аны финанслау ничек булачак?***

– Монысын белмим. Аллаһы ярдәме белән үзебез тотарбыз. Бу инде соңгы гасырдагы иң зур тарихи вакыйга, чөнки үзәк федераль бүлгедә мондый мәчет бердәнбер. Русиядә борынгыдан сакланган тарихи мәчетләрдән, Дербенттан соң, бу - әһәмияткә ия булган икенче мәчет.

***– Касыйм да ничә мәчет бар?***

– Бер генә мәчет. Шуңа бәйрәмнәрдә ул шыгрым тула иде, менә бу Хан мәчетенең мөселманнарга бирелүе бик яхшы булды.

Болай мәчеткә районндагыларны да кертеп, ике меңләп кеше килә. Бу инде татарлар. Ә хәзер мәчеткә йөрүче таҗиклар һәм үзбәкләр дә күп бит әле.

***– Хан мәчетен мөселманнарга бирү мөрәҗәгате озак каралдымы?***

– Юк, барысы да тиз эшләнде. Менә хәзерге мәчет белән генә хәл итеп булмый. Без аның да җирле мөселман оешмасына бирелүен сорыйбыз. Инде бу эш 2007 елдан бирле бара, әле һаман очына чыгып булмый.

***– Әлеге мәчет хәзер кем карамагында?***

– Ул шәһәр милке санала. Мәчеттән тыш мәдрәсә дә бар һәм анда төзекләндерү эшләре бара. Без хәзер барысын да эшләп бетерербез дә, шәһәр җитәкчелеге аны тартып алып, үз кирәкләренә кулланырлар, дип куркабыз. Хәзер бит заманалар шундый.

***– Нигә мөселманнарга бирәселәре килми?***

– Документларның барысы да җыелмаган, устав нотариус аша узмаган, дип әйтәләр. Нинди дер сылтаулар табып торалар инде. Барлык документларны яңадан җыеп тапшырдык, хәзер инде көтәбез.



# “ЯНӘШӘМДӘ НЫКЛЫ ТЕРӘГЕМ БАР”

*Моң кеше җанына чишмә суы белән керә, диләр. Галия апа Мостафина да үз авылының чылтырап аккан чишмә суларын эчеп, шундый моңлы булгандыр...*

Миләүшә ГАЗИМОВА

Тупли авылында туып-үскән кыз кечкенә чагыннан җырларга ярата. Әле мәктәпкә укырга кергәнче үк укытучы булып эшләгән әтисе Йосыф аны еш кына үзе белән дәресләренә алып бара. Анда кызның моңлы булуын белеп, үзен җырлата торган булалар. Тамашачыларга яхшырак күренсен өчен, кечкенә буйлы Галия урындык өстенә басып, “Талы-талы”, “Суда-суда” җырларын суза. Аңа барысы да дәррәү кул чаба. Шундый игътибардан кечкенә җырчы өенә бик канәгать булып кайтып китә.

Ә инде өлкән сыйныфларда укыганда үзешчән артистлар төркеменә оешкан яшьләр белән үзләренең авыл ында да, тирә-як авыллар клубларында да чыгыш ясап йөри.

Әле дә күпләр “Танцуй, танцуй” исемле танылган һинд кинофильмын хәтерли торгандыр. Мин дә аны күп тапкырлар күрсәм дә, караган саен андагы җырларга, биюләргә сокланам. Вакытында бу фильмның танылган “Зюби, зюби” җыры радио, магнитофоннардан еш яңгырады.

Еллар узгач, мин аны Самарның “Ялкынлы яшьлек” ансамбленең бер концертында тагын ишеттем. Бу җырны башкарган, тышкы кыяфәте белән дә, моңлы тавышы белән дә һинд артисткаларыннан бер дә ким булмаган Галия Мостафинага хәйран калып утырган идем.

– Кечкенә чактан һинд киноларын үлеп яратам. “Ялкынлы яшьлек”тә беренче тапкыр “Господин 420” дип аталган һинд фильмыннан укытучы җырын башкардым. Аны тамашачылар бик яратып кабул иттеләр. Шуннан соң инде башка һинд җырларын да башкара башладым. Бер-ике тапкыр тыңлагач та, җырның көен, сүзләрен шунда ук отып алам. Аннан соң баянчы Наил Нурмөхәммәтов белән без азәрбайҗан, үзбәк, һинд, татар телле куплетлардан попурри да төзедек, - дип исенә төшерә Галия апа.

Ул тирән эчтәлекле, мәгънәле, хисле җырлар башкарырга ярата. Әлфия Авзалова башкарган “Әйт, дускаем, әйт” җырын аеруча ошата ул. Шулай ук “Салкын чишмә” җыры да ятрактаннар исемлегендә.

– Безнең кумирларыбыз Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, Флера Сөләйманова иде. Аларның җырларын әле дә сокланып тыңлыйм, - ди Галия ханым.

– Ә бүгенге көндә нинди җырчыларны яратасыз? – дип сорадым мин әңгәмәдәшемнән.

Заманча җырчылардан аңа Раяз Фасыйхов, Бәширә Насыйрова, Сиринә Зиннәтуллина, Рафаэл Якупов, Ришат Төхвәтуллин, Фәдис Ганиев ошый икән.

Галия апа сүзләренчә, кечкенә чагыннан җырласа да, сәхнәгә чыккан саен зур дулкынлау кичерә ул. Җырларның ул үзенең эчке дөньясына, хис-тойгыларына, күңеле халәтенә туры килгәннәрен сайлап ала.

Туплида сигезьеллык мәктәпне, аннан күрше Елховка авылында 9 – 10нчы сыйныфларны тәмамлагач, Галия Куйбышевка килеп, секретарь-машинистка курсларында укый һәм башта “Волготанкер” пароход хуҗалыгында эшли, аннары “Металлист” заводына урнаша.

Куйбешевка күчкәч тә, Галия үзешчән сәнгать коллективларында катнаша. “Ялкынлы яшьлек”кә аны бу ансамбльне оештыручыларның берсе, хәзер инде мәрхүм Шамил Сатдаров чакырып ала. Татар моңнарыннан башка



яши алмаган кыз бу тәкъдимгә шатланып, шунда ук ризалаша.

Галия 18 яшендә Искәндәр исемле авылдаш егетенә кияүгә чыга. Әмма гаилә коруы җырчының иҗади тормышына комачауламый. Хәтта уллары Рәфәэл һәм Ринат тугач та, сәхнәне ташламый ул.

Башта “Ялкынлы яшьлек”, аннан “Идел моңнары” ансамбльләрендә җырлаган Галия Мостафина шәһәребездә генә түгел, ә өлкәбездә дә танылып, аның үз тыңлаучылары барлыкка килә. Бигрәк тә башкалардан үзенчәлекле тавышы, сөйкемлелеге, һинд җырларын оста башкаруы белән аерылып торучы җырчы буларак яраталар аны.

“Ялкынлы яшьлек”кә килгәч үк, Галияне гастрольләргә алып баралар. Ансамбль өлкәбезнең төрле авылларында концертлар куя. Шулай төп эшеннән, гаиләсеннән тыш, моңлы милләттәшебезнең гомере репетицияләрдә, гастрольләрдә үтә.

Бүгенге көндә Галия ханым лаеклы ялда. Ул инде күптән дин юлына басып, гыйбадәтләрен кылып, Аллаһыга шөкер итеп яши. Хәзер сәхнәгә бик сирәк чыга Галия апа. Ә чыкса, мөселман киеменнән була һәм җитди, тирән мәгънәле җырлар яисә мөнәҗәтләр башкара. Бүгенге көндә күбесенчә гаилә бәйрәмнәрендә якыннары алдында, хәмерсез туйларда һәм инде өй эшләрен башкарганда, ашарга пешергәндә җырлый ул.

Ходай биргән сәләтеннән акыллы итеп файдаланып, моңлы тавышлы Галия апа матур итеп көйләп Коръән сүрәләре укый, мөнәҗәтләр әйтә. Дини мәҗлесләрдә дә көтеп алынган хөрмәтле кунакларның берсе ул.

– Бервакыт "Яктылык" мәктәбе мөдире Харидә ханым Дашкина мине бер бәйрәмгә җырларга чакырды. Биредә мәктәптә дин дәресләрен укыткан, хәзер инде мәрхүм Минәхмәт Сәгыйров та бар иде. Шунда ул миңа: "Тавышың моңлы, Коръәнне укырга өйрәнергә кил", дип, үзенең дәресләренә чакырды. Тәвәккәлләп, барырга булдым, - дип сөйли Галия апа.



Мәктәптә биш ел Коръән сүрәләрен укырга, гарәпчә язарга өйрәнә ул. Хәрефләр үзләштерә башлагач та, аларны намаз укырга да өйрәтәләр. Дин дәресләренә йөрүчеләрне Самарның югары уку йортларында белем алган гарәп студентлары – Һиндстаннан Нәгыйм, аның энесе Халит, Марокkодан Әбүбәкер, Ливаннан Рәбигъ тә килеп укыталар.

Бу турыда Галия апа:

– Башта гарәп графикасын өйрәнүе бик авыр булып тоелды, аны үзләштерә алуыма шикләнеп тә куйдым, тик Аллаһы Тәгалә шундый изге ниятләрне гамәлгә ашырырга ярдәм итә икән. Шөкер, якшәмбе мәктәбен тәмамлаганда без инде тәҗвид кагыйдәләрен кулланып, күп кенә Коръән сүрәләрен тәрҗемәләре белән яттан белә идек.

Әбүбәкер шулкадәр моңлы, матур итеп сүрәләр укый иде. Хәтта аның тавышыннан тәннәр чымырдап китә, аңа карап, безнең дә шулай укырга өйрәнәсебез килде. Ул безгә бик яхшы үрнәк бирде. Аллаһы Тәгаләгә шушы ниятләремне тормышка ашырырга ярдәм иткәне өчен мин бик рәхмәтле, - дип сөйли.

Милләттәшебезнең зур хыялын – хаҗ кылуны да гамәлгә ашыра Ходай. 2008 елда ул изге сәфәрдә булып кайта. Аның сүзләренчә, анда Галия апа үзен бөтенләй башка дөньяга эләккәндәй хис итә. 45 көн торганнан соң да, тагын бер генә көнгә булса да анда каласы килә аның. Шулкадәр тирән тәэсирләр калдыра аңарда хаҗ кылу. Саф һава, чисталык, тынычлык, кунакчыллык Галия апаны хәйран калдыра.

– Андагы дини мохит, җирле мөселманнарның хаҗиларга яхшы мөнәсәбәте, тәваф кылулар әле дә күз алдымда тора, - дип сөйли ул.

Хаҗ кылганда Галия апа яшәгән кунакханәдә төрле төбәкләрдән килгән хаҗилар арасында Коръән һәм мөнәҗәтләр уку буенча конкурс үткәрелә. Бәйгедә катнашучыларның чыгышын хәзрәтләр бәяли. Шушы бихисап кеше арасында Галия Мостафина беренче урынга лаек була.

Дин юлына баскан хатын хәйрия белән дә шөгыльләнә. Шәһәребезнең 117нче мәктәп-интернатында укучы начар ишеткән балаларга ярдәм итеп тора ул. Алар өчен ел саен Корбан мәҗлесләре дә уздыра. Бу игелекле эшендә аны хуплаучы, ярдәм итүче ире Искәндәргә чиксез рәхмәтле хаҗия.

Милләттәшебезнең музыкаль иҗатына югары бәя биреп, 2011 елда аңа "2010 ел хатын-кызы" исемен бирәләр. Шул ук елда шәһәр хөкүмәте тарафыннан Самар алдындагы хезмәте өчен күкрәк билгесе һәм Мактаунамә белән дә бүләкләнә ул. Моны да Аллаһы Тәгалә биргән югары дәрәҗә, дип саный Галия апа. Шулай ук аның кандидатурасын бүләкләүгә тәкъдим иткән Минәхмәт Хәлиулловка, Илгиз Колючевка, Клария Рамазановага, 117нче мәктәпнең директоры Ирина Барановага, Фәхретдин Канюкаевка, "Яктылык" мәктәбенең элеккеге мөдире Дания Әбдерәхимовага рәхмәтләрен укый. Аеруча Вагыйз хәзрәт Яруллинның хуплавы шатландыра аны. Ул вакытта өлкәбез мөфтие Галия ханымны бүләкләгән тантанага да килә.

– Бу дөньяда мин – бәхетле кеше, миңа бирелгән язмыш өчен Аллаһыга чиксез рәхмәтлемен. Яраткан ирем янымда, аның белән бергә гомер итүебезгә 40 ел тулды. Балаларым, киленнәрем, оныгым хөрмәт итәләр. Динебезнең иң зур гамәлен – хаҗ кылуны да насыйп итте Ходай. Ниятләрем, шөкер, тормышка ашты, - дип эч серләре белән уртаклашты Галия ханым.

Үзенең бәхетле тормышына багышлап, шигъри юллар да иҗат иткән ул.

Җырламыйча ничек түзим?
Таңым алсу, якты көннәрем.
Мин бәхетле бу дөньяда, чөнки
Янәшәмдә ныклы терәгем.
Хатын чибәр икән, ире яхшы аның,
Диеп әйткән белеп халкым минем.
Җырлап яшим бәхет тәмен тоеп,
Ходайга мин чиксез рәхмәтлемен.

Галия апа Мостафинага карап, соклanам мин. Ходай аңа тышкы һәм эчке матурлыкны да, җыр-моңга сәләтне дә мул биргән, һәм ул Аллаһының бүләкләренә рәхмәтле булып, тормышта иң дөрес, иң ышанычлы, туры юлдан – дин юлыннан атлый.



# Хөрмәтле редакция!



Менә инде 20 ел мин Самара шәһәрендә, ә 1997 елдан башлап, ”Яктылык” мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен алып барам. “Яктылык” мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты 2 нче сыйныфтан башлап укытыла. Без рустелле укучыларга Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгы раслаган программа нигезендә белем бирәбез. 5-11 сыйныфларда 2 сәгать татар теле һәм 1 сәгать татар әдәбияты укыту каралган. Мәктәбебездә белем алучы укучыларда, аларның нинди милләт кешесе булуларына карамастан, бөек Тукай теленә, күп укучыларның туган телләре булган татар теленә мәхәббәт тәрбияләргә тырышам.

Татарстаннан читтә яшәгәнгә, мин дәрестә милли-региональ компонентны да бик теләп кулланам. Әдәбият дәресләрендә укучыларны якташ шагыйрьләребез - Гакыйль Сәгыйров, Зыя Ярмәки, Әнвәр Давыдов, Рөстәм Мингалимов, Рәшит Морзакаев иҗатлары белән таныштырам, аларга багышланган әдәби-музыкаль кичәләр, шагыйрьләребезнең шигырьләрен сәнгатьле итеп укучылар арасында конкурслар, мәктәп радиосы аша әдәби тапшырулар үткәрәм.

Быел мин 4-9 нчы сыйныфларда татар телен һәм әдәбиятын укытам. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның сөйләм һәм язма телләрен үстерү өстендә дә күп эш алып барам. Сыйныфтан тыш та укучыларымны татар телендә төрле темага инша һәм шигырьләр язарга өйрәтәм. Менә шуларның уңышлы дип табылганын сезгә дә җибәрергә булдым.

*Хөрмәт белән “Яктылык” мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
***Нурзидә Фәйзуллина***

# Сөекле укытучыларым

Укулар башлану белән якты мәктәбебезнең ишекләрен киң ачып, безне елмаеп каршы алучы сөекле укытучыбыз - Изидә Дамировна. Менә ике ел инде ул - безнең классс җитәкчебез. Дәресләрдә Изидә апа безне биология фәне белән таныштыра.

Авыр предметлардан саналса да, мин математиканы да бик яратам. Бу дәресне Лилия Ришатовна укыта. Аны мин сөйкемлелеге, сабырлыгы һәм акыллы булуы өчен яратам.

Ә туган телебезне күз карасыдай саклап, аның белән безне якыннан таныштыручы - сөекле Нурзидә Әхмәтовна. Ул безне туган телебезне, әдәбиятыбызны яратырга, татар язучыларыбызны хөрмәт итеп яшәргә өйрәтә.

Һәр укытучы безне тырышлыкка, өлгерлеккә, зирәклеккә, сабырлыкка һәм башка яхшы сыйфатларга өйрәтә.

Аларга мин эшләрендә зур уңышлар, сәламәтлек һәм озын гомерләр телим.

***6 «Б» сыйныф укучысы***
***Аслан Нуран***

# Җәйге ял

Мин быел июльдә әнием һәм абыем белән Казанга студентларның XXVII бөтендөнья җәйге Универсиадасына бардым. Универсиаданың спорт программасына уеннар тарихында беренче тапкыр егерме җиде спорт төре кертелгән. Аларның унысын без карадык: йөзү, нәфис гимнастика, өстәл теннисы, су полосы, баскетбол, футбол, дзюдо, спорт гимнастикасы, синхрон йөзү, «Регби -7».

«Регби-7»не мин беренче мәртәбә күрдем. Ярышта мин Россия «Регби-7» ирләр командасы янында утырдым, аның тренеры «Регби-7» турында сөйләде һәм минем кулымны кысты. Универсиаданың талисманы Юни кушаматлы канатлы ак барс малае булды. Ул тәнәфестә кешеләрнең күңелен күтәрде.

Ярышлардан соң Игенчеләр сарае каршындагы Казансу елгасы яры буенда урнашкан Универсиада паркына бардык. Мин «Fifa-2018» павильонында булганда, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановны очраттым. Парк сәхнәсендә без Россиянең төрле төбәкләреннән җыелган артист-волонтерлар чыгышларын карадык.

Казанда унөченче июльдә Сабантуй булды. Мин дә Сабантуй ярышларында катнаштым: чүлмәк ваттым, капчык киеп йөгердем. Унбишенче июльдә без парктагы Универсиада кунаклары белән «Ак бүре» татар операсының дөнья премьерасын карадык.

Мин паркның бизәге булган - бөтен дөньяда танылган «Cirk due Solei» шоу тамашасын карадым.

Җәй көннәрендә мин әбиемнең туган авылы – Олыязга да кунакка кайттым, балалар лагеренда булдым, ләкин минем өчен иң истәлеклесе – Универсиада көннәре, әлбәттә.

Самар шәһәре ”Яктылык” мәктәбенең
***5 Б»» сыйныф укучысы***
***Ильяс Галимов***

# Әниемнең туган авылы

Һәр кешенең йөрәгенә якын, җанына җиңеллек бирә торган яраткан урыны була. Әнием өчен ул – аның туган авылы Муратовка.

Яшь чакта авылын ташлап, чит җирләргә китсә дә, ул туган туфракларын һәр көн сагына. Г. Тукай да «Туган авыл» шигырендә үз авылы турында яза:

*...Бу дөньяда, бәлки, күп-күп*
*эшләр күрем,*
*Билгесездер — кая ташлар бу*
*тәкъдирем;*
*Кая барсам, кайда торсам,*
*нишләсәм дә,*
*Хәтеремдә мәңге калыр туган*
*җирем.*

Мин дә чын күңелемнән Муратовка авылын яратам, аның гүзәллегенә сокланам. Ул безгә бөтен дөньяда бер генә, бары тик бер генә!

Авылда ике мәчет бар, анда һәр көн азан яңгырый.



Авыл янындагы урманда нинди генә чәчәкләр юк! Без һәр елны шунда җиләккә йөрибез, урманда җаен-көзен мәтрүшкә, сары мәтрүшкә, бөтнек һәм гөмбә җыябыз.

Авыл янында ике гүзәл чишмә ага. Сулары искиткеч чиста, йомшак. Әбиемнең йорты каршында матур күл бар. Күлебез урам уртасында көзге кебек ялтырап ята.

Анда кукан һәм кыяк үсә. Икенче ел инде челәннәр һәм кыр үрдәкләре торалар.

Менә кайда ул чын гүзәллек!

*4 «Б» сыйныф укучысы*
***Алсу Әбдерәхимова***



## Көз җитте

***Җәйләр үтеп, көзләр җиткәч,***
***Яфраклар саргайдылар.***
***Күчмә кошлар саубуллашып,***
***Җылы якка очтылар.***

***Урамда да салкын һава,***
***Җил исә, яңгыр ява.***
***Җиргә яфраклар коела,***
***Кырлар йокыга тала.***

***Бакчалар да бушап калды,***
***Елгаларны боз сарды.***
***Шулай итеп, җәй дә үтте,***
***Моңсу вакытлар җитте.***

***6 «Б» сыйныф укучысы***
***Алсу Гыйматдинова***



Минем сезгә соравым бар:
«Ник шулай дип әйтәләр?
Без – мишәрләр, без –
типтәрләр,
без – Казаннан, балалар!»

# Без - татар балалары

Күпме генә уйласам да,
Моңа җавап тапмадым.
Әни әйтә: «Касталандым!»,
Апа: «Авырый башладым!»
Төннәр буе уйлаганга,
Мине йокы алмады.
Шунда әни күзгә карап:
«Ни булды?» – дип сорады.
Уй-зарымны тыңлагачтын,
Мине алды кочакка,
Һәм иркәләп юаткачтын,

Миңа әйтте шулчакта:
«Балам, без бит барыбыз да
Бер үк Җирдә торабыз,
Кайда гына яшәсәк тә,
Аллабызга ялварып,
Барыбыз да бер үк телдә
Аннан сорыйбыз саулык.
«Без барыбыз да – татарлар!»
– ди һәрчак безнең халык.

***4 «Б» сыйныф укучысы***
***Алсу Әбдерәхимова***

# Иң кирәкле һөнәр

Укытучы – иң мөһим һәм кирәкле һөнәрләрнең берсе. Аларның хезмәте авыр, катлаулы, җәмгыятькә күп файда китерә торган.

Безнең мәктәптә укытучылар күп. Алар бөтенесе дә бик әйбәт, үз һөнәрләрен белә һәм ярата. Мин бөтен укытучыларны да хөрмәт итәм һәм безгә белем бирүләре өчен аларга бик рәхмәтле.

Ләкин минем яраткан укытучым берәү генә. Ул – безнең класс җитәкчебез Хуҗина Изидә Дамировна. Ул безгә биология дәресен укыта. Изидә апа бик яхшы һәм кайгыртучан. Ул безне гел яхшылыкка гына өйрәтә, тәртипле булуыбызны тели.

Әниләребез кебек үк, ул безне кирәк вакытта мактый, ә кайчак ачулана да. Ул һәрвакыт дәресләрне ныклап өйрәнергә куша, чөнки киләчәк тормышыбызда мәктәптә тупланган белемнәребезнең безгә кирәк булачагын аңлата.

Мин Изидә апаның дәресендә утырырга яратам. Чөнки ул һәр теманы безгә җентекләп аңлата. Дәресләрне мавыктыргыч, кызык итеп алып бара белә. Ул безне игътибар белән тыңлый, юата, ярдәм итә. Мин үземнең олы күңелле укытучымны хөрмәт итәм. Аңа авыр һәм мактаулы эшендә уңышлар һәм сәламәтлек телим.

*«Яктылык» мәктәбенең*
*6 «Б» сыйныф укучысы*
*Алия Гыйззәтуллина*

# Диңгез буенда



Җәй көне без гаиләбез белән диңгезгә ял итәргә бардык. Әтием дә, әнием дә эштәге ял вакытларын бер вакытта алдылар, безнең дә каникул иде.

Барып җиткәнче, мин ничек барырбыз, кайда торырбыз дип бераз курыккан идем. Диңгез буена килеп җиткәч, барысы да яхшы хәл ителде. Вакыт соң булуга карамастан, торырга урын да тиз табылды.

Икенче көнне иртән торып, без диңгез буена киттек. Мин башта диңгезнең тавышын ишеттем. Әйе, диңгезнең үз тавышы бар икән. Зур-зур дулкыннар ярга бәрелеп, вак һәм эре ташларны, сүсемнәрне кучереп, тавыш чыгаралар икән. Диңгезне ерактан ук күреп алдым. Ул шундый зур, очсыз-кырыйсыз иде. Суы ерактан ук зәп-зәңгәр булып күренеп тора. Ул көнне дә, аннан соң да без көннәр буе диярлек су коендык. Мин диңгез белән дуслаштым, рәхәтләнеп йөзә башладым.

*6 «Б» сыйныф укучысы*
*Регина Тупасова*

# Игелекле класс җитәкчебез



Минем сыйныф җитәкчесенең исеме Галия Сөләймановна.

Ул миңа бик ошый. Ул - игелекле, игътибарлы, гадел һәм шул ук вакытта таләпчән. Галия Сөләймановна - ышанычлы кеше.

Ул кара чәчле, урта буйлы. Безнең укытучыбыз бик матур.

Галия Сөләймановна физкультура дәресләрен укыта. Дәрестә ул викториналар, спорт уеннары һәм төрле ярышлар үткәрә.

Галия апа безнең сыйныфны Идел елгасына теплоходта экскурсияга алып барды. Шулай ук ул безне иҗат үзегенә дә йөртте.

Галия апа һәрвакыт укучыларның туган көннәрен онытмыйча, безне котлый, бәйрәмнәр үткәрә. Галия Сөләймановна безне физкультура дәресләрен яратырга һәм спорт белән шөгыльләнергә өйрәтте.

Без укытучыбызны бик яратабыз.

*6 «А» сыйныф укучысы*
*Тәлгат Есмурзаев*

# Аның белән горурланабыз

Минемчә, һәр укытучы хөрмәткә лаек. Мине укыткан һәр укытучы миңа ошый, тик минем иң яраткан укытучым – безнең класс җитәкчесе – Абсалямова Лилия Ришатовна. Ул безнең мәктәптә алгебра һәм геометрия фәннәрен укыта. Ул – бик акыллы, тәрбияле, шәфкатьле кеше. Шуңа аның дәресләрен мин һәрвакыт көтеп алам. Дәрестә теманы да ул бик яхшы аңлата. Кайвакытта контроль эштән начар билгеләр алсак та, без, аны борчымас өчен, бу билгеләрне тиз арада төзәтергә ашыгабыз.

Минемчә, һәр укытучы укучыларының аның предметын яхшы белүен телидер. Безнең шундый класс җитәкчесе һәм укытучыбыз булу белән без горурланабыз.

*7 нче сыйныф укучысы*
*Руфинә Иваева*

# Минем яраткан укытучым

Минемчә, һәр укытучы хөрмәткә лаек. Мине укыткан һәр укытучы миңа ошый, тик минем иң яраткан укытучым – безнең класс җитәкчесе – Абсалямова Лилия Ришатовна. Ул безнең мәктәптә алгебра һәм геометрия фәннәрен укыта. Ул – бик акыллы, тәрбияле, шәфкатьле кеше. Шуңа аның дәресләрен мин һәрвакыт көтеп алам. Дәрестә теманы да ул бик яхшы аңлата. Кайвакытта контроль эштән начар билгеләр алсак та, без, аны борчымас өчен, бу билгеләрне тиз арада төзәтергә ашыгабыз.

Минемчә, һәр укытучы укучыларының аның предметын яхшы белүен телидер. Безнең шундый класс җитәкчесе һәм укытучыбыз булу белән без горурланабыз.

*7 –нче сыйныф укучысы*
*Иваева Руфина*

# Укытучыма

*Укытучымны сагынып,*
*Барам көн дә мәктәпкә.*
*Укырга һәм язарга*
*Ул бит безне өйрәтә.*

*Без телибез Сезгә һәрчак*
*Исәнлек һәм тазалык.*
*Шатлыклы озын гомерләр,*
*Зур уңышлар һәм байлык.*

*Безнең өчен тырышып,*
*Үтә сезнең көнегез.*
*Шуның өчен мәңгегә*
*Без рәхмәтлебез Сезгә.*

*6 «Б» сыйныф укучысы*
*Аслан Нуран*

# Корбан бәйрәме

*Бүген бездә зур бәйрәм -*
*Бүген Корбан бәйрәме!*
*Өчпочмак, кыстыбыйлар -*
*Өстәлебезнең яме.*

*Барлык дуслар, туганнарны*
*Бәйрәм белән котлыйбыз.*
*Дога укып, корбан чалып,*
*Бу бәйрәмне зурлыйбыз.*

*4 «Б» сыйныф укучысы*
*Салават Хәлимуллин*

***Хәзерге заман татар яшьләренә нәрсә кирәк, ничек яшиләр, кайда омтылалар? Ничек итеп аларны татар иҗтимагый тормышына җәлеп итәргә, гореф-гадәтләребезгә карата ихтирам уятырга, татарларга гына хас тәртип һәм әхлак кагыйдәләренә өйрәтергә?***
***Шушы максатта иптәшебез - Самарда укучы Камышлы авылы малае Рамил Фәрзетдинов үз тирәсенә фикердәшләр туплый башлый һәм татар яшьләренең «Duslar club» берләшмәсен оештыра.***



*Гүзәл Әмирова*
*"Duslar club" оешмасы әгъзасы*

# «Duslar club» – яшьләр оешмасы

Оешма 3 ел дәвамында күп кенә файдалы эшләр башкарып өлгерде инде. Ә быел, мөстәкыйль оешма буларак, теркәү үтү белән шөгыльләнә башлады. Шушы уңайдан оешманың хисап-сайлау җыелышы да уздырылды. Анда биш кешедән торган идарә әгъзалары сайларга кирәк иде. Яшьләр бертавыштан Илнур Мансуровны – президент, Рөстәм Сафинны – вице-президент, Гүзәл Әмированы – директор, Эльвира Насырова һәм Азат Әмировларны совет әгъзалары итеп сайлап куйдылар. Оешманың киләчәк эш планнары буенча да фикер алыштык, төзәтмәләр кертелгәч, тавышка куеп, расладык. Оешма үз алдына татар яшьләрен уяту, актив тормыш белән яшәргә өйрәтү, эшлекле кеше буларак, заман таләпләренә дә буйсынып, татар җәмгыятенә дә файда китерергә омтылу бурычлары куйды.

Ни өчен «Duslar club» яшьләре оешмасын официаль рәвештә теркәргә тели дигән сорау бирсәк, моңа күп җавап биреп була. Беренчедән, «Duslar club» яшьләрен Самар шәһәрендә аерым татар яшьләре оешмасы булмау борчый. Икенчедән, «Duslar club» активистлары бүгенге көндә өлкәдәге татар оешмалары күбрәк барлык татарларга ориентирлаша, дип уйлыйлар. Ә алар үз көчләрен һәм тырышлыгын нәкъ татар яшьләренә бирергә, яшь бунны милли рухта тәрбияләргә омтыла.

Хәзерге вакытта оешманың юридик документацияләрен әзерләү эше бара, һәм тиздән Самар шәһәрендә яңа аерым мөстәкыйль татар яшьләре берләшмәсе барлыкка килүе көздә тотыла.

Бүгенге көндә «Duslar club» оешмасы эшчәнлеген төрле юнәлешләрдә алып бара.

Мәсәлән, шәһәрдә яшәүче татар яшьләре арасында үзебезнең телдә сөйләшә белмәүчеләр күп. Бу - зур проблема, һәм аны ничек тә булса урыныннан кузгату, татар



теленең матурлыгын, байлыгын һәм бөеклеген аңлату өчен, төрле викториналар уздырабыз. Шулай, октябрь башында тагын бер викторина үткәрелгән иде. Катнашучылар ике командага бүленеп, төрле биремнәр үтәделәр: татарчадан русчага тәрҗемә иттеләр, дөрес җөмләләр төзеделәр, татар мәкальләре эчтәлеген аңлатырга тырыштылар, башваткычлар чиштеләр. Нәтиҗәләр буенча җиңүче команда билгеләнде һәм призлар белән бүләкләнде

Бу чара татар телен саклап килү һәм үстерү юлында бер кечкенә генә адым булса да, татар теле белән кызыксынучылар саны, һичшиксез, берничә кешегә артты.

Яшьләрне татар язучылары, шагыйрьләре, театр һәм сәнгатъ осталары һәм аларның иҗаты белән таныштыру максатында татар телле кинофильмнар карауны кулай күрәбез. Шулай яшьләребез татар кинематографиясе белән дә кызыксына башладылар. Халыклар дуслыгы йортында Илдар Ягафаровның «Күк тау» фильмын карау оештырган идек. Ул тамашачыларыбызда тирән хисләр уятты. Күркәм шәхесләребез Әзһәр Шакиров һәм Ринат Таҗетдин рольләрен шулкадәр оста башкардылар ки, хәтта күпләребезнең күңелен тәмам яулап алдылар.



